Безнен МИРАС

05
май 2014

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

«Болгардагы кече манара». 1997. Киндер, майлы буяу.
Вәкил Шәйхетдинов рәсеме.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдмәнд

Безнен Мирас
12 +
05(28)
май 2014

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

76

ЭЧТӘЛЕК

4 Минтимер ШӘЙМИЕВ: «Җылы безгә һәрчак тансык иде»


20 Миркасыйм Госмановның тууына 80 ел

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

3 Милли ядкярләребезне бергәләп яктыртыйк!

ТАРИХИ МИРАС

4 **Минтимер Шәймиев: «Кизәк яккан чаклар да бар иде...»**
7 **Төп йорт.** *Роберт Әхмәтҗан*
8 **Кыпчакларның хәрби сәнгате.** *Ярослав Пилипчук*
17 **Яңа төрек дәүләте уңчылары.** *Йосыф Акчура*
20 **Каурый каләм эзеннән...** *Диләрә Госманова*
23 **Археографик көндәлек.** *Миркасыйм Госманов*
29 **Миркасыйм!** *Ләбиб Лерон*
30 **Язма мирасны барлау юлында.** (Түгәрәк өстәл)
40 **Соңгы әңгәмә.** *Нәсим Акмал*
42 **«Шәхесләрсез милли тарих юк...»** *Миркасыйм Госманов белән Нәсим Акмал әңгәмәсе*
50 **Төрки-татар тарихи терминнары.** *Ильяс Мөстәкыймов*
52 **Вулкан серен ачкан татар.** *Инера Сәфәргалиева*

ӘДӘБИ МИРАС

56 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
62 **Бер бәйләм беркетмә**
64 **Кунакчыл дошман.** *Әмирхан Еники*
76 **Фаил — Карашәм күгендәге йолдыз.** *Рәмзи Вәлиев*
82 **Үткәннән хатлар**
84 **Бишенче фасыл.** *Марсель Галиев*
88 **Шигырьләр.** *Эдуард Мостафин*
90 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Мөхәммәтшин*

ҖИҢҮ — 70

91 **Бабайларыбызның каберләре кайда?** *Ләбиб Лерон*
96 **Берлинны кем алган?..** *Мидхәт Садыйков*

СӘНГАТИ МИРАС

98 **Сәйдәш маршы.** *Марс Макаров*

Баш мөхәррир —
Лемон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Марат Закир
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Ирек Миннәхмәтов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР Мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре:
Илдус Заһидуллин
Ленар Гобәйдуллин
Алия Мөбарәкшина
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы —
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор —
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Язылу һәм реклама хезмәте җитәкчесе —
Данил САЛИХОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

ФӘННИ МИРАС

100 **Җиһанда сүзе калыр.** *Таһир Гыйлаҗев*
103 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

МИЛЛИ МАТБУГАТ БИТЛӘРЕННӘН

106 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның май ае.** *Ленар Гобәйдуллин*
111 **«Шура» журналыннан — мәзәкләр.** *Рәисә Шәрәфиева*

ШАЯН МИРАС

112 **Кумпык. Тмин Казанда.** *Фаил Шәфигуллин*

ЮРИСТ КИҢӘШЕ

116 **Мирас һәм варис**

118 **«Безнең мирас» елъязмасы. Май**
119 **Мирасворд**
120 **Яңа китап.** *Таһир Гыйлаҗев*

Заказ №А-1290. **Тираж** — 1500 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 5.05.2014
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.
Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Материаллар бары тик электрон варианттагына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән һәм авторларның архивыннан алынган фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском языке)

Тышлыкның 1 нче битендә — Болгар. Елга портындагы Болгар цивилизация музеенда шагыйрь Кол Галигә куелган һәйкәл.

МИЛЛИ ЯДКЯРЛӘРЕБЕЗНЕ БЕРГӘЛӘП ЯКТЫРТЫЙК!

«Безнең мирас» — шанлы-данлы, яулы-даулы үткәнебездә — давыллы дәверләрдә зилзиләле золым җилләре хәрабәгә әйләндергән мәһабәт калаларның, зиннәтле сарайларның, фетнәле заманнар, зынҗырлы еллар шаукымы йогынтысында җимерелгән, ташландык хәлгә килгән яисә бөтенләй юкка чыккан, бүген исә кабат торгызылган, яңартылган мәчет-манараларның, мәдрәсә-мәктәпләрнең — истәлекле һәйкәлләребезнең, үтә дә кадерле ядкярләребезнең тарихи чагылышы ул.

«Безнең мирас» — халык мәнфәгатен, аның киләчәген кайгырткан, сүз кадерен белгән, туган телнең тугры сакчысы булган фидакяр милләттәшләребез һәм кан-кардәшләребез язып калдырган кыйммәтле кулъязмаларның, әһле каләмнәребез һәм сәнгатькярләребез тарафыннан иҗат ителгән, бәһа биргесез бихисап чәчмә илә тезмә әсәрләрнең, сурәт-сыннарның, көй-җыруларның, шулай ук һөнәри эшчәнлекнең, борын-борыннан алып хәзергәчә йөрәкләрдән-йөрәкләргә, күңелләрдән-күңелләргә күчә килгән кыйссаи-хикәятләрнең, көйле сөйләкләрнең әдәби, сәнгати вә рухи көзгесе.

«Безнең мирас» — Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддин, М.Бигиев кебек мәшһүрләребезнең дини тәгълиматлары, әлеге һәм бүтән асыл затларыбызның бүгенге көндә дә өйрәнелмәгән яисә киң катлау укучыларга барып ирешергә өлгермәгән кулъязмалары, татар дөньясында тирән эз калдырган дин әһелләре һәм аларның тормышы хакында, шул исәптән Һарун Таҗиев кебек дөньякүләм танылу алган атаклы милләттәшләребез һәм аларның саллы хезмәтләре турында язмалар дигән сүз дә...

Мөхтәрәм милләттәшләр, газиз кардәшләр! Әйе, шушы саннан башлап, журналыбыз «Безнең мирас» исеме белән дөнья күрәчәк. Сез дә мираска нисбәтле тирән эчтәлекле язмаларыгызны, фикерләрегезне, киңәшләрегезне журналга тәкъдим итеп торырсыз һәм алга таба редакция игълан итәчәк яңа конкурсларда теләп катнашырсыз, дип уйлыйм.



МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ: «КИЗӘК ЯККАН ЧАКЛАР ДА БАР ИДЕ...»

Лев Овруцкий. «Беседы с Минтимером Шаймиевым» китабыннан

Минтимер Шәймиев әтисе Шәһишәрипнең музей-йортында

– Кабинетыгызда бераз эссе кебек тоела...

— Мөгаен. Кирәк булса, сез теләгәнчә көйлибез аны. Мин үзем гомумән җылы яратам. Безнең өйдә нәкъ Гегельчә — каршылыклар бердәмлеге: миңа — җылы, ә хатыныма салкынча кирәк. Кайтып керү белән бөтен форточкаларны яба башлыйм.

– Чын крестьяннарча инде бу – җылыны сакла.

— Сез хаклы. Элек өй җылыту кыйммәткә төшә иде. Балачакта, җылы кадерен белмәгәнгә арт ягыңа тибеп куюлары да мөмкин иде. Безнең Актаныш ягы Оренбург далаларына чиктәш дип әйтерлек, урманнар юк. Без кизәк яга идек. Моны күз алдына китерә аласызмы?

– Якынча. Даль сүзлегеннән карармын. Тирестән ясала бугай, минемчә.

— Әйе, тирестән кирпечләр ясала, аның бөтен бер технологиясе бар, бик авыр эш. Әйтик, әнкәйгә су җылытырга кирәк, гаиләбездә балалар күп. Ә кизәк пыскып яна, җылысы аз. Өйдән җылы чыкмасын өчен, ишекне үз артыңнан бик тиз ябарга кирәк. Акрынрак кыймылдасаң, тибеп кертәләр яки тибеп чыгаралар. Күбрәк әнкәйдән эләгә, чөнки әткәй гел эштә. Ишекне ачасың да, җәһәт кенә керәсең

«Аннан болай барыбыз да мич башында төренеп ятабыз...»

Зур гаилә бергә җыелгач. Сулдан уңга: Мәрзия, Мәдәния, Минтимер, Гөлсем апа (Мәрзиянең каенанасы), Дөргалия, Шәрип ага, Нәгыймә апа, Зөлфирә, Альбина, Әлфия. 1955 ел

яки чыгасың. Менә шулай. Аннан болай барыбыз да мич башында төренеп ятабыз. Бездә ни өчендер урыслардагы кебек сәке-сәндерәләр юк иде. Урысларда бит махсус рәвештә югарыга сәндерә куялар, чөнки җылы өскә күтәрелә. Әмма бездә балалар — мич башында, анда җылы. Җылы безгә һәрчак тансык иде.

– Тән үзе дә җылы саклауны таләп иткәндер, чөнки тиешле калорияләр җитмәгән аңа. Ул заманда бәрәңге генә ашый идек бит. Без шәһәрдә яшәдек, минем исемдә – әнием газ турында хыяллана иде. Гап-гади газ баллоны турында! Ашауны керосинкада пешерә иде.

— Бездә анысы да юк иде. Институтка кергәч, Казанда керосинкалар сатыла торган лавкаларнең күп икәнлеген күрдем. 50 нче елларда да лавкалар бар иде әле. Мин моны зур казаныш дип саный идем. Ә хәзер без республикага тоташ газ керттек! Мәскәү өлкәсендә хәзергәчә юк әле, ә бездә бар.

– XXI гасырда газлаштыру белән горурлану бераз сәеррәк яңгырый. Биредә сезнең ниндидер шәхси тойгыларыгыз бар икәнен аңлыйм.

— Әлбәттә. Мин кешеләрнең ничек газап чиккәнен беләм. Ә хәзер авылда газ ягалар, газда ашарга пешерәләр. Бөтенләй башка тормыш!

Русчадан ***Марат Закир*** *тәрҗемәсе*

Фоторәсемнәр «Шәрип Шаһимөхәммәт улы Шәймиевнең музей-йорты» дип аталган буклеттан алынды.

ТӨП ЙОРТ

Роберт Әхмәтҗан (1935-2008)

Төп йортым син, төп йортым,
адым белән үлчәнгән
яшел кәсле төп йортым —
түмгәкләр һәм билчәннәр
телен белгән төп йортым…
Төп йортым син, төп йортым,
тургайлы түбәләрем!
Тәрәзәңдә кемнең бу
Ак җаны — күбәләге?
Төп йортым бу, төп йортым,
бабамнар сөйләшкән җир!
Чит җирдән бүреге белән
кайтырга киңәшкән җир…
Бәхетле кеше генә
ятып үз түшәгенә,
багып үз түшәменә,
суың эчкән бер йотым…

Туган илем — Идел-йорт,
Татарстан — төп йортым!

1974

КЫПЧАКЛАРНЫҢ ХӘРБИ СӘНГАТЕ

Ярослав Пилипчук

Кыпчак яугире. XII-XIII гасырлар. М.В.Горелик реконструкциясе

Евразия далалары хуҗалары – күчмәннәрнең тарихын өйрәнгәндә кыпчакларның хәрби сәнгате аерым бер урын алып тора. Галимнәр А.Кушкумбаев һәм Ю.Худяковның монографияләре нәкъ менә шушы темага багышланган [Кушкумбаев, 2009; Худяков, 1997; Худяков, 2011]. Мәкаләбездә төп игътибарны кыпчаклар өчен традицион булган сугышу алымнарына һәм аларның хәрби сәнгате үзенчәлекләрен башка күчмә кабиләләрнеке белән чагыштыруга юнәлттек.

Кыпчаклар – килеп чыгышы Үзәк Азия белән бәйле булган төрки халык. Аларның сугышу тактикалары һәм стратегиясе башка күчмән кабиләләрнекенә охшаш. Гаскәр, тулысы белән диярлек, атлы яугирләрдән торган. Җиңел атлы гаскәр җәя-ук белән коралланган, якын сугышта кылыч һәм сөңге кулланган. Түрәләрнең муены көбә, ә йөзе битлек яки ярым битлек белән капланган, тәннәрен көбә кием саклаган [Худяков 2011, с.41-46].

Кыпчакларның гаскәре берничә полктан торган. Күчмәннәр күбрәк авангард сугышларны яратканнар, бәрелешне, дошман белән турыдан-туры сугышка кермәү тактикасын файдаланып, атлы җиңел гаскәр һөҗүме белән башлап җибәргәннәр. Җайдаклар, дошман сафларына җитәрәк, боҗра буенча хәрәкәт итә башлап, алар өстенә ук яудырганнар. Аннары, хәйләләп, кире чигенгәннәр, дошманнан ераклашканнар, һәм, сан ягыннан өстенлеккә ия булгач кына, янәдән һөҗүмгә күчкәннәр. Мондый тактиканың бер үрнәге итеп, 1205 елгы Адрианополь янындагы сугышны мисалга китерергә мөмкин. Европа тәре йөртүчеләре кыпчакларны үзләренә тиң көндәш итеп санамаган, һәм мондый һавалыклары, мин-минлекләре өчен гомерләре белән түләгән. Җиңел җайдаклар башта рыцарьларга җәядән ук аткан, ә тегеләре куу, эзәрлекләү белән мавыга башлагач, кыпчак җайдаклары, сафларын яңадан тезеп, һөҗүмгә күчкән. Болгарлар һәм кыпчаклар тәре йөртүчеләрне чолгап алган, шулай итеп күп кенә европалы аксөякләр кыпчакларның арканына эләккән. Алар арасында Латин империясе императоры Бодуэн (1172-1205) да булган [Клари, 1986, Глава CXII; Виллардуэн, 1993].

Кыпчакларда авыр атлы гаскәрләр дә булганлыгын Юрий Долгорукий белән Изяслав арасындагы сугышны искә алган елъязма текстлары дәлилли. Аларда кыпчак яугирләренең көбә киемдә булулары һәм Юрий Долгорукий җитәкчелегендә Днепр елгасы аша кичүләре хәбәр ителә [Лаврентьевская летопись, 1962, с.330-332]. Кыпчаклар бәрелеш вакытында елганы кичмәскә тырышкан. Кичкән очракта, гадәттә, елганы йөзеп чыгар алдыннан ун ат тиресеннән капчык ясаганнар, аны салам һәм камышлар белән тутырып, бер тамчы су да үтмәслек итеп теккәннәр. Яугир үзенең барлык әйберләрен дә капчык өстенә урнаштырган, аннары үзе утырган, ә аты, аргы якка йөзгәндә, капчыкны тартып барган. Кыпчаклар кенәз дружиналарына 1093 һәм 1111 елларда елга кичкәндә һөҗүм итә. 1093 елда кыпчаклар, каршы якның каушап калуыннан, хафага төшүеннән файдаланып, күп кенә гаскәриләрне кыра. Бары тик 1111 елда гына алар кыпчакларның кичү вакы-

Чыганаклар һәм әдәбият исемлеге:

Анна Комнина. Алексиада / Пер., вступит. статья, комм. Любарского Я.Н. М.: Наука, 1965. – 688 с. http://www.alanica.ru/library/Komn/text.htm.

Аннинский С.А. Известия венгерских миссионеров XIII и XIV вв. о татарах и Восточной Европе // Исторический архив. М.: Институт истории АН СССР, 1940. Т.III. – С.71-112.

Анчабадзе Г.З. Кыпчаки в Грузии // Проблемы современной тюркологии. Алма-Ата: Наука, 1980. – С.342-344.

Бибиков М.В. Византийские источники по истории Руси, народов Северного Причерноморья и Северного Кавказа (XII-XIII вв.) // Древнейшие государства на территории СССР: 1980. М.: Наука, 1981. – С.5-151.

Бичурин Н. (о. Иакинф). История первых четырёх ханов из дома Чингисова // История монголов. М.: АСТ. Транзиткнига, 2005. – С.7-234.

Венгерский хроникальный свод XIV века // Древняя Русь в свете зарубежных источников. Хрестоматия. Т. IV / Составление, перевод и комментарий А.В. Назаренко. М.: Русский фонд со-

тындагы һөҗүмен кире кайтара алган [Лаврентьевская летопись, 1962, с.218-225, 289].

Күчмәннәрнең иң яраткан сугыш алымы — дошманнарын камалышта калдыру. Бу алым 1097 һәм 1099 елларда Вигор елгасы буенда булган сугыш турындагы язмаларда яхшы тасвирланган. Кыпчак ханы Бонякның өч полкы була, шуларның берсе белән яубашы Алтунопа идарә итә. Аның гаскәриләре хәйләләп чигенә башлагач, маҗарлар аларны эзәрлекләргә ташлана. Күчмәннәр, маҗарларны алдап, засадага алып керә. Боняк бөтен гаскәре белән маҗарларга һөҗүмгә ташлана һәм чолгап ала. Маҗарлар чолганыштан бәреп чыга, әмма кире чигенгәндә каушап калып һәм хафаланып, күбесе Вигор һәм Сян елгаларын кичкәндә батып, һәлак була [Лаврентьевская летопись, 1962, с.270-271]. Рус елъязмаларыннан аермалы буларак, латин телле маҗар чыганаклары сугыш булган урынны атамый, әмма хәрби походта король Коломан Книжникның үзе катнашканлыгы турында мәгълүмат бар. Күчмәннәрнең иртә таңнан һөҗүм итүләре турында да язылa. Бәрелеш турында җентекләп хәбәр ителми. Маҗарлар качып китәргә мәҗбүр була. Чигенгән вакытта Лаврентий һәм Купан исемле епископлар һәлак була. Кыпчаклар, король гаскәриләрен эзәрлекләп барып, Алмыш нәселеннән булган граф Эвзаны да үтерә. Маноч исемле кыпчак яугире корольне эзәрлекли һәм иң оста маҗар сугышчысы Матфейның аягын җәрәхәтли, ләкин үзе Пётр исемле маҗар сугышчысына әсирлеккә эләгә [Венгерский хроникальный свод XIV века, 2010, с.361-362]. Казах галиме А.Кушкумбаев фикеренчә, кыпчаклар күчмәннәр өчен хас булган сугыш алымыннан файдаланган. Авангард дошманга еррактан җәядән уклар атып һөҗүм иткән һәм, хәйләләп, чигенгән. Чигенү һөҗүм итәргә көтеп торган төп көчләр бәрелешкә кергәнче дәвам иткән. Алар көтмәгәндә генә дошман өстенә ташланганнар һәм чолгап алган. Кинәт чолганышта калу маҗарлар арасында паника тудырган һәм аларны җиңелүгә дучар иткән [Кушкумбаев, 2009, с.69-70].

1093 елда Бонякның иң якын көрәштәше Тугоркан дошманны флангларадан урап узу алымын оста файдалана. Бу манёвр Святополк өчен көтелмәгән була, һәм кенәзнең полклары бер-бер артлы тар-мар ителә. Шунысы мөһим, Святополк һөҗүмне көтми һәм хәтта каравыл да куймаган була. Кыпчаклар исә Святополк гаскәриләренең санын һәм урнашуын яхшы белеп эш итә. Шулай ук дошман яугирләренең аз санлы булуы да үз ролен уйный. Кыпчакларның һөҗүменә чыдый алмыйча, алар Днепр елгасын кичәргә омтыла, шунда бер өлеше һәлак була. Кыпчаклар исә йөзеп котылырга ниятләгән Святополк сугышчылары өстенә Днепрның уң як ярыннан ук яудырган [Лаврентьевская летопись, 1962, с.218-225].

Кинәт ясалган һөҗүм бәрелештәге җиңүдә мөһим шарт була. 1068 елда кыпчаклар, Альта елгасы буенда славян кенәзләре дружиналарына төнлә һөҗүм итә. Әлбәттә, Ярославичларның гаскәриләре бу шартларда сугышка әзер булмый, каушап кала. Дошманны тылдан һәм фланлгтан урап узу алымын Кончак 1185 елда Каяла елгасы[1] буенда кенәз Игорь Святославич дружина-

действия образованию и науке, 2010. – С.353-372.

Виллардуэн Жоффруа де. Завоевание Константинополя / Пер., статья и коммент. Заборова М.А. М.: Наука, 1993. – 296с. http://www.vostlit.info/Texts/rus7/Villarduen/frametext4.htm, http://www.vostlit.info/Texts/rus7/Villarduen/frametext5.htm.

Голден П. Религия кыпчаков средневековой Евразии // Степи Европы в Эпоху Средневековья. Т.6: Золотоордынское время. Донецк: Донецкий нацональный университет, 2008. – С.309-340.

Горелик М.В. Армии монголо-татар X–XIV вв. Воинское искусство, снаряжение, оружие. М.: ООО Восточный горизонт, 2002. – 84 с.

Гръцки извори за българската история. Т.VI / Съставили и редактирали Тъпкова В., Войнов М., Йончев Л., Тъпкова-Заимова В., Дуйчев И., Иванов Й., Йончев Л., Батаклиев Г., Коледаров П. София: БАН, 1965. – 371 с.

Гръцки извори за българската история. Т. X / Съставили и редактирали Йончев Л., Тъпкова-Заимова В., Батаклиев Г., Войнов М. София: БАН, 1980. – 421 с.

сы белән бәрелешләрдә файдалана. Кыпчаклар, даладагы кенәз гаскәрен чолгап алып, һәряктан ук яудыра. Бәрелешнең хәлиткеч мизгелендә аларның авыр атлы гаскәриләре һөҗүм итеп, канкойгыч бәрелештә җиңә һәм Игорь Святославичны һәм аның улы Владимирны әсир итеп ала [Плетнева, 1990, с.160-164]. Әмма 1097 (яки 1099) елда уңышлы кулланылган бу сугыш алымы 1103 елда җиңүгә китерми. Бу юлы далага походка чыккан славян дружиналары үзләре кинәттән һөҗүм итә һәм кыпчак ханы Алтунопа отряды сугышчыларын кырып сала [Лаврентьевская летопись, 1962, с.277-279; Плетнева, 1990, с.56].

Кыпчакларда «халык-гаскәр» принцибы яшәгән. Шунлыктан кыпчак гаскәриләренең саны дошманныкына караганда өч, хәтта биш мәртәбә күбрәк, ә атлы авыр яугирләрнең саны азрак булган. Шул сәбәпле, алар, көчләр чагыштырмасы үзләре файдасына булмаган очракта, хәлиткеч бәрелешләрдән качкан.

Кыпчакларның тормыш-көнкүреше сугыш шартларына яраклашкан булган. Һәр күчмән шәхси коралы белән үз мал-туарын һәм гаиләсен саклаган. Сугышларның ешлыгына ел фасыллары һәм табигать шартлары йогынты ясаган. Һөҗүмнәр җәй яки көз айларында, утрак тормыш алып баручылар урак өстендә булган вакытта, аеруча еш оештырылган. Бу айларда әсирләрне күпләп кулга төшерү мөмкинлеге зуррак булган. Кышкы һөҗүмнәр далада терлекнең күпләп кырылуы яки азык-төлекнең җитешмәве сәбәпле оештырылган [Лаврентьевская летопись, 1962, с.163].

Кыпчаклар Маҗарстанга һөҗүм иткәндә бөҗәнәкләр тарафыннан салынган юлдан барганнар. Алар тәүге мәртәбә бирегә 1091 елда Дунай һәм Көньяк Карпат арасыннан бәреп кергән. Әмма маҗарлар, баскыннар кире кайтканда, кыпчакларның бер отрядын Паганти елгасы (Поганч инеше) буенда куып җитәләр. Маҗар елъязмачысы хәбәр итүенчә, король Ласло кыпчак ханы Копульха лагерена һөҗүм итә, күчмәннәрдән бары тик Эсембу исемле яугир генә качып котыла. Акуш, Копульханың һәлак булуын ишетеп, үч алырга ант итә. Дунай елгасы буенда маҗар короле Ласло Акушны тар-мар итә. Бу бәрелештә маҗарларның мөһим өстенлекләре булып, атлы авыр рыцарьлар тора.

Барлык сугышлар өчен дә уртак күренеш — бөҗәнәкләрнең һәм кыпчакларның Маҗарстанга шактый ерак үтеп керүләре. Мөгаен, күп әсирләр кулга төшереп һәм талап алган аяклы малларны куып барган кыпчаклар үзләренең мобильлекләрен һәм уяулыкларын югалтканнардыр, шул сәбәпле кайту юлында маҗарлар аларны талаган. Маҗарларның разведкалары яхшырак эшләгәнлеген дә искәртергә кирәк. Кыпчаклар һәм бөҗәнәкләр өстенә көтмәгәндә генә килеп чыгулары, кизү торучыларын үтерүләре, аларның күчмәннәр лагере урнашкан урынны яхшы белгән, дип уйларга мөмкинлек бирә [Шушарин 1997, с.326-328].

XIII гасырда маҗарлар кыпчак һөҗүмнәренә оешкан төстә җавап кайтарыр өчен атлы җиңел гаскәр отрядлары оештыра, шулай итеп Трансилвания гаскәриләре составында кыпчаклар-

[1] Бу елганың хәзерге вакытта кайсы елга булуы турында галимнәрдә төрле фикерләр бар.

Жития царя-царей Давида // Символ. №40. (1998) // http://www.vostlit.info/Texts/Dokumenty/Kavkaz/XI/1080-1100/David/frametext1.htm.

Ипатьевская летопись/ Воспроизведение текста издания 1908 г. // Полное собрание русских летописей. М.: Восточная литература, 1962. Т.2. XVI, 938, 87, IV с.

Кадырбаев А.Ш. Тюрки и иранцы в Китае и Центральной Азии XIII-XIV вв. Алма-Ата: Гылым, 1990. – 160 с.

Клари Робер де. Завоевание Константинополя / Пер., статья и коммент. Заборова М.А. М.: Наука, 1986. – 170с. http://www.vostlit.info/Texts/rus/Klari/frameKlari3.htm; http://www.vostlit.info/Texts/rus/Klari/frameKlari4.htm

Кляшторный С.Г. История Центральной Азии и памятники Князький, 1988 – Князький И.О. Половцы в Днестровско-Карпатских землях и Нижнем Подунавье в конце XII – первых десятилетиях XIII в. // Социально-экономическая и политическая история Молдавии периода феодализма. Кишинев: Штиинца, 1988. – С.22-32.

Кумеков Б.Е. Кыпчаки: хозяйство, общественный строй, племенной состав // Исто-

Дәште Кыпчак күчмәннәренең тактика алымнары

Җәядән ук атучы җайдакларның дошман гаскәре алдында «бoжра» буенча хәрәкәте	«Бoжра»дагы җайдакларның дошманны алдалап чигенүе	Засададагы гаскәр катнашында дошманга контрһөҗүм ясау



А. Җәядән атучы җайдакларның дошман гаскәре алдында «бoжра» буенча хәрәкәте. Дошман гаскәре сафларына ук яудыру.
Б. Дошман атлы гаскәренең һөҗүмгә ташлануы, «бoжра»дагы җайдакларның җәядән ук атып чигенүе.
В. Күчмәннәрнең засададагы гаскәр белән берлектә контрһөҗүме.

Л.А.Бобров рәсеме

ны җиңә. Хәер, аларның башка төрле стратегияләре дә булган. Кыпчак һөҗүмнәре Брашов һәм Фегарш комитатларына[2] зыян сала, мажарларның чик буендагы гаскәрләре күчмәннәргә каршы тора алмый. Кыпчакларның күпсанлы яугирләре көтмәгәндә генә килеп чыга, чик буе заставасын һәлак итә һәм Карпат таулары аркылы Трансильваниягә үтеп керә. Аларга каршы торыр өчен мажар короле Эндре II Тевтон ордены рыцарьларына Бырца биләмәсен бирә. Тевтон рыцарьлары кыпчакларга ялан кырда сугышырга ирек бирми, ә ныгытылган торак пунктлары корып, шунда кысрыклый. Мондый берничә саклану торак-пункты кору нәтиҗәсендә тевтонлылар кыпчакларның Бырца биләмәсенә һөҗүмнәрен туктатып кына калмый, хәтта аларның җирләренә үтеп тә керә. Тевтонлыларның кыпчак җирләренә чираттагы һөҗүменә король Эндре IIнең Трансильваниядәге Тевтон орденына бирелгән биләмәләрне конфискацияләве комачаулый. Король, тевтонлылар урынына, чик буе сакчылары буларак, кыпчаклыларны

[2] Комитат — Мажарстан корольлегендә X гасырдан алып 1918 елга кадәрге тарихи админстратив-территориаль берәмлек.

рия татар. – Т. 2: Волжская Булгария и Великая Степь. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2006. – С.472-481.

Кушкумбаев А.К. Институт облавных охот и военное дело кочевников Центральной Азии. Сравнительно-исторческое исследование. Кокшетау: Келешек–2030, 2009. – 170 с.

Кычанов Е.И. Сведения в «Юань-ши» о переселениях кыргызов в XIII в. // Известия Академии наук Киргизской ССР. Фрунзе: АН

үзенең федераты итәргә[3] тели, шуның өчен көнчыгышка миссионерлар җибәрелә. Һәм, табигый ки, дипломатияне эшкә җигә. XIII гасырның 20 еллары азагында Куман епископиясе оештырыла. Католик динен кабул иткән кыпчак гаскәренең яубашлары Бортц хан һәм аның улы Мемборк маҗарларга славян һәм кыпчак кабиләләренә каршы көрәшергә булыша. Галич төбәгендәге кенәз дружиналарына каршы сугышкан маҗар яугирләре арасында да кыпчаклар булган [Князький, 1988, с.22-32].



Монгол укчылары. Рәшид әд-Диннең «Елъязмалар җыентыгы»ндагы рәсем. 1306 ел.

Федератларны чик буен сакларга җәлеп итү — маҗарлар гына уйлап чыгарган яңалык булмаган. Византия империясенең гаскәри хезмәтендә дә кыпчаклар булган. Алар Дунай буйларында, Добруджада һәм Могленда яшәгән һәм хезмәт иткәннәре өчен прония[4] алган [Stoyanow, 2002, p.683; Бибиков, 1981, с.130-133]. Византия короле Мануил Комнин (1118-1180) аларны Сицилия норманнарына, төрекләргә һәм, мөгаен, 1148 елда Димницикка һөҗүм иткән Дунай буе кыпчакларына каршы файдалангандыр [Бибиков, 1981, с.117]. Соңрак кыпчаклар болгарларга тырышып хезмәт куя. Ярдәмче хәрби көч буларак, алар византиялеләрне алҗытып бетерә һәм, аларны манёвр ясау мөмкинлегеннән мәхрүм итә. Алар Византия империясе гаскәренең тыл белән элемтәсен өзә. Бу вакытта кыпчакларның бер өлеше Веррое, ә бер өлеше Филипополь (Пловдив) янында сугыша. Шәһәрләрнең гарнизоны төп көчләргә ярдәм итә алмаган. Нәтиҗәдә Византия императорының яугирләре тауларда чолганышка эләгә [Никита Хониат, 1862].

Кыпчакларга тауда сугыш хәрәкәтләре алып бару авыр булган. Бирдә алар үзләре генә сугышса, җиңелгән, чөнки таулы урыннарда атлы гаскәрне тиешенчә файдалана алмаганнар. 1223 елда Грузия патшалыгы гаскәриләрен җиңү бары тик Азәрбайҗандагы Гәнҗә әмиренең ярдәме белән генә мөмкин булган. Бу сугышта атлы мәргәннәрнең бурычы җәядән ук атып, дошманның өстенлеген юкка чыгару белән чикләнгән [Анчабадзе, 1980, с.342-344].

Дала сугышларында җитез хәрәкәт итү гаять мөһим. Шуңа да күчмәннәр бәрелешнең башында алман дипломаты Сигизмунд Герберштейн tanz дип атаган сугыш алымын файдаланган [Горелик, 2002, с.30]. Бу алым аеруча лагерьны кору өчен туктаган дошманга һөҗүм иткәндә кулай саналган. Шулай ук әлеге алым башка күчмән кабиләләре белән бәрелешләрдә дә уңышлы файдаланыл-

[3] Федератлары итәргә — ягъни, союздашы итәргә.
[4] Прония — Византия империясендә хезмәт өчен түләү. Бу түләү билгеле бер территориядә салым җыю һәм идарә итү хокукы бирү формасында булган.

Кирг ССР, 1965. Т. V. Вып.1 – С. 59-65. // http://www.kyrgyz.ru/?page=76.

Лаврентьевская и Суздальская летопись по Академическому списку/ Воспроизведение текста изд. 1926–1928 гг. // Полное собрание русских летописей. М.: Восточная литература, 1962. – Т.1. VIII. – 579 с.

Новгородская первая летопись старшего и младшего изводов. М.: Издательство Академии наук СССР, 1950. – 640 с.

Плетнева С.А. Половцы. М.: Наука, 1990. – 208с.
Пріцак, 2008. –

ган. Күчмәннәрнең отрядлары, җитез манёврлар ясарга мәйдан калмасын өчен, бер-берсен чолгап алырга омтылган [Кушкумбаев, 2009, с.81-82]. Ике якның да максаты —дошманның төп көчләрен камалышта калдыру һәм юк итү. Һөҗүм вакытында күчмәннәр гаскәрләрен берничә эре төркемгә бүлеп, таратып урнаштырган. Моңа фәкать камап алу тәртибендә һөҗүм итеп кенә каршы торып булган. Һөҗүм итүчеләр дошманны ярымай рәвешендә, яки боҗрага урап алган [Кушкумбаев, 2009, с.81-84].

Дәште Кыпчак мондый сугыш алымын кулланыр өчен иң кулай урын булган, киң дала җайдакларга җитез хәрәкәтләнү өчен мәйдан биргән. Җиңеп чыгу өчен төп таләп — күп сандагы атлы мәргәннәр булу. Гаскәр йөзләрчә чакрымнарга кадәр таралып урнашкан. Монголлар белән бәрелешләр вакытында кыпчаклар, камалышта калмас өчен, күпсанлы гаскәриләре белән чигенергә мәҗбүр булган. Кайчакта күпсанлы гаскәриләрнең чикләнгән мәйданга тупланувы фаҗигаләргә дә китергән. Әйтик, шушы юл белән монголлар кыпчакларны Кырым ярымутравында камалышта калдыра. Монголлар, кыпчак яугирләренең саны ачлыктан кимегәч кенә, һөҗүмгә күчкән. Әгәр кыпчаклар чикләнгән территориягә килеп эләкмәгән булса, аларны чолгап алу бик кыен булыр иде [Кушкумбаев, 2009, с.91-94].

Күчмәннәр арасындагы бәрелеш, гадәттә, ат өстендәге мәргәннәрнең җәядән ук атышулары белән башланып киткән, аннары сөңге, кылыч сугышына күчкән. 1223 елда Калка буендагы яу моның ничек барганлыгын күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Биредә атлы җиңел гаскәриләр бер-берсенә ук яудыргач, славян кенәзенең атлы авыр гаскәриләре алга ыргылган, ә алар арасында кыпчаклар да булган. Кенәзләр Мстислав Ярославович Немой, Даниил Галицкий, Олег Курский яугирләре монголларны эзәрлекли башлаган, алар исә кыпчакларның иң яраткан алымыннан файдаланган — хәйләләп чигенгән. Славяннар монголларның атлы авыр гаскәриләре сугышка кергәнне көтеп торган. Монголларның атлы җиңел гаскәре славян һәм кыпчак дружиналары белән бәрелешләрдә җитди югалтулар кичерә. Яу кырына монголларның атлы авыр гаскәриләре кергәннән соң, сугышның хәлиткеч мизгелләре башлана. Монголлар төп һөҗүмне славян-кыпчак гаскәренең бер як флангына юнәлтә, союздаш гаскәрнең сафын өзә һәм аның рәтләрен бутый. Алар басымы астында славяннар һәм кыпчаклар чигенә башлый. Тиздән чигенү качуга әверелә: монголларның атлы җиңел гаскәре качучыларны эзәрлекли башлый. Рюриклар арасындагы ызгыш-талаш җиңелүгә иң зур сәбәп була. Бердәм хәрби җитәкчелек булмау сәбәпле, кенәз Мстиславның монголларга үзенең алдынгы отряды белән генә һөҗүм итүе фаҗигагә китерә. Монголлар союздаш гаскәрне аерым кисәкләргә бүлеп, тар-мар итә. Далада чолганышта калган Киев кенәзе гаскәре су чыганакларыннан аерылган хәлдә өч көн саклана, монгол мәргәннәре аларны күпләп кыра [Лаврентьевская летопись, 1962, с.503-509].

1236-1242 еллардагы «Бөек Көнбатыш походлары» вакытында монголлар күп илләрне яулап алыр өчен һөнәрчеләрне, шулай ук утрак тормышта яшәгән халыкларны да үзләре белән ал-

Пріцак О. Коли і ким було написано «Слово о полку Ігоревім». К.: Обереги, 2008. – 360 с.

Сокровенное сказание монголов / Перевод С.А. Козина. М.: Товарищество научных изданий КМК, 2002. – 156 с.

Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. – СПб.: Издано на иждевении С.Г. Строганова, 1884. Т.I: Извлечения из сочинений арабских. XVI. – 563 с.

Тизенгаузен В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. – М.-Л.: Изд-во Академии Наук СССР, 1941. Т.II: Извлечения из персидских сочинений, собранных В.Г. Тизенгаузеном и обработ. А.А. Ромаскевичем и С.Л. Волиным. – 305 с.

Хониат Никита. История со времения царствования Иоанна Комнина / Перевод в редакции Н.В. Чельцова. СПб.: Санкт-Петербурская Духовная Академия, 1862. 540 с. Т.2. (1186–1206). http://www.hist.msu.ru/ER/Etext/Xoniat/index.html

Храпачевский Р.П. Военная держава Чингисхана. М.: ООО Издетельство АСТ: ОАО ВЗОИ, 2004. – 557 с.

Худяков Ю.С. Комплекс вооружения восточных кыпчаков в эпоху развитого Средневековья // Во-

ган. Шулай итеп аларның гаскәрләре тизлек һәм җитезлек җәһәтеннән кыпчаклардан калышса да, сан ягыннан өстенрәк булган [Тизенгаузен, 1941, с.24]. Монголларның гаскәр башында тәҗрибәлерәк хәрби җитәкчеләр торган, ә кыпчакларда исә алар — санаулы гына. Күп кенә кыпчаклар, каршылык күрсәтү уеннан чигеп, Дәште Кыпчакның аръягына чыккан.

Ворскла янындагы сугыш. 1399 ел. «Лицевой летописный свод». XVI гасыр азагы

Күченергә һәм монгол ягына чыгарга теләмәгән кыпчаклар мөмкин булган бердәнбер стратегиягә — партизаннар сугышына керешкән. Бу юнәлештә Бачман хан аеруча активлык күрсәтә, ул берничә ел дәвамында монголларны үзенең һөҗүмнәре белән борчып тора. Монголлар, тылларының куркынычсызлыгын тәэмин итәр өчен, көчләренең бер өлешен кыпчакларны камап алырга җибәрә, ләкин кыпчаклар алар кулына эләкмәгән диярлек. Бачманның җиңелүендә хәлиткеч рольне кыпчак хыянәтчеләре уйнаган — алар монголларга лагерь урынын әйтә. Бәрелештә, монгол яугирләре саны күп булу сәбәпле, кыпчаклар җиңелә. Үлем алдыннан Бачман тезләнми һәм исән калдыруларын сорамый [Тизенгаузен, 1941, с.24, 35-36; Бичурин, 2005, с.200-201; Храпачевский, 2004, с.375]. Кыпчак аксөякләренең бер өлеше дошман белән хезмәттәшлек итә башлавы монголларның Дәште Кыпчакка һөҗүме вакытында хәлиткеч рольне уйный [Тизенгаузен, 1941, с.24, 35-36; Бичурин, 2005, с.200-201; Храпачевский, 2004, с.375].

Кыпчак гаскәриләренең саны — махсус өйрәнүне сорый торган мәсьәлә. Рус елъязмаларында кыпчак гаскәриләренең күпсанлы булуы теркәлгән. Биредә кыпчаклар һөҗүмнәрне гаиләләре белән оештырганлыгын истә тотарга кирәк. Әгәр дә тәҗрибәле яугирләрне генә исәпкә алсак, кыпчак гаскәренең сан ягыннан өстенлеге алай зур булмаган.

Күчмәннең шәхси батырлыгы аның җәмгыятьтәге урынын, дәрәҗәсен билгеләгән. Аларда көч культы булган. Боняк һәм Тугоркан 1201 елда Левунион янындагы сугышта византиялеләрнең кыюсызлыгын күреп, безгә нәрсә итен ашасак та — бәрәннекен яки бүренекен — барыбер, дигән. Бәрән дип кыпчаклар византиялеләрне, ә бүре дип бөҗәнәкләрне атаган. Төркиләрдә бүре белән чагыштыру комплемент, мактау сүзенә тиң булган [Комнина 1965, Книга 8, Параграф 5]. Ауда яки сугышларда катнашу яшь күчмәнне чыныктырган, шәхесен формалаштырган. Батыр булу нәсел дәвамлылыгына да йогынты ясаган. Үз кабиләсендәге кызның гаиләсенә калым түләмәс өчен, күчмән күрше кабиләгә һөҗүм итеп, андагы хатын-кызны кулга төшерә алган. Гадәттә, соңгылары аны куа килгән, һөҗүмгә каршы торыр өчен дә кып-

енное дело Золотой Орды: проблемы и перспективы изучения. Материалы Круглого стола, проведённого в рамках Международного Золотоордынского Форума. Казань, 29–30 марта 2011 г. Казань: ООО «Фолиант», Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2011. – С.41-46.

Шушарин В.П. Ранний этап этнической истории венгров. М.: РОССПЭН, 1997. – 512 с.

Цулая Г.В. Джелал ад-Дин в оценке грузинской летописной традиции. // Летописи и хроники: Сборник статей: 1980 г. В.Н. Татищев и изучение русского летописания / Отв. ред. Б.А. Рыбаков. М.: Наука, 1981. // http://www.vostlit.info/Texts/rus13/Chronograf_14v/

чак егетенең оста сугышчы булуы соралган [Кляшторный, 2003, с.473, 475, 481].

Тарихи чыганаклар кыпчакларның угызлар һәм бөҗәнәкләр белән бәрелешләре турында саран мәгълүмат бирә. Анна Комнина бөҗәнәкләрнең византиялеләргә һәм кыпчакларга лагерь белән каршы торуларын яза. Ябык йөк арбалары бөҗәнәкләргә дошман җайдакларыннан саклану чарасы булып торган [Комнина, 1965, Книга 8, Параграф 5]. Кыпчаклар бөҗәнәкләр лагерена җәядән ук аткан, әмма җиңүгә фәкать йөк олаулары рәтләрен таркатып кына ирешә алган. Кыпчаклар кебек үк бөҗәнәкләр дә яуга гаиләләре белән киткән. Йөк олауларын саклану чарасы итеп, дошман сан ягыннан өстен һәм аның хәрәкәт юнәлеше билгеле булган очракта гына кулланылган [Комнина, 1965, Книга 8, Параграфы 4-6]. Һөҗүм итү көтмәгәндә генә ясалса, мондый саклану ысулын кулланып булмаган. Әлеге очракта, саклаучы тараф кул сугышына күчкән һәм бәрелешне яугирләрнең хәрби осталыгы хәл иткән.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: кыпчакларның бәрелешләрдә файдалана торган иң яраткан алымнары — хәйләләп чигенү, дошманны камап алу, флангтан урап узу һәм дошманны чолганышта калдыру. Аларның таулы урыннарда камалышта калдыру һәм сугышу осталыклары булмаган. Шунлыктан кыпчаклар мондый бәрелешләрдә утрак тормышлы халыкларның гаскәрләре белән союзда булып, атлы яугирләр ярдәмче хәрби көч буларак кына катнашкан. Угызларның кыпчаклар белән бәрелешләренең башлангыч этабына җитез манёврлы һөҗүмнәр хас. Бу сыйфатлар монголларның яулап алу дәверендәге сугышларында да күзәтелә. Монголларның гаскәрләре көнбатышка күченү барышында яулап алынган күчмәннәр хисабына арткан. Монголлар һәм угызларга да кыпчаклар ия булган сыйфатлар хас. Даладагы сугышларда җиңү яубашчыларның осталыкларына һәм яугирләренең батырлыгына бәйле булган. 1236-1242 елларда «Бөек көнбатыш походы» дәверендә монгол гаскәрләренең хәрәкәтләнү тизлеге кимүе һәм партизаннар сугышы алып барган кыпчак отрядларына камалышка эләгүе күзәтелә. Күчмәннәрнең үзара бәрелешләрдә җиңүен яубашларның таланты, хәрбиләрнең җитез хәрәкәтләре, батырлыгы һәм саны ягыннан күплеге хәл иткән. Елъязмаларда кыпчак хәрбиләренең саны берникадәр арттырып күрсәтелә. Кагыйдә буларак, гаскәриләрнең түгел, ә кыпчакларның гомуми саны атала. Күчмәннәрнең үзара бәрелешләре, сугышлары дүрт хәрәкәт схемасында чагылыш таба: 1) камап алу, бу алымны күп сандагы җайдаклар азрак сандагы дошманны яулаганда файдаланганнар; 2) йөк арбалары белән ныгытылган лагерьлардан һөҗүм, бу алым бары тик сан ягыннан өстен булганда гына кулланылган; 3) ганимәт малы белән авырайган дошманның гаскәренә каршы контрһөҗүм; 4) көтмәгәндә, кинәттән һөҗүм.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин*** *тәрҗемәсе* ■

frametext1.htm
Gökbel A. Kipchaks and Kumans // The Turks. Ankara, 2002. Vol. 1. – P.643-659.

Kurat A.N. IV–XVIII Yüzyıllarda Karadenizin Türk Kavimleri ve Devletleri. Ankara: Üniversitesi Dil ve Tarih-Coğrafya Fakültesi Yayınları, 1972. – 511 s.

Paul Pelliot, Louis Hambis. Historie des campagnes de Gengis Khan. Cheng-wou ts'un-tcheng lou / Traduit et annote par Paul Pelliot et Louis Hambis. Leiden: E.J. Brill, 1951. – XXVII, (1), 485 p.

Stoyanow V. Kumans in Bulgarian history // The Turks. Ankara: Yeni Türkiye Yayynlary, 2002. Vol. I. – P.680-692.

Vasary I. Cumans and Tatars.Oriental Military in the Pre-Ottoman Balkans, 1185–1365. Cambridge: Cambridge University Press, 2005. XVI. – 230 p.

ЯҢА ТӨРЕК ДӘҮЛӘТЕ УҢЧЫЛАРЫ*

Йосыф Акчура

БОХАРАЛЫ СӨЛӘЙМАН ӘФӘНДЕ

Сөләйман пашаның төрекчелек эшчәнлеге көннәрендә бохаралы шәех Сөләйман әфәнденең дә төрки милләтчелеге юлында — тел, фольклор, гамәли сәясәт өлкәләрендә эшләгәнлеге күренә. Сөләйман әфәнденең бу юлда мәйданга китергән хезмәте — «Чыгатай һәм госманлы төрки сүзлеге» китабы. Бу китапның проза һәм шигъри рәвештә язылган чыгатай һәм госманлы телендә үрнәкләр китерелгән кереш бүлегендә автор чыгатай телен дөньяда булган төрки телләрнең анасы, госманлы төрки теленең нигезе һәм чыганагы, дип күрсәтә. Шуңа нигезләнеп, Госманлы дәүләтендә дә ул телне өйрәнү, белергә тырышу кирәклеге турында сөйләп, исбатлап тормаска була, ди. «Госманлы төрки теле» бүлеге керешендәге бу төп фикерен «Чыгатай теле» керешендә башкарак сүзләр белән тагын кабатлый: «Бүген Госманлы дәүләтендә кулланышта булган госманлы теле — чыгатай теленнән, ягъни бүген дә Мәвараэннәһердә [1] кулланышта булган телдән аерылган», — ди. Автор чыгатай теле белән госманлы теле бәйләнешен шулай билгеләгән кебек, госманлылар этнологиясен, аеруча госманлы солтаннары нәсел чылбырының да Мәвараэннәһер белән бәйләнешенә басым ясый. Дөрестән дә, бу династия чылбыры буыннан-буынга күчеп, чыгышлары һәм тамырлары Мәвараэннәһергә барып тоташа ди. Шуннан соң Урта Азиядә (Мәвараэннәһердә) яшәгән 92 үзбәк кабиләләренең исемнәрен саный, аларның мәкальләрен һәм йөздән артык шагыйрьләренең шигырьләреннән үрнәкләр туплаганлыгын яза. Шигырь белән язылган чыгатай телендәге керештә максат — чыгатай теле госманлы теленең борынгы формасы буларак, алар арасындагы бәйләнешне, шул рәвешчә, бер телнең ике тармагы икәнен күрсәтү, ягъни чыгатай һәм госманлы халкының, бу ике телнең бердәмлеге идеясен алга сөрү.

Тел һәм аңа ничек карау ноктасыннан, ул төркиләрнең берлеген күргән һәм күрсәтергә теләгән. Үзбәк шәехе бу берлекне тел һәм нәсел берлегенә нигезләп исбатларга омтыла. Төркестан төркиләре белән госманлы төрекләре арасында кайбер мөнәсәбәтләрне гамәли урнаштыру юнәлешендә тырышлык күрсәтә. Солтан Габделхәмит тәхеткә чыккан елларда [2], төрек-рус сугышы [3] алдыннан булса кирәк, шәех Сөләйман әфәнденең, көнчыгыш илләренә сәяхәте була. Бохаралы шәех, Госманлы солтанлыгы илчелеге җитәкчесе сыйфатында, Һиндстан, Әфганстан, Бохара, Һива дәүләтләрендә була. Менә төрекмәннәр илендә булуы турындагы бәет:

Төрекмәннең хәлене бер-бер белдем,
Женес-ү микъдарыны дәфтәр кылдым.

Шәех әфәнде Урта Азия, Һинд җирләрендә гизгән кебек, бу сәфәреннән кайтканнан соң, нәкъ шул рәвештә, сәяхәте уңай нәтиҗәле булуын искәртә. Кулыбызда башка документ булмаса

* Дәвамы. 2014 елның 1 нче саныннан басылып килә.

да, шәех Сөләйман Үзбәкинең бу язмасыннан, төрек-рус сугышы елларында, аның Госманлы хөкүмәте тарафыннан Төркестан төрки хөкүмәтләренә һәм халкына илче итеп җибәрелүен, төрекмәннәрнең җенес вә микъдарын дәфтәргә күчергәнен, Кабул һәм Бохара әмирләре белән сөйләшүләр алып баруын, аннары Истанбулга әйләнеп кайтуын беләбез. Бу вакыйгалар Көнчыгыш һәм Көнбатыш төркиләренең, урыс басып алуы куркынычы астында калган көннәрендә, тел, нәсел, кавем, раса берлекләрен исләренә төшерүләрен билгеләсәк, ялгышу булмас, дип уйлыйм. Игътибар итәрлек икенче нәрсә — шәех Сөләйман әфәнде, шул сәяхәтеннән соң, «Чыгатай һәм госманлы төрки сүзлеге» әсәрен язып бастыруны кирәк дип таба.

Шәех Сөләйман әфәнденең бу «Илчелек сәяхәте» Англия хөкүмәте киңәше белән үткәрелү ихтимал булганлыгы телгә алынган вакыйгалардан да сиземләнә. Мондый сәяхәттән ниндидер бер җитди нәтиҗә көтү хыялыйлыкка сабышу булыр иде. Шулвакыттагы Әфган әмире Шир Али ханның шәех Сөләйман әфәндене аеруча хөрмәтләп кунак итүе, бер тарафтан, буйсындырылган Бохара әмире Русия сәясәтенең ышанычлы бер таянычына әйләнүенә, әмирнең Русиягә буйсынуына мөнәсәбәтен күрсәтү иде. Русия белән дәвамлы сугыш хәлендә булган батыр, сугышчан төрекмән кабиләләренең каты каршылыгын тагын да көчәйтүгә дә бу сәяхәтнең тәэсире булуын искәртә. Госманлы гаскәренә Дунай буенда һәм Кавказ аръягында рус гаскәрләре белән бәрелешендә [4] төрекмәннәрнең күпмедер ярдәме булган. Шуңа күрә Госманлы хөкүмәте бу сәяхәттән бик канәгать кала. Истанбулга кайткан шәех Сөләйман әфәндене котлап каршы алалар. Ул бу турыда «Монда (Истанбулда) бәгъзе җиргә әгъза булдым, Фәхри (хөрмәтле) хезмәтләргә сәхпа булдым (күтәрелдем)», — ди.

Дөрестән дә, газый (сугышта үлгән) Госман пашага мактаулы кылыч китергән маҗарларга (венгр) рәхмәт белдерү өчен җибәрелгән төрек илчелеге башлыгы итеп шәех Сөләйман әфәндене билгелиләр. Урта Азия ватандашларыннан еракта, Көнбатышта (Европа үзәгендә), үзбәк шәехенә хөрмәт күрсәтүләре Сөләйман әфәнденең үзенә дә, маҗарларга да куанычлы тәэсир итә.

Җөмләсе (барчасы) берәм-берәм
килеп үпте.
Төрек! Дия алкыш илә кыямәт купты.
Иске госманлы теле ди(я)рләр,
Азиядән килмешем аңладылар.
Чыгатай белдегемне тыңладылар.
Чук кәлам (күп сүз) сөйләүне
күбесе теләделәр,
Бу лөгать (и)лә мөшварә (әңгәмә)
сөйләшү әйләделәр...

«Чыгатай һәм госманлы төрки сүзлеге» китабының кереш мәкаләләреннән китерелгән фактлардан, шәех Сөләйман әфәнде бәлки үзе дә аңлап җиткермәгән, «бөтен төркилек» фикере барлыгын күрәбез. Бу китап Истанбулдагы кайбер югары дәрәҗәле эшлеклеләр һәм хәтта хөкүмәт даирәләрендә ул фикерне файдаланырга тырышкан затлар булганына да дәлил булып тора ала. Шәех Сөләйман Үзбәки Бохариның «Чыгатай һәм госманлы төрки сүзлеге» әсәренең беренче томы 1882 елда Истанбулда 320 битле китап рәвешендә басылып чыга. Өч кереш мәкалә һәм чыгатай төркичәсеннән госманлы төрекчәсенә тәрҗемә кыска бер сүзлек бар. Сүзләргә, күпчелек очракта, билгеле шагыйрьләр әсәрләреннән алынган өзекләр белән мисаллар китерелә. Бу әсәрнең үзбәк кабиләләре халкы әдәбиятыннан, Урта Азия шагыйрьләре әсәрләреннән һәм Мәвараэннәһер тарихына кагылышлы байтак документлардан торган икенче томы басылмаган булса кирәк. Мин бик тырышып эзләсәм дә таба алмадым.

ӘХМӘТ МИДХӘТ ӘФӘНДЕ

Әхмәт Мидхәт әфәндене дә бу чорның төрекче язучылары арасына кертү урын-

лы булыр. Бу — бик күп язган һәм әсәрләрендә аерым бер карашны раслауга омтылмаган госманлы язучысын — төрекчеләр арасында кертүебез белән килешмәгән кешеләр дә булыр. Әмма телендә, өслүбе-стилендә, гамәлендә, иң тотрыклы төрекчелек күрсәткән, бу мәсләгендә ашыгусыз-сөртенүсез барган яңа заманның беренче госманлы язучысы Әхмәт Мидхәт әфәнде иде, дисәк тә, хата булмас. Милләтчелек дигән сүзнең эчтәлеге «халыкчанлык» (демократизм) дигән мәгънәне дә үз эченә ала. Язу һәм өслүб халыкчанлыгы ягыннан Әхмәт Мидхәт әфәнде белән ярыша алырлык нинди язучы бар? Моннан элек тә Әхмәт Мидхәт әфәнденең язуы һәм өслүбе төрекчелек сызыгында булганын әйткәнем бар: «Мидхәт, Кәмал иптәшләреннән дә аныграк, Европа мәдәниятен, соң гасыр Европа мәдәниятендә иң мөһим урыннарның берсен биләгән милләтчелек фикерен төгәл аңлады. Бу аңлату Мидхәтне халыкка, мохитебезнең тискәре мәгънәдәге бер тәгъбире белән әйткәндә, гавамга, тагын да дөресрәге, төрекчелеккә тартты. Бүгенге Европа мәдәниятенең рухы — гыйлем һәм мәгърифәтне, сәнгать һәм әдәбиятны халык милкенә әйләндерү (демократизацияләү). Әхмәт Мидхәт әфәнде шул рухка, шул нигезгә бөтен гомерен багышлады» [5]. Мидхәт әфәнденең, телдә халыкчанлыгы ягыннан, милләтчелек фикерен аңлау югарылыгына күтәрелүенә ышансак та, Танзимат заманында барлыгы яки барлыкка килү мөмкинлеге фараз ителгән Госманлы милләтчелегенең мәгънә эчтәлеге әле тиешле дәрәҗәгә ирешмәгән, Габделхәмид солтанлыгының башлангыч елларында әле үсү юлына кермәгәнендә дә шөбһәбез юк. Дөрестән дә, Мидхәт әфәнде үзенә шулкадәр дошманнар күбәйткән ки, инкыйлаб вакытында гына, Госманлы милләтчелегенең фикер иясе буларак, хыялындагы милләтчелек теориясен корырга тырышып карый. Мидхәт әфәнде карашынча, «Яңа Госманлы милләте» дигән бер милләт бар. «Госманлылык — гамәлдә хөкемдар булган патшага буйсынып, асыл сәясәткә кушылудан гыйбарәт. Кайсы диндәге кавемнән булсаң бул, моның һичнинди әһәмияте юк [6]. Әхмәт Мидхәт әфәнденең бу карашы, безнеңчә, Габделхәмит дәверенең урталарына кадәр дәвам итә. Шунда гына әфәнде сәясәттән исламчылык, төрекчелек фикеренә күчә. Әсәрләре төрек дөньясының төрле тарафларына таралган, күп укылган һәм төрек галәменең дүрт тарафыннан Истанбулга тартылган Әхмәт Мидхәт әфәнде «барлык төрекләрнең бердәмлеге» фикерен белмәгән, дигән караш белән килешә алмыйбыз. Фәкать, ул чакларындагы әсәрләреннән, бу турыдагы сүзләрне табу гына кыен. Билгеле факт: икенче грек сугышы алдыннан, ягъни 1896-1897 елларда, исемнәре ишетелә башлаган өченче дәвер төрекчелек хәрәкәте егетләренең Мидхәт әфәнде белән тюркология темалары буенча байтак фикер алышулары булды. Әфәнденең искәртүләре күпләрнең карашларын камиллеккә китерергә ярдәм итте, дип була.

Кыскасы, Мидхәт әфәнде, милләтчелек турында уйлана-уйлана, төрекчелек позициясенә килеп чыкты. Икенче мәшрүтият (Милләт мәҗлесе) революциясе (1908) һәм шуннан соңгы елларда илаһият (дин), сәясәт мәсьәләләре өлкәсендә тулысынча төрекчелек позициясендә тора иде.

Искәрмәләр:

1. Урта Азиядәге Амудәрья һәм Сырдәрья елгалары арасындагы үзәнлек.
2. Габделхәмид II (1842-1918) — Госманлы империясенең 1876-1909 елларда идарә иткән солтаны, хәлифе.
3. 1877-1878 еллардагы рус-төрек сугышы.
4. 1877-1878 еллардагы рус-төрек сугышы вакыйгалары.
5. Төрек йорты. — 3 җилд. — Б.170.
6. Мидхәт Ә. Үсс-и инкыйлаб. — Истанбул, 1294/1878. — Б.10-13.

Төрек теленнән
***Мәсгуд Гайнетдин** тәрҗемәсе* ■

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

КАУРЫЙ КАЛӘМ ӘЗЕННӘН*...

Диләрә Госманова

Укучылар игътибарына тәкъдим ителгән текст – Миркасыйм Габделәхәт улы Госмановның (1934-2010) 1963 елда археографик экспедициядә алып барган көндәлеге – галимнең күпкырлы фәнни эшчәнлеген анык тоемларга ярдәм итә. Ярты гасыр дәвамында – 1960 еллар уртасыннан вафатына кадәр – М.Г.Госманов тарафыннан күпсанлы фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр язылды, алар татар тарихы фәненең чыганаклар нигезен баетуда мөһим роль уйный, аерым тарихи темаларны, әдәбият белеме һәм татар мәдәнияте мәсьәләләрен өйрәнүгә зур өлеш кертте.

* Хезмәт Россия фундаменталь эзләнүләр фонды ярдәме белән әзерләнде (проект РФФИ № 13-06-97069-р поволжье «Восточная археография в России в XX столетии: проблемы комплектации, сохранения и изучения письменного наследия татарского народа»).

Галимнең мирасы, саннарга күчергәндә, мәкаләләрен һәм монографияләрен кертеп, берничә йөз хезмәттән тора. Язмыш М.Г.Госмановка үзен олпат галим буларак гына түгел, ә күренекле педагог-тәрбияче, җитәкче-администратор һәм оештыручы буларак та танытырга мөмкинлек бирде.

М.Г.Госмановның 1958 елда университеты белән дан алган һәм дөньядагы барлык татарларны үзенә тартып торучы Казан каласына килүе тирәннән аңлап эшләнгән гамәл була. Югары белем алу өчен Казан университетын сайлап, 24 яшьлек егет максатчан рәвештә үз халкының тарихын, әдәбиятын, мәдәни мирасын өйрәнергә керешә.

Башта Миркасыйм Госманов филолог булырга уйлый һәм Казан университетының тарих-филология факультетының татар филологиясе бүлегенә укырга керә. Әмма III курсны тәмамлагач, ул шул ук факультетның тарих бүлегенә күчә. Студент елларында ук фәнни эзләнүләрдә актив катнаша, фольклор, диалектология һәм археология экспедицияләренә йөри, Казанда нәшер ителүче газета-журналларда фәнни мәкаләләре дөнья күрә. 1963 елны, университетны уңышлы тәмамлагач, аны СССР тарихы кафедрасында аспирантурада калдыралар. М.Госманов 1968 елда «XVII – XVIII гасыр татар нарратив чыганаклары һәм аларның үзенчәлекләре» дигән темага кандидатлык диссертациясен тәгәлли һәм уңышлы яклый.

1963 елның язында, Казан университетының тарих факультетын тәмамлау көннәрендә, диплом җитәкчесе Шамил Фатыйх улы Мөхәммәдъяров белән әңгәмә барышында, махсус археографик экспедицияләр оештыру идеясе туа. Шиксез, бу фикер аңарчы да була, тарих-филология факультетында диалектологик, фольклор һ.б. студентлар экспедицияләре уздыру гамәлдә яши. Ләкин әлеге идеяне тормышка ашыру, аңа озын һәм уңышлы юл салу өчен, аерым факторларның әзерләнеп җитүе, бигрәк тә инициативалы һәм энергияле галимнәр булуы шарт иде.

2013 елның көзендә Казан университетының Археографик экспедициясе үзенең 50 еллык юбилеен билгеләп үтте. Аерым объектив сәбәпләр аркасында, бу вакыйга бик тыйнак рәвештә генә искә алынды. Шулай булса да, әлеге хәрәкәтнең ярты гасыр яшәве, шушы вакыт аралыгында гаять зур географик киңлекне: көнбатыштагы Рязаньнән һәм Касыймнан алып – көнчыгыштагы Иркутскига кадәр,

1963 елгы археографик экспедициядә катнашучылар. Габдрахман авылы. Сулдан: Миркасыйм Госманов, Ренарт Кашафетдинов, Шамил Мөхәммәдъяров (экспедиция җитәкчесе), авылда яшәүчеләр (уртада), Альберт Фәтхи, Хатип Госман. Мирфатыйх Зәкиев фотога тешерә.



М.Госманов үзенең шәкертләре белән. 1978 ел

төньяктагы Пермьнән — көньяктагы Әстерханга чаклы аралыкны, Россия Федерациясенең 5 автоном республикасында һәм 15 өлкәсендәге 900ләп татар авылын йөреп, тикшереп, өйрәнеп чыгуы күп нәрсә хакында сөйли. 50 еллык эзләнүләр чорында 10000 ләп кулъязма, басма китап һәм документлар табылган, Казанга алып кайтып университетның Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегенә (1992 елдан — бер өлеше Татарстан Республикасының Милли китапханәсенә дә) саклауга тапшырылган. Бу табышлар шәрык коллекциясен өч тапкырга арттырырга мөмкинлек бирә[1]. Шушы еллар арасында аспиранттан профессорга, Казан университеты җитәкчеләренең берсенә кадәрле хезмәт юлы узган (1985-1991 елларда ул уку-укыту эшләре буенча проректор вазифаларын башкара) Миркасыйм Госманов 1980 еллар ахырына кадәр археографик экспедициянең җитәкчесе (рәсми яктан 1965 елдан 1989 елга кадәр), кыр тикшеренүләренең үзәгендә кайнаучы була. 1990 еллар башыннан әлеге эшне, Татарстан Республикасының Милли китапханәсе белән берлектә, М.Г.Госмановның укучыларыннан берсе, КФУ доценты Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин дәвам итә.

РЕДАКЦИЯДӘН: Укучыларыбыз игътибарына тәкъдим ителгән текст Миркасыйм Госмановның иң беренче даими көндәлекләреннән алынды. Археографик экспедициянең җитәкчесе һәм тикшеренүчесе аларны 25 ел дәвамында алып барган. Бу көндәлек зур тарихи юлның башлангычын чагылдыра. Ул, башка документлар (отчетлар, аналитик күзәтүләр, хатирәләр һ.б.) белән янәшә, татар археографиясе тарихыннан мөһим чыганак булып та хезмәт итә. Аның белән без галимнең архивында сакланучы көндәлекләр сериясен башлап җибәрәбез. Көндәлекләрне басмага тарих фәннәре докторы, КФУ профессоры Диләрә Госманова әзерли. Текстны басма өчен әзерләгәндә күрсәткән ярдәмнәре өчен, ул Динә Мостафина һәм Ильяс Мөстәкыймовка рәхмәтен белдерә.

[1] Казан университетының археографик экспедициясе җитәкчесенең үзе тарафыннан экспедицияләр тарихы һәм аларның эшчәнлек нәтиҗәләре күп тапкыр яктыртыла. Аеруча билгеле хезмәтләрдән, шул исәптән өлешчә көндәлекләргә нигезләнеп язылган, 1984 һәм 1994 елларда ике тапкыр дөнья күргән «Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары» монографиясен күрсәтергә мөмкин.

Миркасыйм Госманов

Археографик көндәлек

(Казан университетының археографик экспедицияләре турында материаллар)

Беренче кисәк
(1963 – 1966 еллар)


Кереш

1963 елның яз айлары иде. Мин университетның V курсында, диплом проекты әзерлим.
Көннәрдән беркөнне җитәкчем Шамил абый Мөхәммәдъяров белән әңгәмәләшеп утырганда борынгы кульязмаларның начар өйрәнелүе, барланмавы хакында сүз чыкты. Җае килүгә мин халык кулындагы язма материалларның әле күп булуын әйттем, фикеремне 1961 елны Бараба татарлары арасында тапкан „Барабанамә" исемле тарихи кульязма һ.б. белән дәлилләдем (ул елны мин доцент Д.Г. Тумашева белән Бараба татарлары диалектын өйрәнү өчен барган идем. Шул елдан башлап мин татар бүлегеннән тарих бүлегенә күчеп, индивидуаль план буенча укый башладым). Шамил абыйның күзләре кинәт ялтырап китте:
– Әйдә, археографик экспедиция оештырабыз!!...

АРХЕОГРАФИК КӨНДӘЛЕК

Миркасыйм Госманов

(Казан университетының археографик экспедицияләр юлъязмасы)

БЕРЕНЧЕ КИСӘК (1963-1966 ЕЛЛАР)

Кереш

1963 елның яз айлары иде. Мин университетның V курсында, диплом проекты әзерлим. Көннәрдән беркөнне җитәкчем Шамил абый Мөхәммәдъяров белән әңгәмәләшеп утырганда, борынгы кулъязмаларның начар өйрәнелүе, барланмавы хакында сүз чыкты. Җае килүгә, мин халык кулындагы язма материалларның әле күп булуын әйттем, фикеремне 1961 елны Бараба татарлары арасында тапкан «Барабанамә» исемле тарихи кулъязма һ.б. белән дәлилләдем (ул елны мин доцент Д.Г. Тумашева белән Бараба татарлары диалектын өйрәнү өчен барган идем. Шул елдан башлап мин татар бүлегеннән тарих бүлегенә күчеп, индивидуаль план буенча укый башладым). Шамил абыйның күзләре кинәт ялтырап китте:

— Әйдә, археографик экспедиция оештырабыз!!!...

— Мөмкинме ул? — дидем, кыюланып.

Дөресен әйткәндә, ул вакытта безнең университеттан махсус археографик экспедиция оештырып була, дигән уй бер дә башыма килмәгән иде (әлек, диалектологик һәм археологик экспедицияләргә катнашканда, махсус таныклык алып, халыктан кулъязмалар сорап йөрүне дә зур казаныш дип исәпли идем).

Шунда ук фикердән гамәлгә күчтек: план, маршрут һәм состав турында конкрет сөйләшә башладык.

Маршрут мәсьәләсендә инициативаны мин алдым. Диплом эшем Исмәгыйль Бикмөхәммәтов әсәренә багышланган булгач, Оренбург Каргалысына барып, шуңа мөнәсәбәтле яңа документлар табып булмасмы, дигән хыял бар иде миндә. Шуңа күрә, беренче сәфәрне Оренбург өлкәсенә оештырырга тәкъдим иттем. Килештек. Экспедиция составы турында сөйләшәбез. Төп көч СССР тарихы кафедрасы әгъзалары булачак, шулай ук татар бүлегеннән берничә студент алачакбыз. Бу фикер белән мин татар кафедраларының (тел һәм әдәбият) мөдирләре Хатип ага Госман һәм Мирфатыйх абый Зәкиевләргә кердем: «Шамил Мөхәммәдъяров җитәкчелегендә шундый экспедиция оештырылачак, сезнең студентлар катнашса, шәп булыр иде...», — дим. Көтмәгәндә, күптән түгел генә докторлык диссертацияләрен яклаган Х.Госман да, М.Зәкиев тә үзләре барырга теләүләрен белдерделәр. Ярар. Кабул иттек. Менә шулай итеп, экспедициябез саф археографиктан чыгып, комплекслы кыяфәт алды. Һәм аны шулай таныдык та. Докторлар һәм доцентлар катнаша торган булгач, студентларны алмаска булдык (дөрес, мин әлегә студент-дипломник, ләкин уку бетүгә мин университетта калырга тиеш: я ассистент, яки гыйльми хезмәткәр булып, ә экспедиция көзен генә булачак...).

Хәзер башка баручыларны да билгеләргә кирәк. Ләкин бу проблема түгел. Шулай итеп, археографик экспедиция идеясе гамәлгә аша башлады. Смета төзелде, состав билгеләнде, маршрут ачыкланды. Алар расланды, приказ чыкты (әлбәттә, миңа бик күп йөрергә туры килде... Ә дипломны язып бетерергә кирәк...).

Френ, Хәлфин, Сәет Вахидиләр чорыннан соң сүнеп торган археографик эзләнүләр, кулъязмалар җыю эше, менә шулай итеп, яңадан торгызылды. Күрәсез, бу башлангычның беренче көннәреннән алып, мин аны тормышка ашыруда катнашам. Икенчеләй әйткәндә, мин бу кызыклы һәм перспективалы экспедицияләрнең тарихын үзем ясаштым...

Башта, югарыда әйткәнемчә, бөтен инициативаны (әгәр минем элегрәк аерым эзләнүләрне исәпкә алмаганда) Ш.Мөхәммәдъяров күрсәтте. Ул бу идеягә җан бирде, аны тудырды, исем кушып, законлаштырды. Ә менә үстереп, аңа озын гомер тәэмин итүдә бөтен авырлык һәм җиңеллек минем җилкәгә төште. Дөресен әйткәндә, икенче елдан ук безнең олы агайлар читкә тайпылып, экспедицияне фактик җитәкләү миңа калды. Өченче елдан исә, мин юридик яктан да бу эшнең җитәкчесе итеп билгеләндем. Дүртенче елны исә, «җитәкче» дә, «башкаручы» да үзем булдым. Менә шуның өчен дә 1967 елны, диссертациямне тәмамлау елы булып, мин ычкына алмагач, экспедиция дә оештырылмады...

«Мин», «мин» дип язудан үземнең экспедиция тууда, яшәүдә булган үз ролемне күрсәтүдән бигрәк, аның киләчәге өчен никадәр җаваплы булуыма да игътибар юнәлтәм. Әйе, яхшы башлангычны үстереп җибәрү, аны гомерле итү хәзер миңа бик нык бәйләнгән (башка «белгеч» юк бит...). Димәк, мин үз өстемә зур бурычлар алам һәм мин җаваплы.

Хәзер, ягъни 1968 елның башында, кафедралар арасында оешкан проблематик группаның эш планын раслау уңаеннан, археографик экспедициянең киләчәк эш планын төзү мөһимләште. Аны тагы да законлаштырып, аңа киләчәк гомер тәэмин итәргә кирәк. (Берәүләр аның булмавын телиләр дә бит...) Шуның өчен бу көннәрдә мин алдагы 5 ел археографик эзләнүләрнең эш планын төзеп бирдем. Шул уңай белән үземнең элекке язмаларыма күз салган идем — тәҗрибәнең шактый булуын аңладым.

Чыннан да, узган дүрт елда (1967 елны исәпләмим) безгә, бигрәк тә миңа, 6-7 сәфәрдә булырга, бик күп төбәкләргә барып кайтырга туры килгән (аларны аерым-аерым санап тормыйм — түбәндә һәрбер сәфәрнең көндәлеге булачак). Шул эзләнүләр нәтиҗәсендә йөзләгән-йөзләгән кулъязмалар табылган. Алар арасында дистәләгән «сирәкләре» дә, аерым-аерым «уникум»нары да бар. Халык арасында

ничек эшләргә дигән тәҗрибә дә шактый. Хәзер инде кем белән ничегрәк сөйләшергә кирәклеген тиз шәйлим (бик авыр эш бу әбиләрдән-бабайлардан «изге» әйберләрен йолып алу!).

Киләчәккә планнар төзү белән үз язмаларымны күздән кичергәндә, нигә соң боларны акка күчереп куймаска, дигән фикергә килдем. Чыннан да, нигә күчермәскә? Каралама язмалар бит киләчәктә үземә эшләр өчен дә җайсыз. Ә бу язмаларның, заманалар узгач, икенче максатлар өчен дә ярап куюлары бар. Ярар, хәл ителде. Күчерәм. Гади, кыска көндәлек рәвешендә. Ягъни бу әдәби мемуар да, гыйльми отчёт та түгел. Бары үз көндәлегемдә чүп-чардан аруландырылган язмаларның шәкеле генә.

Инде алдагы планнар турында.

Моңарчы гел Татарстаннан тыш өлкә һәм районнарда эзләнгән булсак, хәзер ике юнәлештә эшләргә тиешбез. Һәр ел саен ике-өч сәфәр булырга тиеш: берсе — Татарстанда, икенчесе — чит өлкәләрдә. Татарстанда быел июль аенда, Тау ягыннан (Буа, Тәтеш, Апас районнары) башларбыз. «Читкә» исә, көзен Әстерхан өлкәсенә барып кайтырмын (бәлки бер үзем генә). Максат: якындагы 5-10 елда бөтен Татарстанны «айкап» чыгу белән бергә параллель рәвештә башка өлкәләрдәге татар төбәкләрен дә «барлап» чыгу.

Менә шулай. Хыял зурдан. Нәтиҗәсе ничек булыр? Моны һәр елгы көндәлекләр яктыртыр. Ә хәзергә узган «бишьеллыкка» күчик. Ул — киләчәкнең аерылгысыз өлеше.

М. Госманов. 25.II.1968 ел.

P.S. Башка экспедицияләр (археографик булмаган) турындагы кыскача көндәлек 1966 елгы соңгы сәфәрдән соң бирелер. Өстәмә рәвештә.

....

I СӘФӘР. ОРЕНБУРГ ӨЛКӘСЕ, КӨНЬЯК БАШКОРТСТАН 10.09.-30.09.1963 ЕЛ

10.09.63. Төштән соңгы сәгать дүрттә университеттан алган үз машинабыз белән юлга чыктык.

Мәшәкатьле әзерләнү чоры шулай итеп артта калды. Ул чор минем өчен бигрәк тә мәшәкатьле булган иде. Экспедициягә иң кечкенә дәрәҗәле шәхес булганга да, идея авторларының берсе булганга да, бөтен әзерлек эшләре миңа йөкләнгән иде. Хәерле булсын. Хәзер артта инде ул мәшәкатьләр.

Состав: Шамил Мөхәммәдъяров (җитәкче), Хатип Госман, Мирфатыйх Зәкиев (өчесе өч кафедра җитәкчесе!), Ренарт Кашафетдинов (этнограф), Альберт Фәтхи (китапханә), шофёр Фуат һәм мин. 7 кеше. Дөрес, Шамил абый артта калды. Самолёт белән Бөгелмәгә барырмын, дип. Бер эше бетмәгән булган.

Кузовта барабыз. Такы-тыкы. Фанера фургон. Такта урындыклар. Баллон. Шофёр Фуат үзенең туганын утыртып алган (әби һәм кызый). Кичен Чистай районы Кыр Шынталасы авылына барып, үзебез «блат» — юлдаш әбиләрдә кундык. Әйбәт кенә кунак иттеләр. Йокларга чоланга яттык. Тик... кандала!!! Хатип ага торып качты...

....

11.09.63. Иртүк берничә карткорыга кереп чыктык. Беренче табыш: «Мәймүнәбану» дигән әсәрнең төрки тәрҗемәсе. Шулай итеп «бисмилла» бар.

Чистай, Әлмәт шәһәрләрен узып, Бөгелмәгә юнәлдек. Бөгелмәгә җитәрәк, машина ватылды. Шәһәргә көчкә җиттек. Шамил абый да килеп җиткән булган. Гостиницага урнаштык. «Нефтяник» дип атала.

....

12.09.63. Редакциягә киттек. Юлдан мәктәпләргә кердек (Шамил абый ма-

шинаны ремонтлау хәстәренә керешеп калды. Хатип ага үзенең шәкертләрен тапты — редакция сотруднигы Дамир Зарипов). Редакция машинасы белән Хатип ага, Мирфатыйх абый һәм мин Бәйрәкә авылына киттек. Юлда М.Зәкиевнең туган авылында туктап, аның әнисенә кереп, чәй эчеп чыктык. Урман эчендәге кечкенә генә салам түбәле бер авыл кисәге. Җиргә иңгән иске генә агач йорт. Уйга батам: күрәсең, татарларның барлык эшлеклеләре дә шундый салам түбә астында туып, ташландык авылда үскән, аннары тырмашып адәм булган.

Бәйрәкәдә Кәшиф Рәхимов дигән кешегә килеп төштек. Элек язып-сызып йөргән, аннары 30 нчы елларда «хаҗга» китеп, 20 елга якын «сәяхәт» итеп кайткан. Шулай да сәламәт сакланган, бик тере карт. Бакчачылык белән шөгыльләнә. Мавыгып. Төрле сорт җиләк-җимеш агачлары…

Аңардан Әпсәләм авылындагы шифер заводында яндырылган яки эреткән кәгазьләр арасыннан (утиль) гарәпчә язулы кагәзьләр булуын дә беләбез. Димәк, үлем китапларны икенче урында да бик оста сагалый…

Кәшиф аганың чормасына мендек, биш алты кулъязма (шулардан шактый борынгы татарча фикъһе әсәре дә бар). Басма китаплардан А.Болдыревның «Арабская хрестоматия»се (К.Насыйри автографы белән); Ш.Сами «Лөгат»е.

....

13.09.63. Кичә көне буе чапкалап, Шамил абый машинаны ремонтлаткан. Ул әллә кайлардан үзенең начальник дусларын табып, шулар аша бер атналык ремонтны бер көндә бетерткән. Фуат хәйран калган. Ул кичә: «Бөгелмәдә бик озак саргаербыз», дигән иде. Һәрхәлдә, Шамил абый үзенең «пробивной»лыгын беренче мәртәбә күрсәтте.

Оренбург ягына юнәлдек. Шалты авылын узып, Габдрахман авылына килдек. Ул Ык буенда урнашкан. Җәй айларында бик матур булырга тиеш. Ә хәзер көз.

Авыл халкының төбе Пенза губернасы Краснослободский өязеннән моннан якынча 140-150 еллар элек күчеп килгән. Башка яктан күчеп килүчеләр дә булган икән…

Без Рим Кәримовның аталарында туктаган идек.

Кичен Ык буена барып юындык (тузаннарны юдык), көн салкын булса да, анадан тума чишенеп Ыкка чумдык. Бер Альберт кына кулын да суга чылатмады: ул гомумән судан курка…

....

14.09.63. Иртә торып, Хисмәтулла Төхфәтуллин дигән кешене эзләп Тегермәнгә киттек. Җырлаттык, сөйләттек. Бер кечкенә җырлар дәфтәрен алдык. Гражданнар сугышы чорында язылган яисә русчадан тәрҗемә ителгән җырлар. Ярыйсылары да очрап куя.

Шул ук көнне Габдрахман авылыннан 18 км көньяктагы Чыгәнле авылына килдек.

Авыл моннан бер йөз ел элек салынган. Төрле халык. Пенза губернасы, Ләмберә авылыннан килүчеләр бар.

Мәкальләр, әйтемнәр:

«Эшләмәк кеше орып ала».

«Эшләп алган — орып алган».

«Бездән уңга да юк, сулга да юк» (ягъни искечә дә, яңача да белмибез).

[…] әллә нәрсә табылмаса да, ике кич кундык. Дөрес, Кандалый әсәрләреннән бер кечкенә күчермә таптык…

....

16.09.63. Юлда Муса Җәлил туган Мостафа авылында бер туктап, бөек шагыйрь туган ташландык авылны күздән кичереп, әкәмәт кенә һәйкәл (бюст) янында рәсемгә төшеп, Оренбургка килдек. 304 км узып. Юл бик әшәке иде. Ташландык авыл, һәйкәл озак күз алдыннан китмәде. Бәлки бу символдыр? Безнең олы кешеләрне ничек хөрмәтләвебезне күрсәтәдер ул?

Гостиницада урын юк иде. Шулай да Шамил кызларны сихерли торгач, ике кешелек бер бүлмә алды. Хатип белән урнаштылар. Калганнарыбыз көтүебез белән «Колхозниклар йорты»на барып, бер зур бүлмәгә урнаштык. 16 кровать-

лык салкын абзар. Бер койкада исерек экспедитор (колхоздан) сүгенеп ята, икенче кроватьта филология фәннәре докторы М.Зәкиев ял итә.

Ләкин юлдагы салкыннан соң, кайнар душ бик шәп булды.

....

17.09.63. Төрлебез төрле якка сибелдек.

Мин архивка бардым. Описьларны карап, борынгырак дәвер документларының тасвирламалары белән танышып бер көн утырдым. Бай гына. Махсус килергә кирәк. Татарларның Һиндстанга сәяхәтләре турында да документлар бар сыман. Әйе, махсус килергә кирәк!

Ә Шамил абый белән Ренарт юкка чыкты. Кунарга кайтмадылар.

....

18.09.63. Иртә торып, Каргалыга киттек. Элекке татар байларыннан калган таш кибетләр, тимер ишекле амбарлар, зур йортлар... Ләкин хәзер Каргалы — карга оясы!.. Нәкъ Гитлер узып киткән кебек. Кешеләре дә чырайсыз, чытык йөзлеләр, йомыклар. Җүнләп исәнләшә дә белмиләр.

Мәктәптә булдык. Русча гына укыталар. Ләкин укытучылар үзләре дә җүнләп русча белми икән. Менә шул укытучылар үзләре русча өйрәнсен өчен «Дежурные слова» дигән бер такта элеп куйганнар. Һәркөнне берничә сүз ятларга тиеш икән алар. Ярар, ятласыннар. Ә укучылар? «Наданнар», диде берсе туп-туры.

Гали Ибраһимов дигән бабайда булып, берничә кулъязма кисәге алдык. Кәримә апа дигән бер карчыкка кердек. Ул шагыйрь Һибәтулла Салихов нәселеннән икән. Фамилиясе Саетбатталова.

Шәҗәрәсе: Кәримә — Әхмәтҗәмил — Һибәтулла (шагыйрь) — Сәетбаттал — Салих — Бикмөхәммәт — Ишмөхәммәт...

Көн бик салкын, караңгы чырайлы, гомумән, әшәке иде.

Ашханәсенә кереп чиле-пешле пәрәмәчләр, дуңгыз итеннән гуляш ашап чыктык. Көннең икенче яртысы. Мостафа абзый Әхмәтовта булдык. Күңелле генә кеше. Утыз елдан бирле яза килгән көндәлеге бар икән. Безгә соңгы бүлеген укыды. Надан гына булса да, зәвыклы һәм тырыш кеше булуы күренә.

Зиратта булдык. Ташландык. Мәгәр элек бик тәртипле булган... Мәетләрнең рухлары кебек ташлар тезелешеп тора, гүяки таш урманы... Зираттагы ташлардан кайберләрен кире кайтышлый күчереп алырга булдык.

Эләккән кулъязмалар арасында Сәгъди «Гөлестан»ының бер күчермәсе бар. Әһәмиятсез бәетләр да очрый.

Кичен утырып ләчтит сатабыз (Оренбургта, әлбәттә). Хатип Госман да, М.Зәкиев тә үзләренең эрелекләрен җуя бара, гади кешегә әверелә... Ә менә Альбертның кирелеге һаман арта.

Ә Шамил белән Ренарт бүген дә кайтмады... Олактылар...

....

19.09.63. Көне буе архивта булдым. Тасвирламалар белән киңрәк таныштым. Әйе, махсус килергә кирәк.

Х.Госман, М.Зәкиев, Альбертлар да халык белән аралашып йөргән. Кешеләр белән танышканнар. Көндезен Шамил белән Ренарт кайтып төште: алар Шамилнең бер балалык дустын табып (полковник), шуңа кунакка дип, сахрадагы хәрби частька барып кунган. Тагын әллә кемнәргә барып чыкканнар... Ә көндезен Шамил Обкомга, Облисполкомга барды, машинабызның «утырган» аккумуляторы урынына яңаны тапты. Түләүсез-нисез. Могҗиза! Бер дә белмәгән кешедән суырып алган. Шулай итеп, кузгалып китәрдән элек, «Дубинушка»ны җырлап, машинаны этеп йөрү бәласеннән котылдык. Юкса, соңгы ике көнне, туктаган саен машина этеп җәфаланган идек...

....

20.09.63. Урал (Җаек) суы буйлап казачий татарларның авылларын эзләп киттек. Очсыз-кырыйсыз киң сахра, зур басулар... Юл төрлечә.

Иң элек Зубачий дигән авылга килдек. Моннан 200-220 еллар элек салы-

на башланган, дип әйтәләр. Тарихын җүнләп белгән кеше юк. Халкы бик үк аңлы түгел. Элек бик караңгы булган булырга охшый. Пугачёв «дер» селкетеп йөргән җирләр. Әмма халыкта риваятьләр начар сакланган.

Бер тел бистәсе хатынның сафсатасын тыңлап, озак кына утырдык. Имештер, Урта Азиядә Совет властен урнаштырган... Гел сүгенеп сөйли торган бер бабайны да сөйләтеп утырдык. Магнитофонга язып утырган чакта да тозлап-борычлап берне ычкындырды... «Бөтен язу бозылды, бу ахмак аркасында», дип М.Зәкиев тә сүгенеп тора...

Шул ук көнне, кичен, Чесноковка авылына килеп, Пугачёв исемендәге колхозның рәисе Хәмит Бакировның өенә төштек. Кунып калдык.

....

21.09.63. Чесноковка авылын арлы-бирле йөрдек. Мәгънәле бернәрсә дә чыкмады. Имештер, кемдер, кайчандыр авыл тарихын язган. Кем, кайчан? Беркем дә белми....

Төшлектән соң Нижние Озёры авылына юнәлдек. Бу авылда да рәт чыкмады. Бары бер генә гарәпчә кульязма.

«Киров» исемендәге бик бай колхоз. Зур-зур биналар, клубы ни тора, ә мәктәбе! Миллионер булуы кычкырып тора.

Кичен концерт икән. Һәй бина! Авыл мәктәбе дип әйтмәссең... Шәп!

Концерттан соң Х.Госман укучыларга нотык сөйләп алды.

Директор белән аның бүлмәсендә әңгәмәләшәбез. Мәктәп агония һәм газап белән тел алыштыра икән. Директор аптырап кына утыра: хәзер ике телне дә белмиләр...

Ике көннән бирле Хатип аганың эче китә (Оренбургта ук башланган булган). Кәефе дә бик начар. Вакыт-вакыт «олактык, егетләр», дип көрсенә. Без елмаеп кына куябыз. Хосусән, минем өчен юл әле генә башланды сыман. Әмма олы агайлар кайту турында ешрак сөйли...

22.09.63. Халык чөгендер җыю белән мәш килә. Кышка әзерләнә икән. Без бүген генә үзебезнең кая килеп эләгүебезне чып-чынлап аңладык кебек: әнә Казакъстан чиге! Я шуннан Хатип ага тагы да «олактык, егетләр», дип куя. Бүген аның эче бераз рәтләнә кебек. Ләкин телендә әледән-әле Казан...

Халык телендә казакъ элементы бик көчле. Өч сүзнең берсе казакъча диярлек. Шулай да атаклы телчебез М.Зәкиев һаман гаҗәпләнә: «Карале, болар да безгә бик аңлаешлы телдә сөйләшәләр бит!». Әйтерсең лә Татарстаннан читтәге татарлар башка телдә сөйләшергә тиешләр! (Ул Оренбург өлкәсенә чыкканнан бирле шулай шаклар катып йөри — һай мохитнең тарлыгына күнегү).

Авыл, кайбер кара исәпкә караганда, XIX гасыр башында, кайберәүләрнең әйтүенә караганда, 1811 елда салынган булган. Чик саклаучы казачий татарлар нигезләгән. Ә соңгылары исә төрле җирдән, дар астыннан качучылар. Атаманнар, гадәттә, руслардан булган, алар ярлы хәлдә килеп, баегач, китә торган булган.

Авылда элек укымышлылар да, язма китаплар да, имеш, күп булган, тик беренчеләре үлеп, икенчеләре янып беткән. Бигрәктә 20-30 елларда. Җиргә күмү, утильгә бирү очраклары соңгы елларга хәтле дәвам иткән.

Монда моннан берничә ел элек Хәләф Гарданов булып кайткан иде. Ул миңа бу тирәләрдә фольклорның ярлы булуын сөйләгән иде. Дөрес булып чыкты!

Безнең иң ерак пунктыбыз шушы Озёрки булды. Кире борылдык. Юл әшәке, көн бик салкын иде. Бик туңдык. Кичке 8дә Оренбургка кайтып җиттек. Мунчага киттек, каткан сөякләрне җылытырга дип. Бары Альберт кына өйдә калды. «Юк, бармыйм мунчагызга». Мирфатыйх юл буена сүгенеп барды: «Әлла аны көчләп юындырасы?!!!»

Куну әлеге дә баягы «Колхозниклар йорты»нда булды.

Дәвамы бар ■

Миркасыйм!

Ләбиб Лерон

(Миркасыйм ага Госманов ядкяре)

Сине безгә Ходай җибәргәндер...
Әзһәр Шакиров

Сине безгә Ходай җибәргәндер...
Һәм әйткәндер:
 — Яшә, Миркасыйм!
Мисыр... Иран... Алман илләренең...
Америка... Мажар җирләренең
Син күрергә тиеш һәркайсын!..
Татарстан дигән илеңнең дә —
Мескен түгеллеген — телеңнең дә...
Син белергә тиеш... Башкаларга
Сеңдерергә тиеш... Миркасыйм!..
Син белергә тиеш...

Сине безгә Ходай җибәргәндер...
Һәм әйткәндер:
 — Укы, Миркасыйм!
Латин... Гарәп... Урыс язуы да...
Энә белән кое казуың да...
Кирәк булыр сиңа... һәркайсы!..
Тукай, Такташ, Кәрим Тинчуриннар
Ишек кагар сиңа — төн чорыннан...
Кирәк булыр сиңа... Исхакыйлар
Терәк булыр сиңа... Миркасыйм!..
Кирәк булыр сиңа...

Сине безгә Ходай җибәргәндер...
Һәм әйткәндер:
 — Яз син, Миркасыйм!
Кол Галине, Кандалыйны... калкыт,
Мәрҗанине, Атласины... балкыт...
Яктырт, әйдә, татар дөньясын!
Кай милләтнең күңеле тарлыгын да...
Киләчәккә өмет барлыгын да...
Син әйтергә тиеш... Мөнбәрләрдән
Сүз әйтергә тиеш... Миркасыйм!..
Син әйтергә тиеш...

Сине безгә Ходай җибәргәндер...
Һәм әйткәндер:
 — Сызлан, Миркасыйм!
Дәште-Кыпчак... Болгар...
Алтын Урда...
Шәһре Казан... газап ялкынында...
Нинди булыр Татар иртәсе?..
...Тетрәндереп шулчак... Сискәндереп...
Әрнү-сыкрауларны хискә төреп...
Син җырларга тиеш... Шул чорларны
Син зурларга тиеш... Миркасыйм!..
Син җырларга тиеш...

Сине безгә Ходай җибәргәндер...
Һәм әйткәндер:
 — Казын, Миркасыйм!
Утта янмый калган кулъязмалар...
Хут алалмый ята елъязмалар
Узалмыйча чорлар киртәсен...
Килеп тапканыңны көтә булыр...
Синең юлда күпме киртә булыр...
Син барырга тиеш... Үткәннәргә
Юл ярырга тиеш... Миркасыйм!..
Син барырга тиеш...

Сине безгә Ходай җибәргәндер...
Һәм әйткәндер:
 — Көрәш, Миркасыйм!
Бар кыйтгадан барлап татарларны...
Бер икәнен әйтеп ватаннары...
Син якларга тиеш һәркайсын!
Мөһаҗирләр... Кытай Төркестаны...
Хәтереңә мәңге беркет аны...
Син яуларга тиеш... Ирек, хокук
Син дауларга тиеш... Миркасыйм!
Син яуларга тиеш...

Сине безгә Ходай җибәргәндер...
Һәм әйткәндер:
 — Яшә, Миркасыйм!
Һичбер кызганмыйча үз җаныңны...
Байрак итеп намус-вөҗданыңны...
Туздыр, әйдә, дошман фиркасен!
Гомрең буе халкың хакын хаклап,
Син яшәдең — Татар телен саклап...
Син яшисең һаман... Йөрәкләрдә
Син яшьнисең һаман... Миркасыйм!..
Син яшисең һаман...

27 гыйнвар, 2013 ел

ЯЗМА МИРАСНЫ БАРЛАУ ЮЛЫНДА

2013 елның 25 ноябрендә редакциябез, Казан дәүләт университеты профессоры Миркасыйм Госманов (1934-2010) җитәкчелегендә археографик экспедицияләр оештырыла башлауга 50 ел тулу уңаеннан, татар археографиясе мәсьәләләренә багышланган «түгәрәк өстәл» оештырды. Чарада тарих фәннәре кандидаты, КФУ доценты Җәүдәт МИҢНУЛЛИН, филология фәннәре докторы, ТР ФАнең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире Рәмил ИСЛАМОВ, ТР Мәдәният министрлыгы каршындагы Традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Зәлия БРУСЬКО, ТР Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат ЗАҺИДУЛЛИН, ТР Милли китапханәсенең фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Раиф МӘРДАНОВ, журналның бүлек мөхәррире, тарих фәннәре докторы Илдус ЗАҺИДУЛЛИН катнашты.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН:

— Россиядә археография фәненең традицияләрен үстерүгә Казан император университетының Көнчыгышны өйрәнүче галимнәре зур өлеш керткән. Алар, аерым кешеләрдән үз хисапларына яки университет хисабына сатып алган кулъязмаларны бастырып, Алтын Урда һәм аннан соңгы төрки-татар тарихына караган мәгълүматларны баеткан. Революциягә кадәрге төрки-татар мирасын өйрәнү, барлау, җыю, бастыру өлкәсендә иң зур казанышлар дип бүген, XXI гасыр биеклегеннән караганда, нинди гамәлләрне, кайсы галимнәрнең хезмәтләрен әйтергә мөмкин?

Җәүдәт МИҢНУЛЛИН:

— Татар кулъязмаларын гыйльми яктан өйрәнү һәм җыюның якынча 200 еллык тарихы бар. Күп шәхесләр бу мөһим эшкә бөтен гомерләрен багышлады. Кайберләре шушы игелекле гамәлләре өчен хәтта төрмәләргә ябылды, үлемгә дә хөкем ителде.

Татар кулъязмаларын гыйльми яктан өйрәнүгә һәм бастырып чыгару эшенә, беренчеләрдән булып, күренекле

татар педагогы Ибраһим Хәлфин (1778-1829) керешә, ягъни ул татар археографиясенә нигез салган галим. 1822 елда ул иске кулъязма нигезендә, «Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» дигән китапны гыйльми һәм педагогик максатларны күздә тотып, бастырып чыгара. Бу — кулъязмалар нигезендә, татарча нәшер ителгән беренче басма.

Казан университеты Гыйльми китапханәсендә җыела башлаган шәрык һәм татар кулъязмалары коллекциясенә дә Хәлфиннең шәхси китапханәсеннән күчкән китаплар нигез салган, дип әйтергә була.

Казан университеты профессоры, соңыннан Санкт-Петербург Фәннәр Академиясе академигы Христиан Мартин Френ (1782-1851) да татар кулъязмаларын бастыру өлкәсендә мәгълүм эш башкара. 1816 елда Венада ул немец телендә чыгучы «Фундгрубен дес Ориентс» («Шәрык хәзинәләре») исемле еллык җыентыкта «Дәфтәре Чыңгызнамә»дән бер өзекне латинчага тәрҗемә итеп бастыра. Моннан тыш, Хәлфин, Френ һәм атаклы австрияле галим Йосиф Һаммер, бергәләшеп, Тимер Котлуг ханның уйгыр хәрефләре белән язылган ярлыгын да нәшер итә. Шулай итеп тюркология фәнендә ярлыкларны өйрәнә торган махсус бер тармак — төркичә дипломатика белеменә нигез дә Казан университетында салынган.

Хәлфин белән Френның археография өлкәсендәге хезмәттәшлеге Френ Петербургка күчкәч тә дәвам итә.Университет галимнәреннән күренекле профессорлар Карл Фукс (1776-1846), Мирза Александр Казем-бек (1802-1870), Илья Николаевич Березин (1818-1896) да татарча кулъязмаларны җыю һәм өйрәнү белән шөгыльләнә.

1855 елда Казан университетының Шәрык бүлеге (Восточный разряд) Петербургка күчерелгәч, татар кулъязмаларын өйрәнү эше бераз сүрелә, җыелган кулъязмаларның да күпчелеген башкалага алып китә.

XIX йөзнең икенче яртысында Казан университетында кулъязмалар җыю эше белән күпмедер дәрәҗәдә гыйльми китапханә мөдире Иосиф Фёдорович Готвальд (1813-1897) шөгыльләнә. 1849 елда ул университетның гарәп һәм фарсы телләре кафедрасына профессор итеп чакырыла, 1850 елда китапханә мөдире итеп билгеләнә, цензор да була, тасвирламалар төзи. Вафатыннан соң, кызы әтисенең 10 тартмага тутырылган китапларын университетка тапшыра. Университет китапханәсендә көнчыгыш кулъязмаларын җыю һәм саклау эше бөтенләй юкка чыкмауга без иң элек Готвальдка бурычлы.

Татар кулъязмаларын җыю, тикшерү эше белән биредә соңрак Николай Фёдорович Катанов та (1862-1922) шөгыльләнә. Ул көнчыгыш китаплары цензоры булып та эшли. Галим озак еллар буе «Деятель» журналында «Восточная библиография» рубрикасын алып бара, басылып чыккан бик күп китапларга күзәтү-рецензияләр бастыра. Катанов төрле көнчыгыш телләрдә язылган кулъязма һәм басма китаплардан торган бай шәхси китапханә туплый. Әмма, кызганыч ки, бу китапханә Төркиягә китә. Язучы Муса Акъегетзадә үз вакытында бу китапханәне тәртипкә салу белән шөгыльләнә.

XIX йөзнең икенче яртысы XX йөз башларында язма мирасыбызны җыю һәм өйрәнү белән атаклы галимнәребез Ш.Мәрҗани (1818-1889), К.Насыйри (1825-1902), Х.Фәезханов (1828-1866), Р.Фәхреддин (1858-1936) шөгыльләнә. Кыскасы, татар археографиясенең бай традицияләре бар.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН:

— Совет хакимиятенең беренче унунбиш елында ТАССР археография өлкәсендә шактый уңышларга ирешә. 1921 елда Мәгариф халык комиссариаты каршында Академүзәк оештырыла. Шул ук елны Казанда Көнчыгыш академиясе оештырыла, аның каршында «Көнчыгышны өйрәнүче фәнни үзәк» ачыла. Ул ике елдан «Татарны өйрәнүче фәнни үзәк» итеп үзгәртелә. Татар һәм рус галимнәреннән торган идарә бул-

дырыла. Оешма үзалдына дүрт бурыч куя: 1) тарихи материаллар нигезендә татар халкы тарихын эшләү; 2) ТАССР районнарында кулъзма мирасны җыю; 3) татарлар тарихына бәйле архив чыганакларын өйрәнү; 4) археологик ядкярләрне өйрәнеп, картасын төзү.

Бу җәмгыять составында 1925-1928 елларда Төбәкне өйрәнү үзәге уңышлы эшләп килә. Нәкъ менә шушы Үзәк нигезендә 1929 елда «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте» оештырыла.

Җәүдәт МИҢНУЛЛИН:

— Чыннан да, узган гасырның 20-30 нчы елларында Татарстанда киң масштабта археографик тикшеренүләр алып барыла. «Татарны өйрәнү җәмгыяте» һәм «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте» кулъязмалар туплауны иң нәтиҗәле ысул — экспедицияләр уздыру юлы белән алып бара. Асылда, Татарстанның көнчыгыш төбәкләре тикшерелә.

Шулай ук Ленинградтагы Көнчыгышны өйрәнү институты һәм Тарих-археография институты тарафыннан 1934 елда Татарстанда оештырылган археографик экспедиция хакында да әйтеп үтәргә кирәк. Элеккеге СССР территориясендә көнчыгыш кулъязмаларын туплау өлкәсендә иң зур уңышларга ирешкән бу гыйльми сәфәр нәтиҗәсендә, Казанда һәм Татарстанның төньяк-көнбатыш районнарында 1200 кулъязма, 1000нән артык документ һәм 1859 басма китап җыела. Хәзерге вакытта алар Санкт-Петербургта Көнчыгыш кулъязмалары институты фондларында саклана һәм, кызганыч ки, әлегә кадәр тасвирланып бетмәгән. Әлеге экспедициянең уңышы Вәли Зәбиров һәм Сәет Вахиди кебек мәшһүр археографларның фидакярләрчә эшчәнлегеннән башка мөмкин булмас иде. Бу елларда С.Вахиди тарафыннан табылып, фәнни хәрәкәткә кертеп җибәрелгән 1523 елгы Сәхиб-Гәрәй хан ярлыгын искә төшерергә кирәк, әлбәттә. Әмма, 30 нчы елларның икенче яртысыннан башлап, 60 нчы елларга кадәр планлы рәвештә әлеге тикшеренүләр тукталып кала. Бу елларда археографик эшчәнлек белән шөгыльләнгән С.Вахиди, В.Зәбиров, Г.Гобәйдуллин, Гали Рәхим, К.Сәгыйть, Ф.Туйкиннарның шәхес культы корбаннары булуын һәрвакытта истә тотарга тиешбез.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН:

— Без редакциягә соңгы ике дистә елда археографик (яки комплекслы) экспедицияләр оештыручы, кулъязма мирасны саклау, өйрәнү белән шөгыльләнүче фәнни оешма вәкилләрен чакырдык. Рәмил әфәнде, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының бу өлкәдә нинди уңышлары бар?

Рәмил ИСЛАМОВ:

— Кулъязма мирасны максатчан планлы рәвештә җыйнау ТАССР Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Академүзәк тарафыннан ук башлана. Ләкин озакламый, әлеге фәнни оешманың корылышына кайбер үзгәрешләр кертелү һәм аның җитәкчесе Г.Ибраһимовның авыруы сәбәпле, бу юнәлештә эш бөтенләй тукталып кала. Җыйналган материаллар башка оешмалар карамагына күчә яки бөтенләй юкка чыга.

Кулъязма материаллар алга таба 1939 елда оешкан Татар, тел, әдәбият һәм тарих институты китапханәсендә саклана. Ул 1950 елда СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы китапханәсен ачарга нигез була.

Институттагы документлар коллекциясенең кулъязмалар өлеше 1940 ел азагыннан 1960 елның декабренә кадәр 784 берәмлеккә җитә.

1960 елның 1 июлендә СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Фәнни китапханәсендә архив оештыру турында карар чыга. Булган фондларны һәм архив материалларын тасвирлау өчен методик кулланма әзерләнелә. Аның нигезендә 1961 елның 15 июлендә китапханәдә егерме елдан

артык вакыт эчендә тупланган кулъязма материалларны тасвирлау башлана. СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы гамәлдән чыгарылу сәбәпле, аның карамагында булган архив 1963 елның 3 маенда Казан физика-техник институтына тапшырыла. Шулай итеп Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни-тикшеренү эшчәнлеге киңәя барган саен аның үз архивын булдыру ихтыяҗы барлыкка килә. 1972 елның мартында институтның үз архивы оештырыла. Казан физика-техник институты архивында сакланучы тасвирланган 41 фонд, 75 тасвирлама, 5843 саклау берәмлеге һәм 40 берәмлек фонд эшләре яңа оешмага тапшырыла. Әмма әлеге мәсьәлә тулысынча башкарылмый: XV-XVIII гасырга караган татар кулъязмалары, Галишер Нәвои әсәрләренең күчермәләре, XV-XVI йөзләрдә күчерелгән суфичыл текстлар, шәҗәрәләр анда кала.

1972 елдан әдәбият секторы хезмәткәрләре археографик материал җыйнау эшен тагын да көчәйтә төшә. Экспедицияләргә чыгу ешая, археографик табышлар күләме дә арта.

1986 елда институтның әдәбият секторыннан кулъязмалар һәм текстология бүлеге аерылып чыга. Аның җитәкчесе профессор Нил Юзиев (1931-1996) була. Архив коллективы әлеге бүлек составына кертелә. Элекке архивның кулъязмалары буенча эшләүче төркемнең җитәкчесе итеп филология фәннәре кандидаты (хәзер доктор, профессор) Марсель Әхмәтҗанов билгеләнә. Ул елларда кулъязмалар хәзинәсе яңа материаллар белән тулылана. 2007 елда кулъязмалар һәм текстология бүлеге нигезендә мөстәкыйль яңа кулъязмалар бүлеге, фәнни һәм архив фонды оешты. 2009 елның июленә кадәр аның мөдире М.Әхмәтҗанов булды, аннан соң конкурс нигезендә бу вазифага мин сайландым. Институтның Гыйльми советы карары нигезендә 2010 елда бүлек Үзәк статусын алды. 2008 елның апреленнән кулъязма мирас «Казан Кремле» дәүләт тарих һәм сәнгать музей-тыюлыгындагы «Манеж» бинасында саклана.

Үткән гасырның 1969 елларыннан башлап археографик экспедицияләр Татарстан, Башкортстан, Чуашстан, Мари-Иле, Мордва Республикаларының; Әстерхан, Ульяновск, Чиләбе, Ырымбур, Курган, Пенза, Киров, Свердловски, Пермь (хәзер край) өлкәләренең районнарында үткәрелде. Аларда институт галимнәре — М.Әхмәтҗанов, Шакир Абилов (1915-2004), Мөнир Йосыпов, Камил Дәүләтшин (1935-2013), Мәсгуд Гайнетдинов, Рафис Әхмәтов (1945-2007), Әнвәр Шәрипов, Нәҗип Исмәгыйлов, Фәрит Яхин һәм башкалар актив катнашты.

М.Әхмәтҗанов үзе 1972-2011 елларда Татарстан Республикасыннан тыш Россия Федерациясенең күп республикаларында, өлкәләрендә, шәһәрләрендә һәм районнарында, Урта Азиядә археографик экспедицияләрдә булып, 500гә якын төрле характердагы шәҗәрәләр, 1000нән артык афишалар, 5000нән артык кулъязма һәм сирәк китаплар, төрле документлар туплады.

Фольклор һәм диалектологик экспедицияләргә чыккан башка бүлек хезмәткәрләре дә кулъязма материалларга баеп кайтты. Алар арасыннан аеруча Хәмит Ярми (1904-1981), Мәхмүт Нигъмәтҗанов, Ләйлә Мәхмүтова (1925-2002), Фазыл Фәсиев, Дөрия Рамазанова, Тәнзилә Хәйретдинова, Рәшит Ягъфәровларны (1946-2008) билгеләп үтү зарур.

Соңгы елларда да институт төрле өлкә, районнардагы татар авылларына комплекслы экспедицияләр оештыра. Материалларны җыйнау кешеләр белән шәхси сөйләшүләр ысулы белән дә башкарыла. Гомумән, кулъязма мирасны туплау эше ел дәвамында бара.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН:

— XX гасырның икенче яртысында Казан университетында археографик эзләнүләр урта гасырлар һәм яңа заман төрки-татар язма чыганаклары белгече, галим Миркасыйм Габделәхәт

улы Госманов исеме белән бәйле. Аның инициативасы белән 1963 елда оештырылган археографик экспедиция университетта төрки-татар чыганакларын өйрәнү традициясен яңартуда беренче адым була. 1963-1981 елларда татар авылларында йөреп, меңләгән татар, көнчыгыш телләрендә кульъязма һәм басма китап тупланды. Нәтиҗәдә, университет Фәнни китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең көнчыгыш фонды нык баеды. Миркасыйм аганың эшен, аның фатихасы белән, укучысы Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин лаеклы дәвам итә.

Җәүдәт МИҢНУЛЛИН:

— Казан (Идел буе) федераль университетында археографик эзләнүләр системалы рәвештә хәзерге вакытта да дәвам итеп килә. Ел саен милләттәшләребез яшәгән төбәкләргә сәфәрләр оештырыла, кульъязмаларның тасвирламаларын язу эше дә дәвам итә. Иң авыр елларда — узган гасырның 90 нчы елларында да бу эш тукталып калмады, ТР Милли китапханәсе белән берләштерелгән экспедицияләр оештырылды. Бу эштә иганәчеләрнең һәм Милли китапханәнең элеккеге директоры Разил Вәлиевнең, бу вазифаны хәзерге вакытта башкаручы Наил Камбеевның ярдәме зур булды.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН:

— Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге уңышлы гына эшләп килә. Бүлекнең оешып китүе ничек булды, алга нинди максатлар куелды?

Раиф МӘРДАНОВ:

— Татарстан Милли китапханәсендә электән эшләп килгән Сирәк китаплар секторы 1992 елның гыйнварында Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге буларак оештырылды. Бүлекне оештырганда алдыбызга куйган төп максатлар өчәү иде. Беренчесе — бүлекне белгеч-хезмәткәрләр белән тәэмин итү. Икенче максат — кульъязма истәлекләр туплау. Өченчесе — җыелган ядкярләрне фәнни әйләнешкә кертү.

Археография белгечләренә һәр заманда кытлык булган. Шул сәбәпле без Казан дәүләт университетында укыган, тарих һәм филологик белемгә ия яшьләрне җәлеп итеп, эшне башлап җибәргән идек.

Ә кульъязма истәлекләрне туплау максатында, 1992 елның җәеннән алып Казан дәүләт университеты белән берләштерелгән археографик экспедицияләр оештырыла башлады. Экспедиция һәр ел саен дәвам итте, ул егерме елдан артык вакыт эчендә Түбән Новгород, Пенза, Самара, Оренбург, Пермь, Киров, Ульяновск өлкәләрендә, Башкортстан, Мари-Иле һәм Чуашстан республикаларының милләттәшләребез яши торган төбәкләрендә, Татарстанның төрле районнарында эшләде. Моннан тыш, бүлек хезмәткәрләре һәр ел мөстәкыйль рәвештә ике-өч мәртәбә республикабыз районнарына, шулай ук күрше республика һәм өлкәләргә дә берәр атналык археографик сәфәрләр оештырды. Шул рәвешчә, калалар һәм авылларда сакланып калган кульъязма истәлекләр Татарстан Милли китапханәсенә алып кайтылды. Казан шәһәренең үзендә дә археографик эзләнүләр уңышлы алып барылды. Мөрәҗәгатьләребезгә җавап итеп, башкалабыздагы күп кенә мәчет идарәләре үзләрендә тупланган, фәнни әһәмияткә ия борынгы язмаларны китапханәбезгә тапшырды. Гарәп язуындагы борынгы китаплар Казандагы китап кибетләренең букинист бүлекләреннән дә китапханәгә алынды. Матбугат, радио һәм телевидение чаралары аша халыкка мөрәҗәгать итүләр дә уңай нәтиҗә бирде. Күп кенә милләттәшләребез почта аша яки үзләре килеп кызыклы материаллар тапшырды, мондый хезмәттәшлек хәзер дә дәвам итә.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН:

— Кульъязма мирасны өйрәнүдә тасвирлау эше мөһим урын алып тора. Бу өлкәдә М.Ногман, А.Фәтхи, Ә.Кәримуллин, М.Госманов, М.Әхмәт-

җанов, С.Гыйләҗетдинов, А.Арсланова, Р.Мәрдановның фәнни хезмәтләре игътибарга лаек. Иран ислам республикасы президенты Әхмәди Нәҗад 2007 елны Алсу Арслановага Казан университеты Фәнни китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең көнчыгыш фондында сакланучы фарсы телендәге кулъязмалар тасвирламасының беренче чыгарылышын (Казан, 2005) эшләгәне өчен «Иран ислам республикасының ел китабы» Бөтендөнья премиясен тапшырды. Шул ук елны бу китап Мәскәүдә иранистика өлкәсендә иң яхшы хезмәт өчен бирелә торган халыкара Фирдәүси исемендәге премиягә дә лаек булды. Бүген кулъязмаларны тасвирау өлкәсендә нинди уңышлар бар?

Рәмил ИСЛАМОВ:

— Хәзерге вакытта институтыбызның архивында 210 фонд (якынча 50000 берәмлек материал) бар. Чыганакларның фәнни тасвирланган өлеше 31558 берәмлек (63%).

2005 елда М.Әхмәтҗанов «Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече» дигән белешмәлек бастырып чыгарды. Аңа 1940-2004 елларда җыйналган материалларның кыскача тасвирламасы кертелде. Тарих фәннәре докторы Гамирҗан Дәүләтшин һәм Әдибә Сабирова тарафыннан Советлар Союзы Герое, патриот шагыйрь Муса Җәлил фонды тасвирланды, 430дан артык документларны туплаган әлеге зур хезмәт 2008 елда нәшер ителде. Филология фәннәре кандидаты, өлкән фәнни хезмәткәр Сәлим Гыйләҗетдинов тупланмадагы фарсы телендәге кулъязмаларны тасвирлауны төгәлләде һәм әлеге уникаль хезмәт өч китап булып дөнья күрде (2002, 2006, 2007). Аларда барлыгы 585 кулъязма китап системага китерелгән (940 берәмлек тасвирлама).

Айрат ЗАҺИДУЛЛИН:

— ТР Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә ел саен уздырыла торган археографик экспедицияләр, командировкалар, шәхси коллекцияләрне алу хисабына 5 меңгә якын иске татар һәм көнчыгыш телләрендәге кулъязма мирас тупланды. Шуларның хәзерге вакытта 45% тасвирланган һәм электрон каталогка кертелгән, дип әйтергә мөмкин.

Зәлия БРУСЬКО:

— Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәгендә фольклор экспедицияләре кысаларында авылларда кулъязма һәм сирәк китаплар җыю 1991 елдан ук алып барыла. Бүген Үзәктә 300дән артык борынгы кулъязма саклана. Болардан тыш 500гә якын иске басма китаплар бар. Кулъязма китапларга фәнни тасвирлама эшләү быел башланды. 160 берәмлек кулъязма инде тасвирланды. Шуларның 120се татар, 38е гарәп, 2се фарсы телендә.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН:

— Кулъязма мирас үрнәкләрен тәрҗемә итеп, текстологик эшкәртеп бастырып чыгару, аларны фәнни әйләнешкә кертү татар гуманитар фәненең мөһим бурычы булып тора. Бу өлкәдә башкарган эшләрне атап үтсәк иде.

Раиф МӘРДАНОВ:

— Татарстан Милли китапханәсендә 2008 елда татар кулъязма мирасының мөстәкыйль басма сериясен гамәлгә куйдык, ягъни аның «Милли китап» нәшриятында «Татар археографиясе» дип аталган махсус сериядә фәнни-популяр китаплар нәшер ителә башлады. Һәр елны бу сериядән ике басма дөнья күрә.

«Татар археографиясе» сериясенең төп максаты — Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган язма истәлекләрнең текстларын басмага әзерләп нәшер итү аша татар кулъязма мирасын пропагандалау. Киләчәктә башка фәнни оешмалардагы: китапханә, архив, музейлардагы һәм шәхси куллардагы кулъязма истәлекләр дә, те-

матикасына күрә, килешенү нигезендә, «Татар археографиясе» сериясендәге басмаларга кертелүе ихтимал.

Хәзерге вакытка унике җыентык әзерләнде. Аларның унбере басылып чыкты, ә соңгысы шушы көннәрдә чыгачак дип көтелә. «Мәүла Колый поэмалары», «Кыйссаи Мансур» һәм «Кыз хикәяте» әсәрләре — урта гасыр татар әдәбиятының моңарчы бөтенләй билгесез әсәрләре иде. Калганнары турында исемнәре әйтеп тора. Алар: «Түләк китабы» дастаны, «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмаларына тасвирламалар», «Мөхәммәдьяр. «Нуры содур» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмалары», Хөсәен Фәезхановның «Кыскача татар тарихы» хезмәте, «Сәяхәтнамәләр», «Шанхай Төрк-татар мәдәнияте җәмгыяте», «Сөрген хатлары» һәм «Китапларда милләт язмышлары...». Соңгы җыентыкта археографик эзләнү нәтиҗәләребезгә багышланган мәкаләләр тупланды. Ә бу сериянең чыгып килә торган басмасы тарихи бәетләр җыентыгы буларак әзерләнде.

Рәмил ИСЛАМОВ:

— Археографик экспедицияләрдә туплаган байтак риваятьләр, легендалар, мәкаль-әйтемнәр, җырлар, мәзәкләр унике томлык «Татар халык иҗаты» антологиясе томнарында (1977, 1978, 1979, 1980, 1981, 1983, 1984, 1987, 1988, 1993), М.Гафуриның дүрт томлыгында (1980, 1981, 1983) урын алды.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәренең тупланмалардагы 25 кульязма нөсхәсе филология фәннәре кандидаты Ф.Фәсиев тарафыннан әзерләнеп нәшер ителгән «Кол Гали. Кыйссаи Йосыф» (1983) дигән китапта тасвирланды. Әсәрнең язылуына 800 ел тулуга багышлап чыгарылган бу басмада кульязмаларның күбесе текстологик планда файдаланылды.

Текстологлар тарафыннан әзерләнгән «XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия» (2006), «Кол Шәриф һәм аның заманы — Кул Шариф и его время» (2005) җыентыкларын махсус әйтеп китү сорала.

Филология фәннәре докторы М.Әхмәтҗанов «Татар шәҗәрәләре (Беренче китап)» (1995), «Олы Мәңгәр авылы тарихы» (2000), «Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы» (2002), «Касыйм шәйех-газиз» (2008), «Мирас истәлекләре» (2008), «Мәгариф, археографик эзләнүләр» (2009), «Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы» (2009), «Дәшми калмам — Газраилне күргәндә дә...» (2010), «Төш юрау китабы (Тәгъбирнамә, юрамышлар, ырымнар)» (1991), «Каһарман катыйль» (1998) кебек төрле чыганак үрнәкләре тупланган китаплар бастырды.

Текстологик әсәрләр арасыннан өлкән фәнни хезмәткәр Н.Исмәгыйлов әзерләгән «Мәҗмугыл-хикәят»не (1994) әйтеп үтәргә мөмкин. Аны 1775 елда Мөхәммәдрәхим ибне Рәфыйк әл-Казани (Казан өязе Ташкичү авылы кешесе) Тубыл губернасы Тара өязендәге бараба татарлары арасында яшәгән вакытта язган. Галим тарафыннан шул ук сериядә «Гыйбрәтле хикәяләр» (2004) исемле китап та нәшер ителде. Анда XVIII-XIX гасырларга нисбәтле шәкерт дәфтәрләрендәге кече жанр әсәрләре урын алган.

Зәлия БРУСЬКО:

— Без дә, үз чиратыбызда, кызыклырак материалларны матбугатка чыгарып, ягъни газета-журналларда бастырып, алар турында төрле чараларда, конференцияләрдә чыгышлар ясап, фәнни әйләнешкә кертергә тырышабыз.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН:

— Археографик эзләнүләрнең ахыргы максаты — кульязмаларны фәнни әйләнешкә кертү, фәнни хезмәтләр аша халкыбыз тарихын, мәдәниятен, иҗтимагый фикер үсешен яктырту. Заманында Миркасыйм Госманов XVII-XVIII гасырлар татар нарратив чыганакларына багышланган кандидатлык диссертациясе (1968) һәм XIV-XVI гасырлардагы Җучи олысы ярлыклары турында (1981) докторлык

диссертациясе яклаган иде. Бу өлкәдә татар халык иҗатын, татар әдәбияты тарихын өйрәнүче галимнәребезнең дә уңышлары игътибарга лаек. Соңгы елларда кулъязма чыганаклар нигезендә нинди яңа фәнни темалар эшләнде?

Рәмил ИСЛАМОВ:

— Фондларда сакланучы материаллар диссертация язганда уңышлы файдаланыла. Мәсәлән, алар М.Әхмәтҗановның «Яңа археографик материаллар һәм татар әдәбияты тарихын тикшерүләрдә аларның мәгънәсе» (2000) дигән докторлык, Заһир Шәйхисламовның «Әхмәт Фәйзи иҗатында Тукай темасы (драмалар һәм роман. Вариантлар өстендә эшләү)» (1999), Гөлнара Зәйниеваның «Таҗетдин Ялчыголның «Рисалә Газизә»се» (2002), Айдар Гайнетдиновның «Атнаш Хафизның «Сиражел-колүб» әсәре (проблематика һәм сәнгать үзенчәлекләре)» (2009) кандидатлык диссертацияләренең төп чыганаклары булдылар. Алар, шулай ук, Нурмөхәммәт Хисамовның «XIII-XV йөзләр урта гасыр төрки-татар шигъриятендә Йосыф һәм Зөлайха сюжеты» дигән докторлык (1996), Нил Юзиевнең «Муса Җәлил поэмалары» (1958), Әнисә Алиеваның «XVIII гасыр «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе»нең телен тикшерү» (1990), Зөфәр Мөхәммәтшинның «Фатих Халидинең иҗат мирасы» (1999), Алсу Хасавнехның «XIX гасыр суфи шагыйре Әхмәдҗан Тубылиның этик-эстетик карашлары» (2002), Рәҗәп Бәдретдиновның «Афзал Таһировның иҗат мирасы: идея эчтәлеге һәм сәнгать үзенчәлекләре» (2008), Миләүшә Инсафетдинованың «XVIII гасыр ядкяре «Фәүзен-нәҗат»нең проблематикасы» (2010) дигән кандидатлык диссертацияләрендә чагылыш тапты. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре нөсхәләре филология фәннәре докторы Н.Ш.Хисамовның рус телендәге «Кысса-и Йусуф» Кул Гали. Анализ источников сюжета и авторского творчества» (1979) һәм «Бөек язмышлы әсәр» (1984) дигән монографик тикшеренүләрендә анализланды. Чыганаклар нигезендә алты томлык «Татар әдәбияты тарихы» академик басмасының 1 һәм 2 томнары (1984,1985), М.Әхмәтҗановның «Татар кулъязма китабы» (2000), «Мирас ядкярләре» (2008), Заһир Шәйхисламовның «Аңлыем дип шагыйрь җанын...» (2001), Г.Зәйниеваның «Кол Мөхәммәд шигъри иҗаты: текстология, проблемалар һәм тел үзенчәлекләре» (2008), Ләйлә Шәмсетдинованың «Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» әсәре: проблематикасы һәм сәнгатьчә эшләнеше» (2007) дигән монографик хезмәтләре дөнья күрде.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН:

— Заманча технологияләр куллану, иске басма китапларны электрон вариантка күчерүдә Татарстан Республикасы Милли китапханәсе зур уңышларга ирешә. Башка фәнни үзәкләрдә дә кулъязмаларның электрон вариантлары эшләнәчәкме?

Зәлия БРУСЬКО:

— Кулъязмаларга һәм сирәк басма китапларга фәнни тасвирлама төзелеп беткәч, без дә бу эшне башларга планлаштырабыз. Басма китапларга караганда кулъязмаларның электрон вариантларын эшләү күпкә зарур.

Җәүдәт МИҢНУЛЛИН:

— 23 октябрьдә КФУ һәм «IRCICA»ның Ислам тарихы, сәнгате һәм мәдәнияте фәнни-тикшеренү үзәге арасында килешүгә кул куелды. Килешү нигезендә университеттагы көнчыгыш кулъязмаларын электрон форматка күчерү, реставрацияләү, бу эшләрне башкару өчен махсус остаханә ачу һ.б.күздә тотыла. Болар тормышка ашса, әлбәттә, мирасыбызның саклау һәм өйрәнү өлкәсендә зур адым ясалыр иде.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН:

— Сүзебезне XIX гасырдан башлаган идек. Бүген, XXI гасырда, археография фәнендә кайсы мәсъәләләрне көнүзәк дип атарга мөмкин? Эшне ничек яңартырга кирәк?

Раиф МӘРДАНОВ:

— Нинди генә яңа һәм алдынгы технологияләр кулланылса да, археография өлкәсендә иң беренче һәм иң төп мәсьәлә — белгечләр мәсьәләсе тора. Менә шуны максатчан рәвештә кайгырту һәм булган белгечләргә тиешенчә эшләү мөмкинлекләре булдыру зарур. Бүген татар археографиясе белгечләренә карата таләпләр дә яңача һәм югарырак куела. Алар — гарәп, фарсы һәм госманлы төрек телләрен әйбәт белгән, борынгы чор төрки һәм татар халкы тарихы, әдәбиятыннан тирән мәгълүматлы, шулай ук ислам дине тарихын яхшы белүче иманлы белгечләр булырга тиеш.

Җәүдәт МИҢНУЛЛИН:

— Гомумән алганда, республикабызда археография өлкәсендә планлы, системалы эшләү җитенкерәми. Мәсәлән, Пермь өлкәсенә 6-7 тапкыр гыйльми сәфәр оештырылса, кайбер төбәкләргә исә татар археографлары аяк та басмаган. Моның сәбәбе бик гади: археографик эшчәнлек белән шөгыльләнүче оешмалар төрле ведомстволарга карый. Узган гасырның 20 елларындагы Гыйльми үзәк кебек бу эшне координацияләүче оешма юк.Үзара килешү нәтиҗәсендә моны Татарстан Фәннәр Академиясе эшли алыр иде, бәлки. Кадрлар әзерләү мәсьәләсе дә игътибар сорый. Мин университетта тарихчыларга «Татар тарихы чыганаклары» дигән махсус курс укый идем, университетта барган үзгәрешләр нәтиҗәсендә, ул курс программадан төшеп калды. Аны яңадан программага кертү максатка ярашлы булыр иде.

Казан, Санкт-Петербург, Мәскәү, Уфа һ.б. шәһәрләрдәге татар кулъязмалары саклана торган фондларга кыскача тасвирлама ясап, библиографик белешмәләр белән махсус җыентык төзеп чыгару да көн тәртибендә тора. Чөнки яшь тикшеренүчеләрнең күпчелеге кайда нәрсә саклануын белеп бетерми. Аеруча Россия ислам университеты шәкертләре бу мәсьәләдә бихәбәр. Алар Фәнни китапханәгә килә дә теге яки бу кулъязманы яки басма китапны укырга тотына. Ул кулъязманың фәнни әйләнешкә 100 ел элек керүен дә, аның хакында берничә мәкалә яки китап бысылып чыгуын да белмиләр. Ягъни тарихи чыганакчылык, татар археографиясе тарихын белмиләр. Хәер, хәзерге вакытта татар тарихын гарәби язулы чыганакларны гына түгел, хәзерге татар имласын да укый белмәгән «галимнәр» язуын искә алсак, нигә ул кадәр гаҗәпләнергә? Кыскасы, шәрык археографиясе өлкәсендә бу һәм башка проблемалар (эш урыны, хезмәт хакы, торак һ.б.) хәттин ашкан.

Зәлия БРУСЬКО:

— Дөрестән дә, татар кулъязма китапларына кагылышлы мәгълүматларны берләштерүче мәгълүмати база булдырылса иде. Аны электрон каталоглар төзү юлы белән хәл итеп була. Бу турыда уйлашырга һәм бергәләп эшкә тотынырга кирәк. Шул ук вакытта булган кулъязмаларның фотокүчерелмәләрен PDF форматында да эшләп, интернетка кую мөмкинлекләрен табарга кирәк.

Айрат ЗАҺИДУЛЛИН:

— Туплаган мирасны саклау да республика күләмендәге зур проблема булып тора. Моның өчен заманча бина һәм китап саклагычлар кирәк. Барлык кулъязмалар да 100% реставрация һәм концервация үтәргә тиеш.

Кулъязманы тиешле дәрәҗәдә реставрацияләү бу өлкәдә эшләүче тиешле белгечләрне таләп итә. Безнең китапханәдә кулъязмаларны реставрацияләү буенча Сәяр Хәйдәров исемле егет Санкт-Петербургта укып кайтты. Әмма ул үз белемен тиешле дәрәҗәдә гамәлгә ашыра алмый, чөнки тиешле җиһазлар җитеп бетми. Әгәр дә тиешле җиһазларны бирәбез, дип әйтәләр икән, аны да куярга урын барларга кирәк. Дөрес, заманында Татарстанда региональ концервация үзәге төзергә кирәк, дигән мәсьәлә кузгалтылган иде, бина бирелергә тиеш иде...

Рәмил ИСЛАМОВ:

— Кайбер мәсьәләләрне хәл итү көнбатыш илләренекеннән, Мәскәү, Санкт-Петербург дәрәҗәсеннән шактый ерак тора. Әйтик, химик-биологик эшкәртү бөтенләй юк. Ул лаборант эше дип кенә карала. 4-5 мең сумлык хезмәт хакына нинди химик-биолог килеп бу хезмәтне башкарсын? Эшнең сәламәтлеккә зарарлы булганы өчен өстәмә түләү дә юк.

Айрат ЗАҺИДУЛЛИН:

— Халкыбызда кулъязмачылык традициясен бүген дә өзелде, дип әйтеп булмый. Әбиләр хәзерге заманда да бәетләрне, мөнәҗәтләрне, хатларны, догаларны гарәби язуда кулдан-кулга күчереп яза. Бу язмалар да күпмедер дәрәҗәдә дини-әхлакый әһәмияткә ия. Шулай да күпләр кулъязмаларга макулатурага караган кебек карый. Соңгы елларда борынгы китап фәлән сум тора дигән сүзләрне ишеткәч, кешеләр әһә, моның бәясе бар икән, дип сөйли башлады. Хәзерге вакытта гарәби язулы шәхси коллекцияләрне китапханәгә туплау махсус финанслауны таләп итә.

Зәлия БРУСЬКО:

— Кызганычка каршы, мирасның сакланышы белән артык мактана алмыйбыз, чөнки, беренчедән, вакыт үз эшен эшли тора, икенчедән, безгә бәйле булмаган сәбәпләр белән, берничә ел кулъязмаларны бинабызның подвалында яткырырга мәҗбүр булдык. Анда, дымлылык көчле булу сәбәпле, китапларыбызга бераз зыян тиде. Хәзер исә хәл үзгәрде, кулъязмаларны чагыштырмача яхшы шартлар тудырылган бинага күчердек.

Бүген дөньякүләмендә бик күп яңа технологияләр, яңалыклар кулланыла. Мәсәлән, химиклар, физиклар, биологлар үзләренең эшләү методлары белән кәгазьнең кайсы елларга караганын бик тиз ачыклый ала. Мәсәлән, радиоуглерод анализы ысулы киң таралган. Шулай ук караларны тикшереп, күп кенә мәгълүмат алып була, кайбер сөртелгән, өстенә сызып бетерелгән, юылган яисә башка сәбәпләр белән юкка чыккан хәрефләрне, сүзләрне яңадан торгызырга мөмкин. Әгәр дә кәгазьдә су билгеләре булмаса яки күренмәсә, моның әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Төрле химик эремәләр, препаратлар белән эшкәртү китапларның гомерен бик күп елларга хәтле озынайтырга мөмкинлек бирә.

Бу эшләрне Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенә караган институт галимнәре дә бернинди авырлыксыз эшли ала. Безгә алар белән тыгыз хезмәттәшлек итәргә кирәк, дип саныйбыз. Барысы да акчага килеп төртелгәнгә күрә, хөкүмәтебез тагын да күбрәк ярдәм итсә, безнең әлеге көнгә кадәр сакланып калган язма мирасыбыз югалмас.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН:

— Соңгы чирек гасырда, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан университетыннан тыш, кулъязмаларны барлау, тавирлау белән Татарстан Милли китапханәсе һәм Мәдәният министрлыгы каршындагы Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге галимнәре максатчан шөгыльләнә башлады. Бу өлкәдә эзләнүләр алып баручы фәнни үзәкләрнең артуы киләчәккә өмет белән карарга мөмкинлек бирә. Татар язма мирасын өйрәнү һәм пропагандалау шушы елларда Татарстанда барган яңарышның чагылышына, республикада фән үсешенең мөһим юнәлешенә әверелде. Бу уңышларның нәтиҗәсе — сезнең һәм башка татар галимнәренең фидакяр хезмәте, китаплары. Сезгә шушы игелекле һәм катлаулы хезмәт юлыгызда яңа уңышларга ирешүегезне телим!

***Илдус Заһидуллин** һәм*
***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

***Редакциядән:** журналыбызның киләсе санында Гомәр Даутовның «Гамьле сәфәр хатирәсе» дип аталган язмасын тәкъдим итәбез. Автор археографик экспедицияләрнең берсе хакында истәлекләре белән уртаклаша.*

СОҢГЫ ӘҢГӘМӘ

Нәсим Акмал

Сезнең игътибарга тәкъдим ителгән бу язма – Татарстан радиосының «Татарстан дулкынында» тапшыруының кәгазьгә күчерелгән варианты. Көн саен эфирга чыга торган дистәләгән тапшырулар арасында әллә ни аерылып тормаган гадәти бер тапшыру иде ул, ягъни радио журналистының көндәлек мәшәкатенең бер җимеше. Ләкин аңа башкачарак тәкъдир язылган булып чыкты, ул инде хәзер архивта халкыбызның олуг заты Миркасыйм Госманов белән соңгы интервью буларак саклана.

2010 елның җәй башларында минем кулга «Җыен» фонды әзерләп чыгарган Җамал Вәлиди турында китап килеп керде. Мин аны... кызыксынып дип кенә әйтү бик сай әйтү булыр, тетрәнеп укыдым. Безнең тарихка, бүгенге халәтебезгә, үткәндәге һәм хәзерге шәхесләребезгә күземне ачты бу китап! Менә шул тетрәнү тәэсирендә, шушы китапка багышланган бер радиотапшыру ясау хыялы туды да инде. Озак кына уйлап-уйланып йөрдем дә, Миркасыйм агага шалтыраттым. Чөнки ул бу китапка гыйльми мөхәррир дә булган, сүз башы да язган кеше. Миркасыйм ага теләгемне ишеткәч, очынып китмәсә дә, начар булмас иде, андый тапшыру кирәк инде халыкка, дигән кебегрәк рәвештә битараф кына сөйләшсә дә, аның бу идеяне күңеле белән хуплаганы сизелә иде. Һәрхәлдә миңа шулай тоелды. Тик бер кыенлык бар икән: Миркасыйм ага үзе авылда булып чыкты, Казанга көз айларында гына кайтасы икән. Шуңа чаклы сабыр итеп торырга туры киләчәк.

2010 елның җәе бик коры килде. Июнь башыннан алып август ахырларына чаклы бер тамчы да яңгыр төшмәде. Россияне корылык яулап алды. Тайга янды, бөтен җирдә урман дөрләде, Мәскәү янындагы сазлык торфлары көйрәде. Зур шәһәрләрне төтен каплады, суларга һава калмады.

Мин бу хәлләрне нигә язаммы? Миркасыйм ага бу җәйне табигать кочагында үткәрсә дә, менә шушы казадан котылып кала алмаган ахрысы, диюем. Чамасыз эсселек, төтенле вә тынчу һава аның авыруын көчәйтеп җибәргәндер, дип уйлыйм.

Менә бервакыт Миркасыйм ага Казанга кайтты. Без аның белән университетның ул эшләгән татар халкы тарихы кафедрасында, тыйнак кына эш бүлмәсендә очраштык. Озак сөйләштек. Миркасыйм ага берничә тапкыр саламдай нечкә затлы сигаретын көйрәтте. Мин исә түздем, аның алдында тартырга читенсендем. Без Җамал Вәлиди, аның татар тарихында тоткан урыны, шул тарихка ясаган йогынтысы турында сүз алып бардык, «Җыен» фонды әзерләп чыгарган башка китаплар, бу эшнең мөһимлеге һәм кыенлыклары турында да сөйләштек. Ахырда мин аңа һәр яңа китап турында бергәләшеп аерым тапшыру ясап барырга, шул юл белән аларны халыкка пропагандаларга тәкъдим иттем. Миркасыйм ага ризалашты, без телдән генә үзара килешү төзегән кебек булдык. Бу 2010 елның 8 октябре — атнакич иде.

Радиога кайтып, язманы эшкәртәмонтажлый башлагач, бер нәрсәгә игътибар иттем: Миркасыйм ага сулышын авырлык белән генә ала икән

Сулдан уңга: Ринат Закиров, Разил Вәлиев, Салисә Госманова, Миркасыйм Госманов, Марсель Галиев. Казан. 2006 ел.

бит, кайвакытта тын алганда ыжылдаган авазлар да килеп кушыла: эфирда ямьсез ишетелер дип, сулыш алган тавышларның кайберләрен бөтенләй алып ташладык, каберләрен техник юл белән йомшартырга тырыштык. Нәтиҗәдә, җыйнак, күркәм генә язма пәйда булды.

Тапшыру 10 октябрь — шимбә көнендә эфирга чыкты. Ә инде 12се көнне — дүшәмбедә эшкә килүгә мин аның үлем хәбәрен ишеттем. Ул 11 октябрьдә мәңгелеккә китеп барган икән…

Миркасыйм аганы югалту болай да авыр булган булыр иде. Әмма инде аның белән күңелгә-күңел тиеп диярлек аралашканнан соң, уйламаган-көтмәгән җирдән китеп баруы аеруча авыр булды. Абыемны югалткан көннәрдәге кебек сулкылдады күңел. Нияз абый 2007 елның 11 августында китеп барган иде бит. Ә Миркасыйм ага — 11 октябрьдә. Аһ, бу серле һәм дәһшәтле «11 ле» саны!

…2011 елның 31 маенда университетның музей бүлмәсендә академик Миркасыйм Госмановны искә алу кичәсе үткәрелде. Искәндәр Гыйләҗев: «Миркасыйм абыйның туган көне беренче тапкыр аның үзеннән башка гына үткәрелә», — диде. Монда Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев бар иде. Әхмәт Мазһаров, Илдус Садыйков, Индус Таһиров һәм тагын берничә галим чыгыш ясады. Кичә тәмамланып, халык таралыша башлагач, мин дә Миркасыйм аганың җәмәгате Салисә апа янына сәубуллашырга килдем. Кем булуымны әйткәч, ул мине кочаклап диярлек алды. Теге көнне бит ул синең белән очрашудан канатланып кайткан иде, радиодан тавышы шундый көр, сәламәт булып ишетелде… Менә шулай килеп чыкты инде, энем, дип елап алды.

Менә бит ничек булган икән…

Миркасыйм ага белән миңа озак вакытлар дәвамында якыннан аралашырга насыйп әйләмәде. Әмма менә шундый мизгелдәй күренешләр дә күңелдә онытылмас эз калдырды. Татар халкының бәхете өчен барган яу кырында батырларча һәлак булган (әйе, нәкъ менә — һәлак булган) Миркасыйм Габделәхәт улының якты рухы шат булып, аңа урын Җәннәт түрләрендә бирелсә иде.

ШӘХЕСЛӘРСЕЗ МИЛЛИ ТАРИХ ЮК...

(Миркасыйм Госманов белән Нәсим Акмал әңгәмәсе)

Н.А.: Хәерле көн, хөрмәтле радио тыңлаучылар! Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез өчен тапшыруыбызны башлыйбыз. Күптән түгел «Җыен» фонды күренекле татар галиме, телче, әдәбиятчы, тарихчы, педагог, публицист Җамал Вәлидинең эшчәнлеген һәм тормыш юлын яктырткан яңа китап нәшер итте. Аны укыгач, халкыбыз тәкъдирендә мөһим бер роль уйнаган олуг шәхеснең якты сурәте күз алдына килеп басты. Җамал Вәлиди – хәзерге көндә укылырга, өйрәнелергә, гыйбрәт һәм сабак алынырга тиешле хезмәтләр, мирас калдырган фаҗигале язмыш иясе. Бүген без әлеге шәхес һәм аның турындагы җыентык хакында китапның фәнни мөхәррире, тарих фәннәре докторы, ТР ФА академигы Миркасыйм Госманов белән әңгәмә корырбыз. [...]

Миркасыйм ага, Сез җитәкләгән «Җыен» фонды тарафыннан нәшер ителгән китапларны укып барабыз. Яңа китаплар белән танышкан саен рәхмәт хисләребез зурая. Олы шәхесләребез безнең хәтергә әйләнеп кайтты. Әле менә күптән түгел генә Җамал Вәлиди турында китап дөнья күрде. Күптән инде бу чаклы ук тетрәнеп китап укыган юк иде. Күңелдә горурлык хисе барлыкка килде. Күрче, безнең халыкның нинди олуг, дөнья күләмендә шәхес дип аталырлык затлары булган икән, бар икән. Ә бит халыкның зурлыгы аның шәхесләренең зурлыгы белән билгеләнә.[...]

М.Г.: Хәерле көн, хөрмәтле һәм кадерле тыңлаучылар. «Шәхесләребез сериясе» турында сүз чыккан икән, бер-ике генә җөмлә белән «Җыен» фонды турында да әйтергә кирәктер. «Җыен» фонды туксанынчы елларның башында, татар мәдәниятен, телен, татар тормышын әйбәтләп яктырту, таныштыру максатыннан оешкан бер вакыф, ягъни фонд. Менә шушы фонд эшли башлаганнан бирле аны оештыручы, аның идеологы режиссёр Дамир Сираҗиев булды. Күренекле җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь Разил Вәлиев һәм мин дә кушылып, бу фондны аякка бастырдык. Шуннан бирле безнең төрле юнәлештәге эшләребез бар. Концертлар, конкурслар оештыру һәм китаплар чыгару. Китап дигәндә, без иң элек моңарчы сирәк басылган, ягъни совет чорында тыелган яки онытдырылган әсәрләрне чыгарудан башладык. Мәсәлән, М.Худяковның Казан тарихы турындагы әһәмиятле хезмәтен беренче булып чыгардык. Карл Фуксның татарлар турындагы язмаларын бастырдык. Алар бик әһәмиятле әсәрләр, әһәмиятле язмалар. Исмәгыйль Гаспралының хезмәтләрен чыгардык.

Соңра безгә шундый фикер килде: онытылган шәхесләребез безнең бик күп. Совет чорында без бит өчдүрт кенә шәхесне атый идек. Әгәр мәгърифәтчелек дөньясы турында сүз булса — Каюм Насыйри. Калганнарын белмибез. Каюм Насыйри бит ул — урта куллы бер практик-мәгърифәтче. Мәрҗани һәм Риза Фәхреддиннәр белән чагыштырганда теоретик фикер анда чамалы. Әдәбиятны алсак — бер Тукай. Бик күп еллар Галимҗан Ибраһимов та юк иде. Гаяз Исхакыйны әйтәсе дә юк, аны дошман дип сүгеп, тибеп узудан ары китмәдек. Һәм тагын дистәләгән онытылган шәхесләр бар. Ә тарих — ул шәхесләрнең эшчәнлегеннән гыйбарәт. Совет чорында безгә тарихны халык массалары ясый, дип өйрәтәләр иде. Ә халык массаларын кемнәр ияртеп йөри,







Бездә бик күренекле мәгърифәтчеләр, әдипләр, галимнәр белән бергә татар тормышына зур яңалык китергән эшкуарлар, байларыбыз булган.

кемнәр аңа фикер белән канат бирә? Аерым кешеләр, аерым шәхесләр.

Н.А.: Халыкның энәсе, җепне ияртеп бара торган энәсе – зыялылар булдымы?

М.Г.: Әйе. Менә шушы зыялыларны беркадәр кайтару юлына мин аспирант чорыннан ук мавыгып киттем. Иң башта Хөсәен Фәезхановны яңадан өйрәнеп, аның турында китап яздым. Шулвакытта Мәрҗани, Риза Фәхретдиннәр турында да кызыксына башладым. Аларсыз безнең мәдәни тормышыбызны күз алдына да китереп булмый. Һәм менә соңгы вакытта шул шәхесләргә багышланган махсус китаплар чыгарырга, дигән карарга килдем. Мәсәлән, без Фатыйх Кәрими, Газиз Гобәйдуллин турында, бертуган Рәмиевләр яки Гайнетдин Әхмәров, Габдрахман Сәгъди булсын, ниһаять, Гали Рәхим кебек онытылган бөек шәхесләребез турында да китаплар чыгаруга ирештек. Унбиштән артык китап чыкты. Һәрбер шәхескә багышланган документлар, аларның әсәрләреннән үрнәкләр һәм эшчәнлеге турында әйтелгән фикерләр... Менә шулай итеп бу эш башланып китте. Хәзер зур план төзелде. Минем уемча, әгәр дә гомер булып, дөньялар нормаль барса, татар шәхесләре хакында йөз егермегә якын китап чыгарып булыр иде.

Бездә шәхесләр бик күп. Һәм бик кызык, ялтырап торган шәхесләр бар. Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Исмәгыйль бәй Гаспралы... Аларсыз безнең тарих юк. [...] Күренекле фикер ияләренең берсе – Җамал Вәлиди. Ул бер яктан – филолог, икенче яктан – тарихчы, өченче яктан – фикер иясе, философ та. Аның язган әсәрләре үз чорында әдәби хәрәкәткә дә, тарихи фикергә дә бик нык тәэсир ясады. Ләкин, мәгълүм булганча, Җамал Вәлиди, иң беренчеләрдән булып, «солтангалиевчелек» дигән уйдырма, яла белән гаепләнеп, 1932–1933 елларда ук кулга алынган, төрмәдә кыйнап үтерелгән кеше. Аннан соң, Солтангалиевнең исемен телгә алу тыелган кебек, Җамал Вәлиди дә оныттырылган иде. Менә шул Җамал Вәлидинең әсәрләрен, хезмәтләрен җыеп, «Шәхесләребез»

сериясендә чыгардык. Шуны да әйтергә телим: Җамал Вәлидинең әле бу томга кермәгән хезмәтләре дә бар. [...] Кызганыч, аның мирасы, иҗаты оныттырылган иде, хәзер инде яңадан кайта башлады.

Н.А.: [...] Миркасыйм ага, сез оныттырылган, дип әйттегез. Менә, әйтик, шушы китапны укыган чагында бер фикергә килеп юлыгасың: Җамал Вәлиди иң беренче булып җәдитчелек хәрәкәтенә бәя бирә. XIX гасырның икенче яртысы – XX йөз башларына таба инде көч-куәт алган җәдитчелек хәрәкәтенең 1905 елда булган революциягә хәзерләнү икәнлеге турында да әйтә. Без бит инде моны мәктәптән беләбез. Димәк, Җамал Вәлидине онытылган, дип әйтеп булмый. Безгә аның фикере таныш.

М.Г.: Фикере таныш, чөнки ул фикер бер Җамал Вәлиди тарафыннан гына әйтелмәгән, башкалар тарафыннан да кабатланган. Ләкин, оныттырылган дип әйтүем, конкрет шәхес буларак, ул үзе оныттырылган. Ә фикер, кайбер оныттырылган кешеләрнең дә фикерләре мөстәкыйль рәвештә яшәп китә ала. Җамал Вәлидинең хезмәтләрен галимнәр файдаланган, ләкин исемен генә телгә алмаганнар. Алса да, «солтангалиевче» дип тибеп, узып кына киткәннәр. Шуның өчен монда «оныттырылган» дию шәхескә булган конкрет мөнәсәбәткә карый.

Ә инде Җамал Вәлидигә гомумән килгәндә, аның иҗаты бу бер-ике китап белән генә чикләнми. Тагын икеөч китап чыгарырга мөмкин. Галимнең «Очерки образованности и литературы татар» дигән рус телендә язган китабы бар. Хәтта совет чорында да галимнәр аны бик оста файдалана иде, исемен атамыйча гына. Аны да чыгарырга кирәк. Башка мәкаләләре дә бар аның. Аларны да бастырырга кирәк. Һәрхәлдә, йомгаклап әйткәндә, Җамал Вәлиди – бик күренекле шәхесләребезнең берсе.

Н.А.: Сез инде «йомгаклап» дип әйттегез дә, ләкин менә Җамал Вәлиди темасын бик үк йомгаклап җиткерәсе килми бит, чөнки бу китапны укыганнан соң туган хисләр шулхәтле көчле, шулхәтле тәэсирле. Бу китап менә минем кебек журналистка гына түгел, ә галимнәргә һәм безнең мөгаллимнәргә, укытучыларга да зур рухи һәм фәнни бер азык булыр, дип уйлыйм мин. Менә, әйтик, аның Тукай турында әйткән фикере. Беренчеләрдән булып, ул Тукайның бөеклеген күреп, танып алган. Аннан соң Галимҗан Ибраһимов белән матбугатта алып барылган бәхәсләре...

М.Г.: Ни өчен Җамал Вәлиди белән Галимҗан Ибраһимов арасында барган бәхәсләр зур әһәмияткә ия? Хикмәт шунда, инкыйлабка кадәрге татар әдәбияты, урыс совет әдәбиятының кыерчыгы, бер кечкенә генә тармагы түгел, ул мөстәкыйль әдәби фикер булып яши иде. Һәм менә шуның мөстәкыйль әдәби фикер булып яшәгәнлеген күрсәтеп торган берничә мөһим факт бар. Һичшиксез, Исхакый – яңа чор әдәбиятның «елга башы». Гадәтебезчә, Тукай дибез. Тукайга кадәр үк «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ы белән Исхакый танылган. Һәм аны Габдулла Тукай үзенең остазы итеп таныган. Чыннан да ул шулай. Тукай үзе дә – әдәби фикернең мөстәкыйльлеген исбатлый торган иң күренекле шәхесләрнең берсе. Аннары менә – Җамал Вәлиди. Ул да иҗтимагый, әдәби фикернең нигезен, көчен тоеп иҗат иткән кеше. Шуның өчен, Совет чорындагы әдәби тәнкыйтьтән аермалы буларак, 1917 елга кадәрге безнең әдәби фикеребез шактый мөстәкыйль иде. Моны белергә кирәк. Ә без менә бөтен казанышлар совет чорында гына булды, дибез. Совет чорында казанышлар формаль рәвештә генә барлыкка килде. Әдәби фикер бетте. Социалистик реализмга кереп баттык. Һәм большевиклар күрсәтмәсеннән бер сантиметр читкә чыгудан да курка идек. Большевизмның нәрсә икәнлеге һәм ничек беткәнлеге хәзер барыбызга да билгеле. Банкрот булып бетте. Шуның өчен революциягә кадәрге иҗтимагый фикер, әдәби фикер мәсьәләсенә киңрәк тукталу, һичшиксез, кирәк. Шушы мәсьәләләргә игътибар иткәндә,

«Җыен» фондының әгъзалары һәм кунаклары. Казан. 2008 ел

без, җәдитчелек дигән олы күренешне дә истә тотарга тиешбез. Җәдитчелек — ул гадәти мәгърифәтчелек түгел, ул күпкә киң, күпкә тирән хәрәкәт, гомум милли яңарыш хәрәкәте. Безнең әдәбият өлкәсе булсын, тарих өлкәсе булсын, иҗтимагый фикер өлкәсе булсын, мәдәниятебезнең иң гөрләп чәчәк аткан чоры бишенче елдан соң башланып китә. Тукай да бит юкка гына: «Без бишенче елны уяндык таң белән», дип әйтми. Һәм шуннан соң бу хәрәкәт егерме өченче елларга кадәр дәвам итә. Егерме өченче елларда, мәгълүм булганча, Солтангалиевне, татар зыялыларын эзәрлекләү башлана. Шуннан соң инде торгынлык чоры китә. Формаль рәвештә барысы да ал да гөл кебек, әдәби әсәрләр дә күп, ләкин аларның эчтәлеге шаблон бер калькага салынган. Сирәк-мирәк кенә кайбер әсәрләр ялтырап чыкты, сирәк-мирәк кенә кайбер әдипләр чын мәгънәсендә әдәбиятчы булып күтәрелде. Мәсәлән, Әмирхан Еникине алыйк. Ә калган күбесенең бүген әсәрләрен укырлык түгел. Бу — фаҗига. Менә шушы күзлектән караганда, Җамал Вәлидинең һәм фикердәшләренең, хәтта оппонентларының да урыны аерым югарылыкта.

Инде Галимҗан Ибраһимовка килгәндә, ул да гаҗәп талантлы кеше булган. Ләкин характеры беркадәре субъектив. Мәсәлән, бер кеше белән бер бәхәсләштеме — ул аның дошманына әверелә. Моны Тукай белән мөнәсәбәтендә дә күрергә мөмкин. Галимҗан Ибраһимов гомер буе Тукайны читкә тибәрергә тырышып килде. Шул ук вакытта Галимҗан Ибраһимовның үз фикерләре дә бик кызык, үзе дә бик тирән, һәм чын мәгънәсендә талантлы фикер иясе, мәшһүр әдип. Ул чиновник та булып китә берара. Бу шәхесләргә карата менә шушындый киң караш кирәк. Аларның урыннарын дөрес билгеләү зарур. Бездә, кызганыч ки, шәхесләрнең урыннарын билгеләү җитәрлек булмады. Җамал Вәлиди белән сез әле генә танышкан кеше буларак, шаккатып әйтәсез. Мин аны күптән беләидем. Ләкин әсәрләрен бер җиргә җыеп карагач, бөтенләй башка картина ачыла, башка югарылык күренә.

Менә тагын шуңа бер мисал: бездә Һади Атласи бар. Аның «Сөембикә»,

«Казан ханлыгы», «Себер тарихы» дигән китаплары мәшһүр. Алар берничә мәртәбә басылып чыкты. Бу перестройкадан соң да аны тарихчы буларак белә идек. Менә күптән түгел аның әсәрләренең ике томлыгын чыгардык. Беренче томы узган ел чыкты. Анда — тарихи әсәрләр. Ә инде менә быел аның публицистикасын, мәкаләләрен чыгардык. Мин элек тә белә идем ул мәкаләләрнең кайберләрен. Аерым-аерым укыгач, алар арасында бәйләнеш әллә ни сизелми дә иде. Ә менә бу икенче томны чыгарган вакытта Һади Атласи бөтенләй башка югарылыкта, башка шәхес, башка фикер иясе буларак күз алдыма килеп басты. Бик кызык бер мисал китерәм. Ул бит утызынчы еллар башында берничә мәртәбә төрмәгә ябыла, аннан соң сөргенгә җибәрелә. Шул сөргеннән, ачлы-туклы яшәгән җиреннән, апасына язган хатлары бар. Шул хатларын укып, шаккаттым. Анда безнең әдәбиятта моңарчы яктыртылмаган бер ак тап бар. Ул репрессиягә эләккән кешеләрнең үз язмышы, күргән хәлләре турында язылган әдәбиятның җитәрлек булмавы. Ибраһим Салаховның бер повестен исәпкә алмаганда, бездә ул ГУЛАГ темасына, төрмә темасына багышланган әйбер юк иде. Ә менә Һади Атласиның егерме-утыз хатын укып чыккач, сөргендәге татарларның ничек яшәгәнлеге, ни күргәнлеге, ни белгәнлеге — бөтенесе ачык булып, күз алдына килеп баса. Болар менә соңгы томда да бар, Һади Атласига багышланган «Шәхесләребез»дә дә бар иде ул мәкаләләр. Ләкин менә публицистика белән бергә карагач, аның хатлары да публицистик тарихи кыйммәткә килгән. Бу беркадәре минем өчен ачыш та булды, ялт итеп, гөлт итеп, яңа бер шәхес килеп чыкты. Гадәти тарихчы гына түгел, елъязмаларны укып язган тарихчы гына да түгел, ә зур фикер иясе!

Бездә Габдерәшит Ибраһимов бар. Аны, гадәттә, панисламист, диләр. Японнарны мөселман итәргә тырышып йөргән бер әкәмәт-чудак кеше, дип әйтәләр. Чынлыкта исә алай түгел. Ул, Япониягә барып, аларны мөселман итәргә тырышмый, андагы мөселманнарга таянып, Япониядә Россиягә, колониализмга каршы фикер уятырга тырыша. Аның Германиядә чыккан мәкаләләрен табарга туры килде. Һәм ул анда татарлар турында мәкаләләр басу белән бергә, Рим папасына да мөрәҗәгать итә. Халыклар арасында да дини татулык булсын иде, диннән генә чыгып, бер халыкны икенче халык измәсен иде, ди. Безгә менә шул колониаль изелүдән котылырга кирәк, шуңа сез дә ярдәм итмәссез микән, дип Рим папасына мөрәҗәгать итә. Рим папасы моңа нинди җавап биргәндер, анысын әйтүе читен. Ләкин мөрәҗәгать үзе кызык. Аннары икенче нәрсә. 1916 елда, милли хәрәкәт Россиядә бик көчәйгән вакытта, финнар, поляклар, Балтыйк буе халыклары, яһүдиләр, безнең ил мөселманнары да Россиядә хөкем сөргән милли изүгә каршы протест күрсәтеп, бер зур документ эшли. Шул документка поляк, фин, эстон, яһүд, грузин һәм башка халыкларның вәкилләре белән бергә Ибраһимов та кул куя. Империалистик, колониалистик изүгә каршы хәрәкәт була бу. Менә шушы күзлектән караганда, Габдерәшит Ибраһимов, кайберәүләр бездә язганча, әллә нинди панисламист кына түгел, адашып-саташып йөргән миссионер да түгел, ә чын мәгънәсендә халыкара масштабтагы зур сәясәтче булып чына. Габдерәшит Ибраһим да өйрәнелергә тиеш, аның турында да бер әйбәт китап чыгар, дип өметләнеп яшим.

Бездә бик күренекле мәгърифәтчеләр, әдипләр, галимнәр белән бергә татар тормышына зур яңалык китергән эшкуарлар, байларыбыз булган. Мәсәлән, Әхмәт бай. Беренче булып укытучылар өчен махсус мәктәп-мәдрәсә оештыра. Аның энесе Гани бай егерме елга якын менә шушы юнәлештә эшли. Педагогик юнәлештә бөтен Россиядән татар укытучыларын, һәрбер өлкәдән җыеп,

семинарлар, курслар уздыра. Һади Атласиның да, 1902 елны Гани бай оештырган семинарларга барып, беркадәр күзе ачылып кайта. Шуннан соң «Табигать тарихы» дигән махсус китап та яза. Димәк, менә безгә шушы эшкуарлар, хәйриячеләр турында китап язарга кирәк.

Без «Бертуган Рәмиевләр» дигән бер китап чыгардык. Рәмиевләрнең китап, газета-журналлар чыгаруга, мәктәп-мәдрәсәләргә керткән өлеше беркадәр яктыртылды анда. Ләкин бер Рәмиевләр генә түгел, Акчуриннар да, Хөсәеновлар да бар. Гомумән, Оренбургның революциягә кадәрге татар дөньясының бер үзәгенә әверелүендә Хөсәеновларның, билгеле, роле зур. Алар турында да китап чыгарырга уйлыйбыз. Чөнки хәйриячеләр, иганәчеләр дә үзләренең тарихи урыннарын алырга тиеш. Алар да — безнең зур шәхесләребез.

Инде менә шушы көннәрдә зур шәхесләрдән берсе Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанинең эшчәнлегенә караган бер китап чыгардык. [...] Ул китап оригиналь рәвештә, безнең тарафтан язылмады. 1915 елны Газиз Гобәйдуллинның әтисе Салих Гобәйдуллинның иганәсе ярдәмендә, татар галимнәре җыелып, Мәрҗани турында үзләренең фикерләрен, хезмәтләрен яза. Анда дин галимнәре дә, тарихчылар да бар, философлар да бар, ислам юристлары да бар. Йосыф Акчура кебек сәясәтчеләр дә катнаша. Бик зур күләмдә Мәрҗанинең тууына хиҗри ел исәбеннән йөз елга багышланган бер китап чыккан. Хәзер дә бездә мәкаләләр чыккалый, ләкин ул мәкаләләрне язучыларның кайберләре — гадәти публицистлар, кайберләре иске телне, иске чор әдәбиятын җүнләп белмәгән тарихчылар, кайберләре исә берничә китабын гына укып мәкалә язган кешеләр. Ә менә без Мәрҗанине төрле яклап характерлаган унбишенче елгы китапның үзен яңадан бастырырга дигән фикергә килдек. Хәзерге әдәби телгә якынайтып, бастырып та чыгардык. Бу инде Мәрҗани турында үзенә күрә бер энциклопедия, дип әйтергә ярый. Безнең бит күпчелегебез моңарчы динне сүгеп язудан ары китә алмады. Хәзер инде дин белән шаярып, кокетничать итү башланды.

Хәзер дин белән шаярып, кокетничать итү башланды. Белгән-белмәгән килеш дога укыган булып, исемнәрне әллә нинди гарәпчә формага үзгәртеп, мөселманга әйләнү модага кереп китте.

Белгән-белмәгән килеш дога укыган булып, исемнәрне әллә нинди гарәпчә формага үзгәртеп, мөселманга әйләнү модага кереп китте. Ә менә бу китапны язучылар — алар чын ислам тарихын, ислам культурасын белгән һәм иң мөһиме — Мәрҗанинең үзен күргән, аннан дәресләр тыңлаган яки аның белән фикер алышкан, бәхәсләшкән кешеләр. Мәсәлән Баруди, Риза казый Фәхреддин. Шул ук вакытта, бая әйткәнемчә, аның хезмәтләрен тикшерүдә Зәки Вәлиди, Йосыф Акчура кебек дөньяви галимнәр дә катнаша. Алар да бик югары бәя бирә. Бу — чын мәгънәсендә Мәрҗани турында үзенә күрә бер энциклопедик хезмәт.

Менә, егетем, бик сокланып, Җамал Вәлиди турында сөйләдең. Дөрес, сокланырга лаек шәхес. Ләкин Җамал Вәлидидәй шәхесебез — дистәләгән. Революциягә кадәр чыккан вакытлы матбугат арасында «Аң» дигән журнал бар. Чын дөньяви, сәнгатьчә эшләнгән, әдәби журнал. Аның беренче санын Тукай үзенең «Аң» дигән шигыре белән башлап җибәрә. Менә шул журналны чыгарган кеше — Әхмәтгәрәй Хәсәни. Артык бай да булмаган ул, ләкин кулындагы бөтен мөмкинлеген файдаланып, журнал чыгара, «Шәрык клубы»н оештыруда катнаша, язучыларга да ярдәм итә. Тукайны да исән чагында

соңгы күргән кешеләрнең берсе. Әхмәт бай Хөсәенов акчасы белән иганәче булса, Әхмәтгәрәй Хәсәни исә үзенең интеллектуаль белеме, омтылышы белән иганәче булган кеше. Ул идея, фикер бирә һәм оештыра. Аның турында да китап эшләнеп ята.

Узган ел Карл Фукс — татарларны өйрәнеп Европа галимнәреннән беренче буларак объектив һәм нормаль әсәрләр язган кеше турында — «Шәхесләребез» сериясендә китап чыгардык. Янә шундый кеше бар. Татарларга бик хөрмәт белән караган кеше — тарихчы Михаил Худяков. Аңа багышлап та «Шәхесләребез» сериясендә китап чыгарырга ниятлибез. К.Фукс турында китап чыккач, миңа берәү әйтә: «Ул бит татар түгел», — ди. Хикмәт шунда: безгә татармы, түгелме — анысы икенче мәсьәлә.

Н.А.: Барыбер – безнең шәхес.

М.Г.: Ул безгә хезмәт күрсәткән шәхес, безгә үрнәк булган шәхес! Худяков да менә шулай. Исмагыйль Гаспралы турында да без китап чыгардык. Ул да кырым татары. Без аны да сериядә чыгардык һәм ул китапны Кырымда да, Төркиядә дә бик олылап каршы алдылар. Киләчәктә дә татар булмаган, ләкин татарга хезмәт иткән, татарның аңын күтәрүгә өлеш керткән кешеләр турында китаплар чыгарырбыз, дип уйлыйм. Җыеп әйткәндә, эшлисе эшләр бик күп. Һәм бик кызык, гаҗәеп шәхесләр килеп чыга. Әгәр дә менә шул шәхесләребез турында бер җитмеш, сиксән, йөз китапны дөньяга чыгарып булса, тарихыбыз беркадәре дөресрәк кыяфәт алыр иде [...]

Н.А.: Үзеннән-үзе туа торган бер сорау бар. Бу китапларны тарату мәсьәләсе. Аларны милләткә укытырга кирәк. Иң әүвәл зыялыларга, укытучыларга, мөгаллимнәргә, галимнәргә укытырга кирәк. Барып җитәме бу бик тә кирәк булган китаплар?

М.Г.: Четерекле проблеманы күтәрдең син. Бездә бит хәзер китап сәүдәсе дигән әйбер юкка чыга язды. Төрле порнография, эротика белән чыккан китаплар почмак саен сатыла, ә менә үзебезнең милли мәдәниятебезгә караган әйберләр чамалы. Мәсәлән, Казанда хәзер бер генә китап кибете калды. Анысын да идән астына төшкән, дип әйтәләр, подвалга. Районнарда, авыл кибетләрендә китап сату дигән әйбер бөтенләй юкка чыкты. Бу — мәсьәләнең бер ягы. Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Безнең «Җыен» фонды бу китапларны сату белән шөгыльләнми. Без бушлай таратабыз. Хәзер йөз сумга бер шешә аракы алган кешеләр утыз сумга китап алмый. Анысын дә исәпкә алырга кирәк. Шуның өчен без китапларны бушлай таратабыз. Ул китапның берсе генә укылса да, аклана. Без китапларны мең, ике мең, мең ярым тираж белән чыгарабыз. Шуның бер, ике, өч йөзе генә укылса да — ул аклана дигән сүз.

Киләчәктә дә татар булмаган, ләкин татарга хезмәт иткән, татарның аңын күтәрүгә өлеш керткән кешеләр турында китаплар чыгарырбыз, дип уйлыйм.

Китаплар, нигездә, бушлай таратыла: китапханәләргә бирәбез. Милли китапханәгә кимендә илле-алтмыш данә бирәбез. Ул район китапханәләренә өләшә. Казан университетының китапханәсенә бирәбез, ул исә башка китапханәләр белән китап алмашканда җибәрә. Шулай итеп, ул китаплар чит илгә дә барып чыга. Утыз-кырык китапны иң элек шәкертләремә, хезмәттәшләремә, китап ярата торган танышларыма, зыялыларга өләшәм. Аннары мәдрәсәләргә дә бирәбез. Кайбер китапларны Диния Нәзарәтенә бирдек. Мәсәлән, «Мәрҗани» китабын. Татар руханилары җыелган мәҗлестә бер йөз китап бүләк итеп бирдек. [...] Китап сәүдәсе белән без шөгыльләнмибез, ә инде китап белән кызыксынган кешеләр безне таба, үзләре мөрәҗәгать итә. Без, һичшиксез, бернинди каршылыксыз китапларны бирәбез. Киләчәктә дә «Җыен» фондына мөрәҗәгать итсеннәр. Ләкин

бернәрсә бар. «Җыен» фондында өч-дүрт кенә кеше эшли. Аның да берсе — шофёр. Ерактан язган кешеләргә посылка белән китаплар җибәреп торуы безгә бик кыен. Ун посылка җибәргәнче, бер китапны әзерләгән кешегә түләү безнең өчен дөресрәк. Чыгымы да бар. Диаспоралардан татар вәкилләре килгәндә, «Җыен» фондын табып мөрәҗәгать итсәләр, капчыклап китап бирәбез. Рәхим итегез, укыгыз гына. Безнең эшебез хәйриячелеккә корылган, сәүдә итү түгел.

Н.А.: Димәк, сез инде кемнең дә булса матди ярдәменә, менә шушы китапларны чыгару өчен кирәк акчага мохтаж, дигән сүз.

М.Г.: Әйе, без, кул сузып дигәндәй, кайбер вакытларда акча сорап йөрибез кайбер бай оешмалардан, кайбер бай эшкуарлардан. Һәм алар ярдәм дә итә. Китапны бастырган вакытта кемнең матди ярдәме белән чыкканлыгын күрсәтәбез. Менә Һади Атласины чыгаруга ТАИФ акционерлык җәмгыяте ярдәм күрсәтте. Мәрҗанине чыгаруга Түбән Камадан бер химия комбинаты җитәкчесе ярдәм күрсәтте. Һәм киләчәктә дә күрсәтер дип торабыз. Без үзебез акча эшләмибез, без акчаны алып, шул акчага китап чыгарабыз. Монда бер нәрсәне әйтергә кирәк: фондның директоры Фуат Рәфыйков, йөгереп йөреп, менә шушы китапларны чыгарудан канәгатьлек күрә. Ул моның өчен үзенең алган хезмәт хакыннан башка бер тиен дә алмый. Һәм мин дә, редактор буларак та, шул китапларга мәкаләләр язучы буларак та, бернинди гонорар алмыйм, таләп тә итмим. Чөнки, иманым камил, бер ышанычым бар: һәр кеше үз халкына, үз җәмгыятенә нәрсәнедер бушка эшләргә тиеш. Шулвакытта гражданлык җәмгыяте барлыкка килә. Мин шушы максаттан чыгып бу эшне оештырып йөрим һәм бер нәрсәне әйтергә кирәк: шуның аркасында үземнең китапларымны чыгаруны онытып та җибәргәләдем. Мин моны мавыгып эшлим, яратып эшлим, чөнки менә гөлт-гөлт итеп ялтырап, яңа шәхесләр ачыла. Бу — үзе бер шатлык.

Н.А.: Миркасыйм абый, сезгә дә, безгә дә шундый шәхесләрне яңадан, яңаларын һаман ача торырга язсын! Сезгә инде – китапларны әзерләүче, безгә исә – укучы буларак. Аннан соң тагын бер сүз бар иде. Әгәр мөмкин икән, мәшәкать дип әйтмәсәгез, яңа китаплар пәйда булган саен, без тыңлаучыларыбызны алар белән таныштырып, менә шушындый тапшырулар ясап бара алмабызмы икән?..

М.Г.: Минемчә, идея начар түгел. Һәрбер китап хакында аерым-аерым булмаса да, ике-өч китап чыккан саен, тәгаен бу китаплар турында мәгълүмат биреп бару һич тә начар булмас иде.

Н.А.: Димәк, килештек. Болай булгач, Миркасыйм абый, безнең «Татарстан» радиосында да «Шәхесләребез» дигән бер тапшырулар тезмәсе, сериясе барлыкка килә, дигән сүз.

М.Г.: Миннән дә тора, сездән дә тора…

Н.А.: Миркасыйм абый, бик зур рәхмәт. Сезгә исәнлек-саулык, уңышлар теләп калабыз.

М.Г.: Мин дә сезгә уңышлар телим. Шимбә-якшәмбе көннәрендә сезнең радиодагы музыкаль тапшыруларны тыңларга яратам. Нормальный татар җырлары яңгырый. Профессиональ композиторлар язган булса да, халык җырлары булса да. Кайбер теге FMда эшли торган радиоларыбыздагы җыр түгел, әллә нәрсәләрне биреп, башны катыралар… Сезнең шимбә-якшәмбе тапшыруларында, бигрәк тә «Татарстан дулкынында», еракта, читтә яшәүче милләттәшләребезгә багышланган тапшыруларыгызда менә шушы сыйфат саклансын, тагы да югары күтәрелсен иде. Чын музыка, чын сәнгать тансык. Җырның иң хикмәтле сыйфаты профессиональ югарылыктагы тавыштан гыйбарәт. Сезгә дә, тыңлаучыларга да исәнлек, иминлек, саулык, уңышлар телим.

Н.А.: Рәхмәт.

Аудиоязманы басмага
***Диләрә Госманова** әзерләде.*

ТӨРКИ-ТАТАР ТАРИХИ ТЕРМИННАРЫ[1]

Ильяс Мөстәкыймов

БОЛАМЫК (بولاميق)

Аш төре.

«Әдгү барлас такы төшеп, ханга йаглы боламык кылып эчереп, хан үзегә килгәч алып Бохарага, Тимер биккә килеп торыр»[2] (Барлас кабиләсеннән булган Әдгү төшеп, [Туктамыш] ханга майлы боламык пешереп эчереп, хан хәл җыйгач, аны Бохарага, әмир Тимергә алып килде).

БАЙАР (بايار ~ بيار ~ باير), БУЙАР (بويار)

Рус түрәсе. «Боярин» дигән рус терминының төркиләшүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән сүз.

«Ул сукыр байарны безгә бирсәң ирде, йау кылмагай ирдүк»[3] (Ул сукыр баярны безгә бирсәң иде, [алга таба] сугышмас идек).

«Вә йәнә тарих мең дә сиксән йитедә барыс йылында М.хавич Й.лашай дигән байар бистә тигрәсенә кальга суктырды»[4].

КАРЫНДАШ (قرينداش)

Бертуган ага-эне яки апа-сеңел:

«Алчы нуйан, Куба нуйан, Соңкур. Болар коңратларның олугы ирде. Бүртә-Куҗин[5] боларның карындашы ирде»[6].

ЧАПКУН ~ ЧАПКЫН (چاپقون)

Атчабар (гонец).

«Без такы сүзеңезга ынам кылып, олуг чапкунымыз белә олуг намәи һөмайунымыз йазып сез кардашымызга җибәрдүк»[7] (Без дә сүзегезгә ышанып, олуг чапкыныбыз белән падишаһлык хатыбызны язып, сез кардәшебезгә җибәрдек).

ЙАРЛЫГ (يرليغ)

Указ, боерык; хөкем. «Йарлыг» сүзе «йар~җар салу» '[боерыкны, карарны] игълан итү' төшенчәсеннән барлыкка килгән дип фараз ителә.

«Йөресен Миср-у Шамда йарлыгыңыз, тапугда ыргасун күп барлыгыңыз»[8]. (Боерыгыгыз Мисырда һәм Сүриядә [дә] үтәлсен, хезмәтегездә булган күп кешеләр шатлансын).

Башлыча Чыңгыз хан һәм Чыңгызый хөкемдарлар дөньяда үзләрен генә хакыйкый, законлы хөкемдар санаган. Шуңа күрә Чыңгызый ханнар һәм хәтта ханзадәләр тарафыннан язылган һәр документ, кемгә генә язылмасын, боерык саналган һәм «ярлык» дип аталган. Моның инерциясе шактый озак дәвам итә. Билгеле булганча, 1475 елдан Кырым ханнары госманлы падишаһларының вассаллары булган. Шуңа карамастан, Сахиб-Гәрәй ханга 1532-1551 елларда хезмәт иткән төрек кешесе Рәммал хуҗа Сахиб-Гәрәйнең госманлы падишаһына юллаган хатларын да «йарлыг» дип атый. Рус чыганакларында да татар хөкемдарларының хатлары еш кына «ярлык» дип аталган. Хәлбуки, «йарлыг~ярлык» сүзе бу очракларда «хат, язу» мәгънәләренә якын.

«Йарлыг сүзеннән йарлыкаш~йарлыкач»(يرليقاش ~ يرليقاچ)исеме һәм йарлыгамак (يرليغاماق) (ярлыкау, ингам итү) фигыле барлыкка килгән.

---

[1] Дәвамы. Башы алдагы санда.
[2] Тәварихе гөзидә – Нсрәтнамә. – Б.86, юл 1278.
[3] Мустакимов И.А. Два тюркоязычных документа о башкирских выступлениях первой четверти XVIII века // Проблемы востоковедения. – 2011. – № 3. – С.86.
[4] ОРРК НБЛ К(П)ФУ, ед.хр. 1589т, л. 2б.
[5] Бүртә-Куҗин – Чыңгыз ханның олы хатыны.
[6] Тәварихе гөзидә – Нсрәтнамә. – Б.81, юллар 1181-1184.
[7] Материалы для истории Крымского ханства. – С.196.
[8] Zajaczkowski, A. Najstarsza wersja Turecka Husräv u Šīrīn Qutba. – Cz. II: Facsimile. – Warszawa, 1958. – С.14, стк.11.

ЙАР, ҖАР ' (يار, جار)

Яр салу, игълан итү.

«[Амәт-Самәт хан] Яссы Камышта ултырырмын, тип халыкга йар салды»[9].

ЧӘРИГ ~ ЧӘРИК (چريک)

Гаскәр.

«Чәриг» сүзеннән «чәригләмәк» ‘гаскәр тарту, гаскәр белән килү’ фигыле барлыкка килгән:

«Андын соң шаһзадәләр киңәш кылып, ләшкәр берлә чәригләп йөределәр»[10].

Соңрак татар телендә «чирү» формасын алган.

«Андын соң хәзрәти Мир Тимер вәгъдә ирешмәгән өчен орышмай чирүве берлә кайтып, Бохара шәһрегә барырга юнәлделәр»[11].

Сүзнең бу формасы аеруча Кырым ханлыгында таралыш тапкан. Кырым ханнарының ярлык-хатларында вакыт-вакыт «татар» йә «нугай» сүзләрен алыштырып килгән[12]. Хәзерге татар телендә «Кырым чирүе кебек» дигән әйтем бар[13].

ТЕЛ (تل , تيل)

Тел (әсир)

«Азау кашындан үтеп китәркән тел төшеп, телне китереп сорганымызда (*сораганыбызда. – И.М.*)...»[14] (Азау [каласы] яныннан үтеп барганда [кулыбызга] тел эләгеп, телне китереп сораганыбызда...).

ЙӨРЕЛГӘ (يورلكا)

Кырым ханына Рус хөкемдарлары тарафыннан җибәрелә килгән «хәзинә», «тиеш» дигән малларны билгеле урынга барып, рус вәкилләреннән алып хан казнасына тапшыру хезмәтен башкарган өчен Кырым ханының махсус вәкиленә («алмашыр бәгенә») Рус хөкүмәте тарафыннан бирелгән бүләк (?).

«Алмашыр бәге алмашыр йиренә барып акылначай белә кичә күренешләр иткәндә үз бәклек тийешенчә тәмам бер тийеш биреп... бу алмашырда бу йөрелгәләр әксек бирелептер»[15] (Алмашыр бәге алмашу җиренә барып, окольничий[16] белән кичә күренешкәндә, бәклек дәрәҗәсенә тиешле тулы бер тиеш[17] биреп... бу алмашуда йөрелгәләр ким бирелгән).

«Һәр оругның бикләренә хәзинә буйарларыңыз сәмүр вә сусар вә сырт тунлар йөрелгәләр биреп сый вә хөрмәт кылмак гадәте кадимдер»[18]. (Һәр ыруның бәкләренә хәзинә түрәләрегез йөрелгә рәвешендә сәмүр (соболь), сусар (куница) һәм сырт туннар[19] биреп, [аларны] сый-хөрмәт итү борынгы бер гадәт булып килә).

ЙАМ (يام)

Почта станциясе. Монгол империясендәге Үгәдәй хан заманында почта станцияләре челтәре булдырыла. Монгол империясе таркалып, дүрт мөстәкыйль Чыңгызый династияле олыс (дәүләт) барлыкка килгәч тә, аларда бу челтәр эшләвен дәвам итә.

«Бу такы бетелгән бикләр бардылар, тәмам вилайәтләрдә йам багладылар»[20] (Бу телгә алынган бәкләр бардылар, бөтен вилаятьләрдә почта станцияләре челтәрен булдырдылар).

Дәвамы бар. ■

---

[9] Ivanics M., Usmanov M.A. Das Buch der Dschingis-Legende (Daftar-i Čingiz-nāma). – Szeged: Univ. of Szeged, 2002. – [Bd.] I. – S.80.

[10] Тәварихе гөзидә – Носрәтнамә. – Б.142, юллар 2096-2097.

[11] Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер = Жизнь Джингиз-хана и Аксак-Тимура. – Казань, 1822. – Б.79.

[12] Материалы для истории Крымского ханства. – С.26, 228, 238, 245, 336 һ.б.

[13] Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. – 1 том. – Казан, 1989. – 433 б.

[14] Материалы для истории Крымского ханства. Изд. В.В.Вельяминов-Зернов. – СПб., 1864. – С.226.

[15] Материалы для истории Крымского ханства. Изд. В.В.Вельяминов-Зернов. – СПб., 1864.

[16] Акылначай (русчасы: окольничий) – XIII-XVIII йөз башында Рус мәмләкәтендә сарай чины һәм вазифасы.

[17] Тиеш – Кырым ханнарына һәм аксөякләренә Мәскәү һәм Польша-Литва дәүләтләре тарафыннан даими рәвештә җибәрелә килгән бүләкләр.

[18] Материалы для истории Крымского ханства. Изд. В.В.Вельяминов-Зернов. – СПб., 1864. – С.677

[19] Сырт тун – төлке, тиен һ.б. мехлы җанварларның сырт өлешендәге мехларыннан тегелгән тун. Рус чыганакларында «шуба хрептовая» дип килә.

[20] Тәварихе гөзидә – Носрәтнамә. – Б.141, юл 2081.

ВУЛКАНОЛОГ҆ ҺАРУН ТАҖИЕВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Колумб Американы ачкан кебек, Һарун Таҗиев – киң халык даирәсенә вулканнарның табигатен ачкан зат. Һарун Таҗиев (1914-1998) – үз эзләнүләрен дөньяга танызткан мәшһүр галим. Аның җитәкчелегендә һәм катнашында 1940-1992 елларда төшерелгән фильмнар циклы дөньякүләм танылу алды. Әлеге фильмнар җир турындагы фәнгә (геология, вулканология һәм тектоника) багышланган. «Иблис белән көрәшү» исемле фильм телевизорлар каршына, мәсәлән, Франциянең генә түгел, ә дөньяның күп илләрендә яшәүче миллионлаган тамашачыны җыя торган булган.

ВУЛКАН СЕРЕН АЧКАН ТАТАР

Инера Сәфәргалиева

Һарун Таҗиев хезмәт юлын инженер-агроном буларак башлый, аннан геолог һәм тауларны өйрәнүче инженер булып хезмәт итә. Нәтиҗәдә, кыр тикшеренүләренең өлгесен вулканологиягә күчереп, әлеге фәндә чын яңарыш ясый. Һарун Таҗиев, кайнап торган вулкан авызында эзләнүләр алып бару — ачышка омтылган һәр вулканологның турыдан-туры вазифасы, дип исәпләгән. Чөнки аңа кадәр вулканнарны билгеле бер ераклыкта гына өйрәнгәннәр.

Таҗиевның җир йөзендәге дистәләгән актив вулканнарга, шул исәптән Көньяк Африкадагы Афар тирән сөзәк чокырына (анда ике лава күлле, дөньядагы иң эре вулканнарның берсе урнашкан) экспедициясе дә мондый эзләнүләрдә махсус белгечләрнең катнашуы кирәклеген күрсәткән. Кырык ел дәверендә ул, төрле галимнәр төркеме белән эшләп, «тектоник плитәләр» теориясен нигезләгән. Вулканнарның күп кенә физик, химик элементлары, лава күлләренең даимилеге, су асты вулкан атышларының хәрәкәте һәм башка бик күп ачышлары аның табигый һәлакәтләрне кисәтү гамәленә нигез салган…

Экспедиция материалларыннан Һарун Таҗиев 48 кыска һәм тулы метражлы фильм ясаган, 34 китап, төрле фәнни мәкаләләр, монографияләр язган. Аның «Ут эчендәге кратер», «Вулканнар», «Иблис белән көрешү», «Күкерт исе», «Җир калтыраганда», «Су һәм ялкын» кебек фәнни китаплары рус теленә дә тәрҗемә ителгән.

Галимнең актив вулканнар куенында алып барган мавыктыргыч аңлатмалары тәэсирендә укучы һәм тамашачыларда җирнең ошбу бөек серле халәтендә катнашу хисе барлыкка килә. Таҗиевнең вулканнар эшчәнлеге — җирнең кыяфәтен үзгәртә торган геологик күренеш, вулкан газларының океаннар барлыкка килүдәге гадәттән тыш әһәмияте, аларның атмосферадагы, җирдәге һәм су астындагы яшәешкә тәэсире һәм эволюциясе турындагы ышанычлы фәнни мәгълүматлары бүгенге вулканологиянең нигезен тәшкил итә.

Таҗиевның һәрвакыт үз гражданлык позициясе була. Башта ул — Бельгиядә Гитлер басып

алуларына каршы хәрәкәттә яшерен эш алып баручы, шартлатучы. Соңыннан — Франсуа Миттеран хөкүмәтендә табигать һәлакәтләрен кисәтү буенча җаваплы дәүләт сәркатибе. Өстәвенә, ул әле яхшы спортчы да: альпинист, спелеолог, регби һәм футбол остасы буларак та билгеле.

Һарун Таҗиевның улы Фредерик Лавашри китабында әтисенең 1936 елда Берлинда узачак җәйге Олимпия уеннарында Бельгия университеты исеменнән катнашырга чакырылганлыгы турында яза. Ләкин ул үзенең һәм, шул исәптән, коммунистик фикерле әнисенең сәяси карашлары аркасында, бу чакырудан баш тарта. Ничек инде Гитлер иленә барасың?!

Әмма мәшһүрлек өчен актив граждан булу, зур галим, язучы, документаль кино остасы һәм талантлы спортчы булу гына да җитмидер, күрәсең. Французларның аерым хөрмәт-яратуларын казану өчен харизмалы, сөйкемле сөякле, үзенчәлекле кеше булу да зарур. Һарун Таҗиевның данын Франциядәге бары бер-ике галим даны белән генә чагыштырып булыр иде. Алар: танылган галим, океанолог Жак-Ив Кусто һәм фәкыйрьләр өчен «Эммаюс» фондын булдырган аббат Пьер. Бер чорда яшәгән һәм эшләгән әлеге өч шәхес күп еллар дәвамында Франциянең мәшһүр кешеләре исемлегеннән (илле кешедән торган исемлек) төшми. Аларның икесе: Жак-Ив Кусто һәм аббат Пьер — төп французлар. Ә менә Һарун Таҗиевның чыгышы татар морзалары нәселенә барып тоташа.

Һарун Таҗиев 1914 елның 11 маенда Польшада (ул вакытта Польшаның бер өлеше Рәсәй империясе составында була) туа. 1921 елда әнисе белән Бельгиягә күчеп китә. 1953 елда, Франциядә урнашып, 1971 елда француз гражданлыгына ия була.

Ташкентта яшәгән ике туганының балалары Нелли һәм Камил Таҗиевлар белән вулканолог улының дәлилләнгән мәгълүматларына караганда, Һарун Таҗиевның әтисе, Сабир Таҗиев 1884 елда Сәмәркандта туган. Кызганычка каршы, аның турында һәм туган урыны хакында Википедиядә дөрес мәгълүмат урнаштырылмаган. Шунлыктан, бу язмамда якыннары тарафыннан дәлилләнгән мәгълүматларга таяну бик мөһим, дип исәплим.

Бөек вулканологның Ташкентта яшәүче туганнары хәбәр итүенчә, Сабир Таҗиев чыгышы белән борынгы Дашкиннар нәселеннән (нәсел җебе 400 елдан артыкка сузыла). Элек морзалар үзләренә беркетелгән җирләр хисабына патша хезмәтен үтәргә тиеш булган. Шул хезмәттән качу максатыннан, Сәйфетдин һәм Шәмсетдин Дашкиннар Пенза өлкәсенең Краснослободск өязенең Дашки авылыннан Урта Азиягә күчеп килә.

Сәйфетдин Дашкинның (туган елы — 1800) Таҗетдин бин Сәйфетдин Сәйфетдинов (1828(36)-1898) исемле улы туа. Аның Газизә белән (1846-1904 елларда яшәгән, Казан губернасы Шиншар авылыннан Кәрим кызы) никахыннан уллары Сабир туа. Нәтиҗәдә, Сабир үзенә фамилия итеп әтисенең исемен ала.

Танылган вулканолог Һарун Таҗиев, Сәйфетдин Дашкинның оныгы, үзенең килеп чыгышы белән татар кенәзе нәселеннән икәнен белгән һәм бервакытта да онытмаган. Гомеренең соңгы елларында ул әтисенең туган ягын, туганнарын күрү теләге белән Үзбәкстанга да килә. Шул сәфәреннән соң, ул күп серияле «Сәмәркандка кайту» фильмын төшерә.

Сабир Таҗиевның хатыны Зенита Клуптның да әтисе ягыннан татар тамырларына ия булуы ихтимал. Беренчедән, әтисенең исеме Ильяс (бу Бельгия документларында дәлилләнгән). Һарун улының мәгълүматларына караганда, Ильяснең апасы Лола, ә Зенитаның сеңлесе Асия исемле булган. Бу исемнәр — шул чордагы гадәти татар исемнәре. Зенита документларының берсендә әтисенең Польшада туганлыгы турында әйтелә. Сабир үзе дә хатынына Бибизәйнәп

Һарун Таҗиев яшь галимнәр белән экспедиция вакытында

дип дәшә торган булган. Алтын Урда татарлары Польшада XIV гасыр ахырларында төпләнә башлаганлыгы да билгеле…

Икенчедән, әдәбиятчы Зинаида Шаховская үзенең «Набоковны эзләгәндә» дип аталган мәкаләсендә болай дип яза: «…шигырьләрне тәрҗемә итүдә Роберт Вивье һәм аның хатыныннан башка (танылган вулканолог Һарун Таҗиевның әнисе) Бельгия шагыйрьләре һәм ике рус — В. һәм мин тырыштык». Әлеге өзектән Һарун Таҗиевның әнисе икенче иргә кияүгә чыкканлыгы аңлашыла. Бу, әлбәттә, ире — табиб Сабир Таҗиевның 1914 елгы сугышта үлеменнән соң була.

Сабир үзенең яңа туган улын күрә алмагандыр, мөгаен, чөнки улы тугач та дүрт айдан соң ул һәлак була.

Вулканологның Ташкенттагы туганнары үзләренең нәселендә булган күңелсез хәл турында да хәбәр итте. Сабирның үлеме хакында газета битләреннән укып белгәннән соң, олы абыйсы Гәрәй Таҗиев (1865 елда туган) Бакуда үз-үзен атып үтерә…

Мәкаләдә китерелгән фотосурәтләр, документаль материаллар киң җәмәгатьчелеккә моңа кадәр билгеле булмаган дөреслекне ача. Төгәлрәк әйткәндә, вулканология фәненең үсешенә һәм танылуына зур өлешен керткән галим Һарун Таҗиевның килеп чыгышы татар нәселеннән икәнлеген ачыклый.

Фредерик Лавашри фикеренчә, аның әтисе вулкан бомбалары яңгыры һәм вулкан газлары атмосферасында, яшәү белән үлем чигендә бик зур ачышлар ясаган. Бүгенге көндә ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кергән, һәрдаим янып торган Этна вулканы — аның лабораторияләренең берсе булган. Фредерик Лавашри әтисенең фәнни мирасы әле өйрәнелеп бетмәгән һәм тагын бер кат дөньяви танылуга лаек, дип исәпли.

Ә Франциядә яшәүче татарларга бер тәҗрибә ясап карарга тәкъдим итәм. Әгәр бу илдә сезнең чыгышыгыз белән берәрсе кызыксынса, сез аларга Һарун Таҗиев белән бер милләттән икәнегезне әйтегез. Һәм сез бу исемнең биредә бик күпләргә билгеле икәнлеген ачыкларсыз. Һәрхәлдә, инде илле яше тулганнарга… ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

ИЛБИКНЕҢ СОРАВЫ

Илбик әйтте: «Моны яхшы аңладым,
Янә бер сүзем бар, җавап бир тагын.

Кирәкле бер сорау минем өчен ул,
Шунлыктан җавапта игътибарлы бул».

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ СОРАВЫ

Һәм Үгделмеш әйтте: «И, котлы илбик,
Бийне бөек итә һәм данлый белек.

Бийнең урдасы ул — белек, бий үзе,
Белексез булыр кол, нигә кол сүзе?

Сорау җиңел, әмма җавап җаваплы.
Җавапка еш кына бий генә хаклы.

Уңаен бий тотты, миңа авыры:
Төшермә йөкне, и егет-батырым».

ИЛБИК СҮЗЕ

Илбик әйтте: «Мескен сораучы — моңлы,
Үзе белмәгәннән генә сорый ул.

Шуның өчен инде шатлан гына син:
Соравыма җавап бирә аласың».

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ СҮЗЕ

Һәм әйтте Үгделмеш: «И изге түрә,
Ишетү җиңел эш әйтүгә күрә.

Сүзен сөйләгәннәр җанын йончыта,
Тыңлаучы кинәнә һәм нәкъ ул ота.

Ни ди, ишет, күпне күргән ир-егет
(Үзең сөйләми тор, бары тик ишет):

«Күп ишетеп белкә була һәр кеше,
Күп сөйләүдән исә аурый ир башы.

Колак рәхәтлеге генә ул тыңлау,
Сөйләү исә бик еш хәтәр дә була.

Сөйләмәгән сүзең — саф алтынласаң,
Бакырга әйләнер әйтеп ташласаң».

Илбик әйтте: «Бик тә дөрес сөйләдең,
Билеңә бәхетле кәмәр бәйләдең».

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ СҮЗЕ

Җаваптан Үгделмеш: «И илбик котлым,
Миңамы күп кирәк — мин ич бер колмын.

Колның җаны фида — ә илбик исә,
Сөенсен колының кулыннан килсә.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.
** Курсив илә язылган юллар нәкъ оригиналдагыча, тик сүзләрнең фонетик йөзе генә борынгыча.

Ишетсен, әйтим мин үзем белгәнне,
Ә илбик кичерсен хата булганны».

ИЛБИК БИЙЛЕККӘ ЛАЕК БУЛУ ТУРЫНДА

Илбик әйтте: «Инде сүз алыйм үзем.
Ошбу иде минем сораулы сүзем.

Түрәтте бер тәңре Хаува баласын —
Олысын-кечесен, яхшы-яманын,

Белекле-белексез, ярлы һәм баен,
Акыллы-акылсыз, надан гидаен.

Барсына да ярар өчен бу бийгә,
Данлыклы идарә өчен ни кирәк?

Баесын халаек, ил чәчәк атсын,
Изге булсын үзе, илаты артсын.

Хәзинә җыелсын — көмеш, асылташ,
Дошманнар җиңелсен, бетсеннәр тоташ.

Гаскәре күп, көчле булсын куллары,
Сәясәт йөретсен, гыйлем кулланып.

Җәелсен дөньяга атагы-даны.
Үсә торсын коты, һәм күтәрсен аны.

Рәхәт, озак торсын илгә баш булып,
Дөньялыгын тапсын җанын тапшырып».

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ СҮЗЛӘРЕ

Җавабын Үгделмеш болай дип бирде:
«Бик тә авыр сорау күтәрдең, илбик.

Бийлек эшен бийләр үзләре белә,
Канун-заң һәм низам алардан килә.

Тумыштан тәгаен булгач бийлеккә,
Өйрәнер, мөгаен, үзе күреп тә.

Ходай кемгә бүләк итсә бий эшен,
Акыл һәм уш бирә — барча тиешен.

Ходай бий итәргә кемне теләсә,
Шуңа бирер тәүдә дәрт, холык, сәләт.

Бийлек эше инде бийләрнең эше,
Анык яхшы белер бий булган кеше.

Үзегез яхшырак беләсез инде —
Үзең бий, атаң да яхшы бий иде».

ИЛБИК СҮЗЕ

Илбик әйтте: «Болар — сүзнең дөресе,
Тугры сүздән килә җофар, кен[1] исе.

Башкаручы мәшгуль икән эшендә,
Эш сыйфаты ачык күзәтүчегә.

Мин башкаручымын, күзәтүче — син,
Башкаручының син бәялә эшен.

Сиңа Тәңре акыл, уш биргән инде,
Белекле дә булып, тәрбияләндең.

Миңа хезмәт иттең кечедән бирле,
Гаделлек нилеген кечедән белдең.

Бар һөнәрне оттың һәм белдең үзең,
Миңа тугры булды эшең һәм сүзең.

Юньлеләргә әйтә инсан үз сүзен,
Тугры фида итә кешегә үзен.

Тугры булганлыктан сиңа ышанам,
Сүзеңне гел миңа тугры әйтсана

Ни ди тугрылыклы рәхимле кеше
(Тугрылык асылда кешелек башы):

«Тугрыны зирәкләр мактыйлар бигрәк,
Тугрылык һәрвакыт һәркемгә кыйммәт.
Тугры кеше тапсаң, елыш син аңа,
Шулай ди әхлакый гыйлем — тәгълимат».

ҮГДЕЛМЕШ СҮЗЕ

Җавабын Үгделмеш болай дип әйтте:
«Исән-сау яшә, и кулы кодрәтле.

[1] Кен — боланнардан алына торган хуш исле матдә.

Бийлеккә иң тәүдә асылзат кирәк,
Корыч батыр, миргән һәм дә куш йөрәк[2].

Атасы бий булса, углы бий туар:
Угылга төп сыйфат бирә аталар.

Зиһенле булсын бий, белекле, зирәк,
Бийлеккә юмарт һәм юньле зат кирәк.

Белек илә бәкләр идарә итә,
Уш илә ил-көннең эшен йөретә.

Бәк исемен белем генә матурлый,
Белемсез бәк исә исемен хурлый.

Акыллы булсын бий, фәһемле, зирәк:
Гадәттә дошмансыз булмыйлар биләр.

Ни ди, ишет әнә тәҗрибәле ир
(Башыннан кичермеш шау-шулы гомер):

«Белекле булсын бий, уяу һәм ушлы,
Барсын алдан күрә белү тиешле;
Кыланышы һәйбәт, һөнәр — мең төмән.
Аты изге булсын, холкы килешле».

Хаува токымыннан булган олуглар
Белем белән генә бөек булдылар.

Иге булса заты ир иге булыр,
Иге булып алыр ул түрдә урын.

Тәңредән ыек[3] ул бийлек, бий — ару[4],
Арулыгы илә илне коткарыр.

Халык башы алып[5], батыр ир була.
Бөек эш башларлык баһадир була.

Ни ди ишет әнә Үтәгән[6] бәге,
(Аның сүзе — сүзнең акыллырагы):

«Халык бийе бик тә булдыклы булсын,
Теле, күңле төпле, холыклы булсын».

Белекле һәм зирәк, иленә тугры,
Юмарт, ачкүз түгел, һәрьяктан тулы.

Кулыннан килсен һәртөрле игелек,
Ипле-юньле булсын, кылыгы төзек.

Лаеклы бий булсын халыкка олуг.
Аңардан таралсын изге бер ыруг.

Белек белән башлар кеше эш башын:
Фикерләп эшләсә, уңарыр эше.

Халыкны бий белек илә беркетә,
Белеге җитмәсә, фәкать өркетә.

Бу бийләр ялгышса, и котлы илбик,
Билеге чирләр һәм кирәгер табиб.

Аның дәвасы да акыл һәм белем,
Фәһемең илә тап имен, и иплем.

Бий булса белекле, зирәк һәм ипле,
Кырынайган йөкне төзәтер инде.

Белекле һәм ушлы батыр бий — илдар
Ике дөньяда да әҗерен табар.

Ике дөньяда да лаеклы кеше
Никадәр бәхетле һәм котлы кеше.

Бу бапта әйткән бер шагыйрь тапкыр сүз
(Наданга ул гыйлем, сукырларга күз):

«Ачык әйтеп бирик — кемнәр бәхетле?
Кеше арасында кем була котлы?

Ризыгын, мөлкәтен бүлешкән кеше:
Дөнья вә ахирәт аның өлеше».

Кыланышы уңай һәм холкы юньле
Булса, сөенечтә кичәр һәр көне.

Ходай кемгә бирсә иге холыкны,
Иге холык белән изге юрыкны,

[2] Куш йөрәк — фраз. «бик батыр» мәгънәсендә.
[3] Ыек (ыйык, ызык) — «Тәңре тарафыннан» яисә «Тәңрегә җибәрелгән» дигән борынгы сүз; борынгы бер титул буларак та очрый.
[4] Ару — «бик тә саф» мәгънәсендәге сүз.
[5] Алып — баһадир, әкияти батыр.
[6] Үтәгән — төркиләрнең тәүге ватаны.

Нигъмәте чиксез күп аңар дөньяның —
Үзең файдалан һәм өләш калганын.

Ходай фазыйләтен бирсә һәм котын,
Булыр холкы яхшы, кылмышы бөтен.

Иге холык белән һөнәр — мең төмән —
Булса бийдә, илдән китәр чаң-томан.

Ни шәп нәрсә иге хәрәкәтләрең,
Бирер алар иргә бар хаҗәтләрен.

Начар булса Ходай бирмеш холыгы,
Аны имгәтер, вай, замана угы.

Каю бийдә булса тискәре холык,
Сөенеч көткәндә булыр кайгылык.

Фәһемле булсын бий, ару-саф булсын,
Чын асыл зат сафлык өчен омтылсын.

Тәкъва кеше һәрбер囲 эштә сак булыр,
Сак эш иткән бийләр эшен булдырыр.

Әгәр бий булмаса аңлы, саф-сөзген,
Пакьсез булыр барча эше үзенең.

Сабыр карарлылык — бийгә бизәклек,
Гамәлләрен тезә торган үзәк җеп.

Акыл ныклы булса гына эш уңай,
Белеп эш итү дә өстәлсә шуңа.

Акыллыга гына килә эш уңу,
Акылсызны эштән ерак тот һәм ку.

Күңел күзе күрмәс булса, күз — тишек,
Уй-фикер булмаса, булмый эш итеп.

Ни ди илгә күп ел баш булган кеше,
Ихтыярлы, эштә сыналган кеше:

Каю кемдә булса зиһен һәм акыл,
Аны ир дип ата, аны хөрмәт кыл.

Зиһене, акылы төз булган чакта,
Хатасын яшереп, кечене макта.

Нинди яхшы нәрсә акыллы булу,
Бик кирәк акылчан эш итә белү.

Килешми кемгә дә ашык-пошыклык,
Китерер ул бийгә йөзгә кызыллык.

Җиңел акыл, ярсу, юкка пошыну —
Белексез бер надан кеше эше бу.

Ашыгып кылган эш булгалый рәтсез,
Ашыгып ашасаң, аш та ләззәтсез.

Кабаланма һич тә, һәрчак бул сабыр
(Мәгәр намаз-тәгать дигәндә — йөгер)!

Йөзең мөлаем һәм тук булсын күзең,
Ачык-тыныч булсын холкың вә сүзең.

Туемсыз булыр ул күзе сок кеше.
Күзе сокка җитмәс бу дөнья ашы.

Соклык бер аурудыр, юк уты-име,
Аны имли алмас һичбер ил камы[7].

Ни ач булса да ач, ашар да туяр,
Күзе ач ачлыгын үлгәндә куяр.

Комсызлар баемас, сок бер туярмы?
Бөтен ил бай булыр, ә комсыз — ярлы.

Бий булсын ушлы һәм аеруча аңлы,
Аңлы кеше эше булмас зәваллы.

Кемдә булса оят һәм юньле холык,
Ярамас эшләргә озайтмас кулын.

Ходай кемгә бирсә оят һәм әдәп,
Шуңа бирә абруй һәм төгәл дәүләт.

Ярамас эшләргә тышаудыр намус,
Бар изге эшләргә кушадыр намус.

Оят — изге нәрсә, матурлык иргә,
Намус кашмавы[8] — көч изге эшләргә.

Сүзе чын — күңле саф намуслы ирнең,
Илгә хезмәт өчен туа һәр көне.

[7] Кам — «шаман, им-томчы».
[8] Намус кашмавы — гадәттә кызларның кызлыгын белдергән һәм чәч өстеннән киелгән алтын кыршау — монда күчерелмә мәгънәдә.

Әгәр бий күңлендә булса хыянәт,
Файда булмас илгә, андыйга ләгънәт!

Уң булмаса бийнең теле вә холкы,
Ул илдән качарга юл эзләр коты.

Сүзеннән кайтса бий өметеңне өз,
Үкенечкә үтәр гомереӊ шиксез.

Бигүк уяу һәм сак булсыннар бийләр,
Бийләр гафил булса, ил азап чигәр.

Илне тотып торган кыршаулар ике:
Бере — саклык, бере — чын гадел хөкем.

Саграк булган бийләр ныгытыр илен,
Дошманнарны җиңеп, кидерер тезген.

Ни ди, ишет, яучыл егәрле ирләр:
Сак булып егетләр дошманын җиңәр.

И ил башы бәкләр, илбик булсын сак!
Үзегез йөрегез илне багыбрак.

Сак эш итү бийнең хәлен ныгыта,
Гамьсез булу бөтен илне юк итә.

Саклык белән сындыр дошман муенын,
Һәм тәэмин ит халкың тыныч булуын.

Ике шәй илә бий бийлеген бозар,
Кәкер юлга китәр, юлыннан язар:

Берсе — көчлек, икенчесе — гафиллек,
Шулардан таркала халык һәм бийлек.

Әгәр дошман муенын сындырыйм дисәң,
Үзеңнең колагың сак булсын бик тә.

Саклык төзер диләр, гафиллек бозар,
Сакланмаса, гөлләр тик илләр тузар.

Гафил булган бәкләр эшен бетермәс,
Гафил илбик озак хакимлек сөрмәс.

Гафилләрне һәрчак бозадыр зирәк,
Сак дошманга һөҗүм ясалмый кинәт.

Сак илбик дошманнан таптатмас илен.
Яу килсә, майтарыр[9] акыл һәм белем.

Залим дә озак идарә кылмас:
Золымны ил озак күтәрә алмас.

Ни ди, ишет, әнә, белекле сүзен:
«Залим хакимлеге булмас бик озын».

Золым ут ул: тирә-юнен яндыра,
Гаделлек исә су: иген уңдыра.

Озак булсын дисәң идарәң, бөкә,
Гадел заңнар бүләк ит бар ил-көнгә.

Гаделлек илә ил арта, төзелә,
Көчлектән ил кими, дөнья бозыла.

Золымнан бозылды нигә багыстан,
Залимнәр үзләре үлделәр ачтан.

Бийләр күңел биреп гаделлек сөрә
Икән, халык — бийлек нык басар үрә.

Иң начары шулдыр, бәхетле илбик,
Бүтән бийләр әйтсә «ул ялганчы», — дип.

Сүзе чын булса һәм холкы да котлы,
Халык тугры калыр, булыр бәхетле.

Ялганчы кешеләр вафасыз булыр,
Вафасызлар төрле юньсезлек кылыр.

Ни ди, ишет, әнә вафалы кеше,
Вафа ул кешедә кешелек башы.

Теле ялган ирнең җәфа ул холкы,
Җәфа кемдә исә, шул ул нәкъ елкы.

Йөрәкле булсын бий, чын алпар булсын,
Дошман килсә аңар, чын тоткар булсын.

Сү[10] башы ирән, күр, йөрәкле булсын,
Йөрәксезләргә дә үрнәкле булсын.

Куркакка баш булса йөрәклерәк ир,
Йөрәксезләр дә тиз йөрәклеләнер.

[9] Майтару — түбәндә «отпор бирү».
[10] Сү, сүв — гаскәр.

Бу сүзнең исбатын бу баптан укы
(Һәм акылдан-хистән бер кичер тагы):

«Арыслан баш булса этләргә беркөн,
Ул этләр булачак арысланга тиң.
Әгәр арысланга эт булса башчы,
Андый арысланга эт дию мөмкин».

Юмартлык, хуш күңел килешә бийгә,
Салмаклык өстәлсә, шәп була бигрәк.

Юмартлык китерә бийгә ир данын,
Дан исә әхвәлен ныгытыр аның.

Җыелып килерләр азамат ирләр,
Теләге үтәлер җыелса гаскәр.

Ни ди, ишет, урып җыйган батыр ир:
Урып ал, и алпар, һәм гаскәргә бир.

Юмарт бул — бүләклә, ашат һәм эчер,
Җитмәсә, җыеп ал һәм тагын җийдер.

Батыр егетләргә байлык киселмәс,
Матур кош-кортларга җирдә җим бетмәс.

Кылыч, балта, җәя, ук һәм көч, йөрәк
Бар икән, ир затка тагын ни кирәк?

Җиһангир табынмас бар хәзинәгә:
Җибәрсә гаскәрен мал хәзер аңа.

Ил тотарга гаскәр кирәк, сүв кирәк,
Гаскәр өчен кием кирәк, ту[11] кирәк.

Боларны табарга халык бай булсын
Моның өчен дөрес хөкем куелсын.

Бу дүртнең һәрбере алмаштыргысыз,
Бере булмаса да, бийлек булдыксыз.

Тагы биш нәрсәдән бий булсын ерак
(Аты изге булу бийгә яхшырак):

Берсе ашыгычлык, берсе саранлык,
Берсе үч; шул өчтән яшә сакланып.

Дүртенчесе бийгә азгынлык яман,
Бишенчесе яраксыз кыланыш, ялган.

Боларны үзеңә якын кылма син,
Атың ерак, сүзең алдак булмасын[12].

Шунда иң начары азгынлык булыр:
Аның азагы моң — бәхтең юк булыр.

Бу хакта болай дип әйткән бер шагыйрь
(Шагыйрь сүзен тоткан сүзләргә баер):

«Авыр йөк кешегә — ул бозык холык:
Бәйдәге этнеке шикелле кылык.
Дошман кылмаганны азгын зат кыла,
Дошман ул: дошманнан аермасы юк».

Күп ил кулда тотыйм дисәң, и илбик,
Бу өч эшне эшләү кирәк бик белеп:

Уң кул кылыч орсын, гүяки алып,
Сул кулын өләшсен үлҗәдән алып.

Теле исә булсын шикәрдән сөчек.
Шуңа буйсыначак олы һәм кече.

И илбик, күп сыйфат кирәк илбиккә:
Халык мәхәббәте бирелми тиккә.

Көләч йөз, татлы сүз, юньле үз булсын,
Кылмышы шулай ук төгәл — төз булсын.

Күңле йомшак булсын, ә кулы — юмарт,
Шуларга ярашлы рәхимлелек шарт.

Һәртөрле ирдәмлек килсен кулыннан.
Ерак торсын азгын, ярамас юлдан.

Асылда халыктан сайланмыш кеше
Тулы кямил була, һич кимчелексез.

Дәвамы киләсе санда ■

[11] Ту — гаскәрнең төп байрагы, монда күрәсең, күчерелмә мәгънәдә.
[12] Бу борынгы бер мәкаль, күрәсең. Атың ерак — даның еракка китсен, мәгънәсендә.

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

Безнең редакция архивында Татарстан Язучылар берлегенең проза, шигърият, тәрҗемә секцияләренә кагылышлы бер бәйләм беркетмәсе саклана. Әдипләребезнең төрле елларда язган хатлары, ниндидер үтенеч белән Әдәби фонд идарәсенә яисә Язучылар берлеге җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп язган гаризалары да бихисап.
Хөрмәтле укучылар, бу юлы сезнең игътибарны бары тик бер беркетмәгә генә юнәлтергә булдык. Ул – мәшһүребез Әмирхан Еникигә һәм аның «Кунакчыл дошман» хикәясенә бәйле беркетмә.

11 апрель, 1956 ел. Бауман урамындагы унтугызынчы йорт. Татарстан Язучылар союзында проза секциясенең чираттагы утырышы бара.

Утырышта катнашалар: Афзал Шамов, Габдрахман Әпсәләмов, Һава Хөсәенова, Рәйсә Ишморатова, Гөлшат Зәйнашева, Фатих Хөсни, Атилла Расих, Нурихан Фәттах, Сафа Сабиров, Габдрахман Минский, Шәриф Хөсәенов, Р.Шакиров, Халит (*бәлки Гали Халит? – Ред.*), һ.б. Барлыгы – 19 кеше.

Көн тәртибенә бер генә мәсьәлә куелган, ул да булса – Әмирхан Еникинең «Кунакчыл дошман» исемле хикәясен уку-тикшерү.

Хикәяне автор үзе укый башлый. Ул укуын тәмамлауга, әсәр турында фикер алышулар башлана.

Кереш сүзне Атилла Расих әйтә:

– Хикәяне ялыкмыйча тыңладым. Соңгы елларда сугыш темасына язу кимеде. Бу нормаль хәл түгел. Шул күзлектән караганда, бу хикәянең «кире кайтуы» күңелле факт.

Хикәя әйбәт, идеясе дөрес. Безнең сугышчыны колбаса белән, сыр белән сатып алып булмый дигән идея ята хикәядә. Хикәянең формасы да әйбәт. Ләкин эшлисе бар әле: хикәянең күптән язылган булуы телдә бик нык сизелә. Бу хикәянең теле авторның соңгы вакыттагы әсәрләре теленә караганда начар. Кереш өлеш кирәкми. Хикәяне туп-туры сәфәргә чыгып китүдән башларга кирәк. Төп нәрсә – солдатларның немец офицеры белән сөйләшүендә. Фашистларның кабахәтлеген ныграк күрсәтергә иде.

Сүз дилбегәсен Сафа Сабиров кулына ала:

– Минемчә дә кереш өлешне ташлап калдырырга кирәк. Гади совет кешеләренең патриотлыгын тирәнәйтергә кирәк.

Сөйләшүне Рәйсә Ишморатова дәвам итә:

– Хикәяне бик кызыксынып тыңладым. Өлкән солдат образы тулы эшләнгән. Хикәянең ахырын икенче төрлерәк эшләргә кирәк иде. Әсәр, укылып беткәч, шәхсән, миндә ризасызлык тудырды.

Габдрахман Әпсәләмов сүз ала:

– Хикәядә сугышның иң авыр чоры күрсәтелә. Хикәя шушы көе генә сугышның беренче чорын тулысынча күрсәтә алмас. Кешеләрдә борчылу юк. Алар әкертен генә бара да бара. Сугышның авырлыгын ныграк ачарга кирәк. Аннан соң немецлар сугышның беренче көннәрендә бик явыз кыланды. Солдатларның үзебезнең якка чыккач немецларның «кунакчыллыгы» турында сөйләүләре ышандырмый. Хикәя бу килеш чыга алмас. Канәгатьләндермәү тойгысы кала. Кирәкле форма табылмаган.

Афзал Шамов:

— Хикәяне кызыксынып тыңладык. Ул вакыттагы тәртипләр буенча, өч солдат безнекеләр арасында калмас иде. Немецларның ерткычлыгы ныграк күрсәтелергә тиеш, дигән фикергә кушылам. Шушы моментлар күрсәтелсә, әсәр икенче төрле төс алачак. Хикәядә чын сугыш күренми. Шомлы тынлыктан башка берни юк. Монда сугыш бөтенләй икенче яктан күрсәтелә. Хикәянең оста язылган урыннары бар. Ләкин хикәя болай бармый, аны үзгәртергә кирәк. Ничек үзгәртә — анысы авторның үз эше. Өч солдат та яхшы эшләнгән, аларның характерлары бар. Хикәянең теле кытыршы.

Шәриф Хөсәенов фикере исә мондыйрак:

— Габдрахман Әпсәләмов фикере белән мин бик үк килешеп бетмим. Әсәрдә дошманның мәкерлеген күрсәтү төп урында тора. Немецларның ерткычлыкларын күрсәтергә кирәк. Өч солдатның берсен — башлыгын рус итеп бирү — ясалмалык тудыра. Бу хикәя өчен мондый нәрсә һич мәҗбүри түгел.

Һава Хөсәенова:

— Миндә шундый фикер туды: автор бу хикәясен ни өчен язды икән? Мин бөтен тулылыгы белән авторның фикерен аңлап җиткерә алмадым. Автор мәсьәләгә җиңелрәк килгән кебек. Характерларны тарихи җирлектән аерып алып биреп булмый, ә әсәрдәге кешеләр тормыштан аерылыбрак бирелгән. Немецлар монда артык юләр булып күренә, аларның хәйләкәрлеге ышандырып җиткерми. Безнең солдатларның максатлары билгеле түгел, аларның эчке кичерешләре күренми. Безнең солдатларның немец офицеры алдында уйнаган рольләрен ачыклыйсы бар, аларның эчке детальләре аз.

Фатих Хөсни сүз ала:

— Өч егетнең үз-үзләрен тотышлары сокландыргыч. Хикәя шул ягы белән ота. Немецлар гөнаһсыз тәэсир калдыра. Аларны чын йөзләре белән күрсәтергә, ерткычлыкларын, кабахәтлекләрен күрсәтергә кирәк. Ике якның да эчке көрәшен күрсәтүгә басым ясарга кирәк. Хикәя бу хәлендә бармый.

Габдрахман Минский:

— Әсәрне эшләү мөмкинлеге бар. Әсәрнең идеясе — бер якта мәкерле дошман, икенче якта мораль яктан көчле, өстен торган совет солдатлары. Ләкин идея ачыклыгы җитмәгән. Хикәянең соңы эшләнмәгән. Безнең солдатлар үзләрен бик иркен тоталар — курку да юк, берни дә юк, ышандырмый.

Сугыш темасын башладык. Минемчә, безгә бу теманы җанландырып җибәрергә кирәк.

Шуннан соң авторга — Әмирхан Еникинең үзенә сүз бирелә:

— Хикәянең чиле-пешле җирләрен үзем дә ачык күрдем. Чынлап та, хикәя ныгытып эшләүне сорый. Иптәшләрнең фикеренә кушылам. Ләкин әсәрнең идеясен зарарлы дип тапмыйм.

Проза секциясе председателе
Габдрахман Минский.
Секретарь ***Нурихан Фәттахов.***

Беркетмә тәмам. Телгә, сүзгә һәрчак сак караган Әмирхан ага Еники каләмдәшләренең фикерләренә, аларның теләк-тәкъдимнәренә колак салгандыр, дип уйлыйбыз. Хикәясен төзәткәндер, эшкәрткәндер, бәлкем, яңа юллар, яңа күренешләр дә өстәгәндер. Ни булса булган, «Кунакчыл дошман» хикәясе күп тә үтми матбугатта басылган, бераз соңрак әдипнең китапларында да урын алган (әйтик, «Юлчы» китабында).

Беркетмәне укып-тәэсирләнеп, әлеге әсәрне — «Кунакчыл дошман» хикәясен редакция «Әдәби мирас» сәхифәсендә журнал укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәргә булды.

КУНАКЧЫЛ ДОШМАН

Әмирхан Еники

...Тын, буш юл. Әмма күпме вакытка ул буш, күпме вакытка ул тын? Ике көн буена бу юл һәм моның кебек бик күп юллар өстендә, мәхшәр купкандай, ут, төтен, тузан уйнап торды. Коточкыч дәһшәт урынына әверелде, җан өзгеч фаҗигаләр мәйданы булып китте бу якты офыкларга сузылган җәйге ямьле юллар!

Ләкин никадәр генә куркыныч, хәтәр булмасын, ахырда шушы олы юлга чыгарга тәвәккәлләделәр. Чыкмыйча мөмкин түгел иде, болай да өч көн буена кырлар уртасыннан юлсыз-нисез, сай үзәнлекләр буйлап кача-поса килделәр. Инде җитәр, артык түзәр хәлләре калмады, бу билгесезлекнең бер чиге булырга тиештер, ниһаять!

Тузанлы таш юл өстенә килеп чыккач, алар туктап, сүзсез генә юлның көнбатыш очына бераз карап тордылар. Аннан берсе пилоткасының эче белән тирләгән битен сөртте, икенчесе, җиргә тезләнеп, ботинка бавын рәтләде, өченчесе кесәсеннән тәмәке янчыгын чыгарган иде, ләкин чишә башлаган җиреннән туктап, уйланып торды да ни өчендер янчыкны кесәсенә кире салды. Шуннан соң алар юл кырыендагы җәяүлеләр сукмагы белән көнчыгышка таба карап киттеләр.

Көн буе, ут шарыдай, баш түбәсендә әйләнгән кояш аларның тәмам теңкәләренә тиеп беткән иде; гимнастёркалары манма су булган, иңбашларына тир тозы калкып чыккан, ә яңаклары, колак артлары буйлап юл-юл кара тир агып төшкән. Тәнгә азрак җил үтсен дип ахрысы, каешларын билләреннән салып, иңбашлары аша кигәннәр, котелок һәм кружкаларын шул каешларының очына такканнар. Өчесенең дә кулларында каяндыр сындырып алган карама таяклар...

Кемнәр соң бу сәер солдатлар? Аларның берсе — Горький шәһәреннән грузчик Василий, икенчесе — Норлат егете Хәким, өченчесе — Чистай мишәре Талип иде. Нидән соң алар мондый сукбайлар кыяфәтенә кергәннәр?

...Өченче көн сугыш башланды. Гитлер армиясе, совет халкын йомшак урыны өстендә буарга теләгәндәй, безнең илгә таң алдыннан, дөнья иң татлы йокыда чакта бәреп керде. Ә бу өч солдат хезмәт иткән батальон, шушы кабахәт хаинлек эшләнгән көннән бер атна чамасы элек кенә дәүләт чигенә килеп, оборона ныгытмалары төзергә керешкәннәр иде. Бу әле чын мәгънәсендә сугышчан часть та булмый, чөнки солдатлары аның балта, пычкы, көрәк кебек атмый торган кораллар белән генә коралланганнар иде. Хода белсен, корткычлык булганмыдыр инде ул, ләкин чик буенда яткан батальонга коралның чынын, ата торганын төзү эшләре беткәч кенә бирергә вәгъдә итәләр.

Билгеле инде, фашист армиясе үзенең бөтен ут һәм тимер көче белән искәртмәстән бәреп кергәч, батальонның коралсыз солдатлары ихтыярсыз, сарык көтүедәй, тирә-якка сибелеп бетәләр.

Менә шул мәхшәрдән качып котылган чакта бу өч солдат, ничектер бергә туры килеп, шушы газаплы һәм фаҗигале юлларын башладылар. Сугышның беренче сәгатьләреннән үк аларга дошманның никадәр көчле, хәтәр булуын гына түгел, явыз, ерткыч икәнен дә күрергә туры килде. Батальон торган җирдән сигез-ун ки-

Д.Нәүрүзова коллажы

лометрлар чамасы читтә алма бакчаларына күмелеп утырган бер кечкенә шәһәрчек бар иде. Немец авиациясе очып кергәч тә, менә шул бернинди хәрби часть-мазар тормаган, гомумән, бернинди хәтәр сизмичә һәм беркемнән явызлык көтмичә тыныч кына яшәгән шәһәрне ярты сәгать эчендә җир белән тигезләде дә куйды. Кичтән капка төпләрендә оек бәйләп утырган әбиләр, бакча сукмакларында йөгерешеп йөргән нәни балалар йокыларыннан уяныргa да өлгермичә хәрабәләр астында калдылар.

Егетләр кара сөремгә чорналган шәһәрчекне читләтеп уздылар. Шулчакта бер нәрсә аларны бик гаҗәпләндерде: шәһәрдән чыккан юл буенда ара-тирә аунап яткан кеше мәетләре очрый башлады. Кай җирдә бер генә мәет, ә кай җирдә исә берьюлы берничә мәет — хатыны-кызы, бала-чагасы аунап ята иде. Күбесе йөзтүбән капланып төшкәннәр... Нидән бу? Кайбер мәетләрне игътибар беләнрәк карагач, егетләр эшнең серен аңлап алдылар: немец самолётлары шәһәрдән качып котылырга тырышкан бу бичараларны пулемёттан кырып йөргән икән... Шундый мәгънәсез явызлык иде бу, егетләр ни уйлап, ни әйтергә дә белмәделәр.

Хәер, немец авиациясенең никадәр нахал булуын, никадәр мәгънәсез, ахмак эш итүен алар үзләре дә бик тиз җилкәләрендә татыдылар. Шулай, икенче көнне арыш басуы эченнән тар гына юл белән китеп барганда, безнең яктан кайтып килүче ике немец самолётының берсе болар өстенә борылды. Ярый әле Хәким шунда ук моңа игътибар итеп өлгерде. Туктала биреп, ул:

— Егетләр, карагыз әле, бу очлы борын безнең өскә килә түгелме соң? — диде.

Василий күтәрелеп караганда самолёт инде түбәнәя дә башлаган иде.

— Ятыгыз! — дип кычкырды да ул арыш эченә чумды.

Егетләрнең җиргә сеңүләре булды, арыш өстен шаулатып көчле җил исеп китте һәм яман үкереп зур кара күләгә шуып узды. Йомшак камыл төпләренә пулемёттан өзеп-өзеп кенә «тыр-р», «тыр-р-р» иттереп эре пуля тезеп китте. Ләкин тагын әйләнде, тагын арыш өстен өермәләндереп, улап, җирне гаять зур тегү машинасында теккәндәй, тырылдап узды. Үкерә-үкерә ераклашты, югары күтәрелде һәм үз юлы белән китеп барды. Иң элек Хәким, тезләнеп, арыш арасыннан тизрәк башын сузды һәм бик хиресләнеп самолётны озатып калды. Василий торып утырды да, ничек тынычланырга белмәгәндәй, тезләрен кочаклады.

— Вот сволочь, вот подлец! — ди иде ул, башын чайкап-чайкап. — Нишли, ә? Нишли бит, ә! Их-их, нигә болай булды соң әле бу?! — Һәм ярсудан йодрыгы белән җиргә кат-кат сугып алды.

Болар китәргә дип аякларына да бастылар, ә Талип беләкләре белән башын каплаган килеш һаман ята иде әле. Хәким иелеп аның итәгеннән тартты:

— Талип, ни булды сиңа? Тор әйдә!

Талип иң элек акрын гына чалкан әйләнде, аннан терсәгенә таянып кына башын калкыта башлады. Чырай калмаган иде аңарда. Василий гаҗәпләнеп башын селекте:

— Ай-һай, авиацияне бер дә яратмыйсың икән син! Зрә!

Талип нидер әйтмәкче булган иде дә тик калтырануын тыя алмады.

...Әнә шулай котырынды немец авиациясе. Кайсы якка гына колак салма, гөрес тә гөрес җир селкетеп химаясыз шәһәрләрне җимерде, тын авылларны яндырды, тузанлы юллар буйлап төркем-төркем качып баручы хатын-кыз, бала-чагаларны кырып йөрде, хәтта ялгыз кешеләрне куып йөрүдән дә тартынмады. Дошманның шушы оятсызлыгы һәм ерткычлыгы безнең егетләрне иң караңгы, иң газаплы уйларга төшерде. Нигә бу болай? Ничек кенә килеп чыкты соң әле бу? Дошман иркенләп котырынсын, ә син качып-посып, кырлар уртасында адашып йөр, имеш! Я, моңардан да аяныч хәл булырга мөмкинме? Һичшиксез, бу хәлдән чыгарга кирәк иде. Ничек кенә булса да, үзебезнең берәр частьны очратып, шуңа кушылырга кирәк иде. Шунсыз эш харап. Шунсыз алар бетәчәкләр!

Дошман кулына эләгү ихтималы алар өчен хәзер иң зур куркыныч иде. Бу

куркыныч аларга гадәттән тыш сак булырга куша иде. Шунлыктан алар, армыйталмый һаман көнчыгышка таба барсалар да, олы юлга чыгарга җөрьәт итмәделәр. Ара-тирә якын килсәләр дә, анда һаман дошманның үтеп-сүтеп торуын сизеп, читкә тайпылырга мәҗбүр булдылар. Тик менә сугышның өченче көнендә дөнья бераз тынган кебек күренгәч һәм менә болай, өермә күтәреп алып киткән чүп шикелле, кая барганнарын, нишләгәннәрен белмичә йөрүдән тәмам җаннары бизгәч, алар, ниһаять, олы юлга аяк бастылар.

Горький русы Василий ничектер үзеннән-үзе башрак булып танылып өлгергән иде инде, шуңар күрә ул гел алдан бара, ә Хәким белән Талип, тезгенсез җибәргән атлар шикелле, аңардан калыбрак атлыйлар. Алар өчесе дә бик арыганнар, яңаклары суырылган, иреннәре кибеп яргаланган, аякларенә каты төк бәреп чыккан... Эсселектән, туктаусыз килүдән хәлсезләнү өстенә аларны тагын ачлык чынлап борчый башлады. Моңарчы Талипның саклап йөрткән биш-алты шакмак шикәрен суырып, кузгалак чәйнәп, ара-тирә җиләк чүпләп килделәр. Бүген дүртенче тәүлек инде бер локма икмәк капканнары юк, тиздән эчләре арка сөякләренә ябышыр кебек... Тәмәкеләре дә бетеп килә, хәер, ач корсакка тартып та булмый, хәзер үк укшыта башлый.

Алар баралар... Алларында туп-туры сузылып киткән тигез юл. Аның тараеп югалган түренә кадәр күз туктарлык бер генә карачкы да күренми. Бөтен тирә-якта сәер, ят бушлык һәм җансыз тынлык хөкем сөрә. Сугыш әллә бик артта калган, әллә бик алга киткән — белер хәл юк. Әйтерсең, бу бер үлек ара, ник бер җан әсәре сизелсен, хәтта әйләнәдәге табигать тә, коты алынгандай, тып-тын утыра. Солдатларның инде үзара сөйләшәселәре дә килми башлады — бик күңелсез уйларга йотылганнар иде алар.

...Күпмедер барганнан соң, менә бервакытны алар үз артларында тоташ, каты бер гөрелдәү ишеттеләр. Өчесе дә туктадылар һәм артларына борылып, тыңлап тора башладылар. Тигез юлның очындаургылып-ургылып соры тузан күтәрелә иде. Ни галәмәт бу? Тузан таралмыйча юл өстендә асылынып тора, шунлыктан нәрсә килгәнен абайлап та булмый. Ләкин бик яман нәрсә килә, ахрысы, каты гөрелдәү бөтен тирә-юньне тутырып һаман көчәя бара.

Ниһаять, Василий шәйләп алды булса кирәк, шомлы тавыш белән:

— Немец танклары! — диде.

Шунда ук өчесе дә бер-берсенә карадылар: «Нәрсә эшләргә?» Аптырау һәм курку шул секундта ук аларның агарган йөзләренә бәреп тә чыкты. Шулай да югалып калмадылар. Хәким кулы белән сул якка изәп күрсәтте:

— Әйдәгез, йөгерик шунда!

Юлдан дүрт йөз метр чамасы гына читтә, тигез кыр уртасында, кечкенә ап-ак каенлык күренә иде. Шунда йөгермичә бүтән чара юк. Василий, ашыгып:

— Әйдәгез! — диде дә юл буендагы канауга сикереп төште. Төшү белән уң ягында канау аша калын шпаллардан салынган кечкенә күперне күреп алды. Күпер егерме-утыз метр гына читтә иде. Урманга дип омтылган җиреннән Василий, кисәк кенә уңга борылып, иелә-иелә шул күпергә таба йөгерде. Хәким белән Талип та, артларыннан җитеп сукканны көткәндәй, җилкәләрен җыерып, аның артыннан йөгерделәр.

Күпернең эче бик тәбәнәк, кысан булса да, егетләр ничек тә сыйдылар. Сулышын көчкә алган Хәким:

— Ни... нигә монда кердең? — диде.

Василий иң элек бик яман итеп бер төчкерде, шуннан соң гына ачулы тавыш белән:

— Вот голова, тигез кырдан йөгереп кара, — диде. — Пулемёттан бер генә сиптергән булырлар иде.

Талип бизгәк тоткандай дер-дер калтырый иде. Аның калтырануы Хәкимгә бик ямьсез тәэсир итә иде: ахырда, түзмичә, ул терсәге белән Талипның кабыргасына төртеп алды:

— Булмале шулхәтле... ир башың белән...

— Нишлим соң, мин гаеплемени? — диде Талип, елардай булып, һәм аның тешләре бер-берсенә шык-шык бәрелеп куйды.

...Җир тетрәтеп килгән гөрелдәү шундый коточыргыч дәһшәт белән якынлаша ки, тиздән менә аларны бөтенләй йотар, юк итәр кебек иде... Ул да булмый, таш юл сыгылып тора башлады, күпернең калын шпаллары сикерешергә тотындылар, солдатлар өстенә тузан коелды, һәм мотор үкерүе, тимер чыңы, ташлар шыкырдавы дөньяны тәмам күмеп китте.

...Танклар үтәләр.

Бер-ике минут кына булса да шушы галәмәткә чыдап утыр әле! Өстәвенә егетләрнең буш эчләре җир белән бергә туктаусыз селкенә һәм бу нәрсә аларны аеруча газаплый иде. Шыкырдатып тешләрен кыскан Василий эченнән генә танкларны санап утырды. Соңгысы үткәч, тирән сулап:

— Унике... Да... бәдбәхетләр! — диде.

— Дөрес, унике, — диде Хәким дә.

Талипча да шулай булып чыкты. Өчесе дә санап утырганнар һәм өчесендә дә хәзер бер үк авыр, күңелсез уйлар иде: танклар безнең якка таба киттеләр, димәк, алар һаман да немецлар артыннан сөйрәлеп баралар икән әле...

Василий кат-кат башын чайкап куйды:

— Юк, юк. Үзебезнекеләргә җитәбез, җитәргә кирәк. Колбасниклар кулына гына эләкмик!

Танклар шактый кызу ераклаштылар, яман тавыш тирә-якны һаман яңгыратса да, бик тиз тоныклана барды. Шулай да безнең егетләр күпер астыннан чыгарга ашыкмадылар. Исләрен җыеп, үзалларына уйланып, сүзсез генә утыра бирделәр. Ахырда, тавыш тәмам тынгач, Василий урыныннан кузгалды. Бил тиңентен чыгып, сак кына башын күтәрә башлады. Иң элек уңга — кыр ягына карады, аннан акрын гына сулга — юл өстенә борылды. Һәм... менә сиңа кирәк булса: юл өстендә туптуры аңа карап өч немец басып тора иде. Василий һич сискәнмәде, курыкмады, бер хәрәкәт ясамады, ә немецларга карап катты да калды. Күпме дәвам иткәндер бу хәл, тик бераздан гына ул үзенә төбәлгән бер пистолет, ике автомат көпшәсен күреп алды. Аз гына саксыз хәрәкәт — көпшәләр шул секундта ук аңа ут төкерергә тиешләр. Ләкин немецлар үзләре дә аңа бик хәйран булып карап торалар иде. Курку һәм саклык хисеннән бигрәк, онытылып кызыксыну аларны гүя биләп алган иде. Һәрхәлдә, Василий шуны ничектер сизде булса кирәк, күз ачып йомганчы торып аягына да басты. Автоматлар атмый калдылар, чөнки Василий коралсыз иде.

Берни сизмәгән Хәким белән Талип таякларын сөйрәп, күпер астыннан чыктылар да, күтәрелеп тә карамыйча, кагына башладылар. Шушы берни абайламау аларны коткарды — немецлар тагын атмый калдылар. Василийның башында бер исәп тә туып өлгерде: менә шулай өркетмичә генә немецларга якынлашып, кинәт кенә автоматларын тартып алып булмасмы? Тик иптәшләр каушап калмасыннар иде, ничек итеп аларга моны сиздерергә?

Ләкин шул минутта ук Василий үзенең артында ниндидер кеше тавышлары ишетте. Борылып караса, әлеге теге кечкенә каенлыктан боларга таба кулларын болгап, кычкыра-кычкыра тагын дүрт немец килә иде. Бары хәзер генә ул эшләрнең никадәр җитди, хәтәр булуын белеп алды һәм чынлап торып шүрләде. Хәким белән Талип та йөгерешеп килгән немецларны күреп берьюлы агарынып киттеләр, ихтыярсыз, Василийга сыена төштеләр. Шулай да Хәким иптәшенең колагына тиз генә пышылдады:

— Әйдә, чабыйк!

Василий башын бормыйча гына:

— Юл буена кара, — диде.

Хәкимгә борылып карауның кирәге дә булмады, артында дошман басып торганлыгын ул ничектер аркасы белән сизеп алды.

Йөгерешеп килгән немецлар юлга чыкмыйча каналдан шактый читтә туктaлдылар. Аларның берсе юлда торган өч немецка нидер кычкырып әйтте. Шуннан соң өч немецның әлеге пистолет тотканы үзенчә бик әтәчләнеп безнекеләргә нидер кычкырды. Бу бер офицер кисәге булса кирәк, киеме һәм билгеләре бүтәнчәрәк, үзе яшь, йөзе алсу, күзләре зәңгәр... Бөтен торышыннан һәм калкына биреп кычкыруыннан аның сугышны күңелле эш итеп санавы, ә үзенә гел җиңеп йөргән бәхетле егет итеп каравы сизелеп тора иде.

Ул тагын кулын алга сузып, гайрәтләнеп нидер кычкырды. Ә безнекеләр, сүзен аңламагач, аңа тыныч кына тик карап тордылар. Гаҗәеп хәл! Әллә күзләре матур булган өченме, әллә чын офицердан бигрәк артистка охшагангамы, ул безнекеләргә бер дә куркыныч булып күренмәде.

Ниһаять, офицер, канау аша йөгереп чыгып, пистолеты белән алга таба селтәп-селтәп күрсәтергә тотынды. Бу — шул якка атлагыз, дип боеру иде. Безнекеләр аңлап алдылар һәм, канаудан чыгып, күрсәткән якка таба ашыкмыйча гына атлап киттеләр. Офицер алдан төште, ә калганнары, ата казлардай каңгылдашып, арттан ияределәр. Аларның бу яман шаулап сөйләшүләре, һичшиксез, безнекеләр турында иде. Ни сөйләшәләр, — әйтүе читен. Ихтимал, рус солдатының кулында таяк кына, үзе ялангач, үзе аңгыра, йә шулар белән сугышып йөр инде, дип көлүләре булгандыр.

Безнекеләр чынлап торып дошман кулына эләгүләрен аңлыйлар иде. Өчесе дә тыштан болай тыныч кебекләр, ләкин бу минутта һәркайсының да күңелен борчыган үз уе бар иде. Василий, мәсәлән, бертуктаусыз немецлар кулыннан ычкыну турында уйлана. Дошман белән беренче тапкыр күзгә-күз очрашудан ул бернәрсәне бик яхшы сизеп калды: каушамаска кирәк икән. Шуңа күрә ычкына алуларына ул бик өметле карый. Аннан бу колбасниклар артык уяу халык түгел шикелле, шаять, алдап булыр үзләрен, тик җай гына чыксын!

Хәким дә немецларны бик җентекләп күзәтеп бара, ләкин Василий шикелле үк алай ашыгып нәтиҗә ясаудан ерак иде. Киресенчә, пленга эләгү шушыдыр инде, кая илтерләр дә нишләтерләр икән, дип уйлана иде. Талипның исә бар курыкканы үлем булганга, эченнән дога урынына бары бернәрсәне генә кабатлый: атмасалар гына ярар иде!

Каенлыкка җитәрәк, Василий иптәшләренә пышылдап кына:

— Каушамагыз! — диде. — Бөтен сорауларга җавапны үзем бирәм, ә сез мин әйткәнне кабатлап кына торырсыз!

Егетләр дәшмәделәр.

Каенлык авызында аларны кулларын артка куеп, аякларын аера төшеп басып торган озын, чандыр немец офицеры каршы алды. Бу кечкенә җанвардан булмаска тиеш иде. Башында аның алгы чите иләмсез текә күтәрелеп торган фуражка; шунда тигез канатларын туп-туры җәйгән ак бөркет эмблемасы беркетелгән... Өстендә тар погонлы, яшькелт-соры френч, аякларында — краги белән кара ботинкалар, билендә — портупеялы каеш, шуның сул ягында — зур пистолет кобурасы...

...Безнең өч солдат менә шул, кадап куйган казыктай, тик кенә торган немец алдына килеп бастылар. Алып килүче купшы офицер күкрәген киереп, кулларын бот буена сузып, кызу-кызу гына нидер әйтте, ә тегесе чак сизелерлек итеп кенә башын селкеп куйды. Шуннан соң ул үлекнекедәй яртылаш йомык хәрәкәтсез күзләре белән безнекеләргә төбәлде. Өч солдатның эченә берьюлы салкын йөгерде:

юк, бу ата фашисттан рәхим көтеп булмый иде. Озак карап торды немец өч солдатка, бигрәк тә Василий чыраена «мәхәббәте» төште булса кирәк, иләмсез күзләрен озаклап аңа текәде. Ә Василийның калын иренле, зур авызлы, җәенке борынлы чырае чыннан да гаҗәеп серле иде: ягъни ул чырайда искиткеч ваемсызлык җәелеп ята, шуннан башка берни юк. Кем алдында басып торганын беләме ул, борчыламы, куркамы — һич сизеп булырлык түгел, шайтан алгыры!

Шулай аптырабрак калган немец, ниһаять, ташка баскандай ачык, тимердәй салкын тавыш белән саф русча:

— Сез бөек Германия армиясенең кулына төшкән әсирләр, шуны беләсезме? — дип сорады.

Немецның болай саф русча дәшүе егетләрне бик гаҗәпләндереп җибәрде. Ләкин Василий бер кереп алган кабыгыннан ничек тә чыкмаска тырышты: сыңар иңбашын җыерып, исе китмичә, ялкау гына:

— Күрәбез, — диде.

Әйе, менә шулай һичнигә исе китмичә, ваемсыз булып күренү аркасында гына ул үзен дошман капризыннан бәйсез тота алачак. Бу хәзер аңа бик ачык иде.

— Коралларыгыз кайда? — дип сорады немец.

Василий кулындагы кәкре таякка карап, көрсенеп куйды.

— Менә шушы инде...

Немец авызының бер кырые белән генә елмайгандай итте.

— Совет армиясен без шәбрәк коралланган булырга тиеш, дип уйлаган идек.

— Шәбрәген алырга өлгермичә калдык шул, парин! — диде Василий, үз ишенә әйткәндәй, гаҗәеп бер тәкәллефсезлек белән.

— Ә нинди частьтан сез?

— Әллә тагын... Белә алмый калдык.

— Ничек белә алмыйча калдыгыз?

— Шулай... Кич белән генә килеп төшкән идек, иртән чигенә башладык.

Немец тагы да кысыла төшкән күзләре белән Василийга бөтенләй кадалды: «бу мужик» дөресен әйтәме, ялганлыймы? Ә Василий, рәхим ит, кара, дигән төсле, сыңар төген дә кыймылдатмыйча, тыныч кына басып тора. Җитмәсә, теш арасыннан «чырт» иттереп төкереп тә куйды. Немецның нечкә иреннәре кысылып, яңак сөякләре уйнаклап алды. Әгәр ул Василий чыраенда санга санамау шикелле берәр нәрсәнең чаткысын гына сизеп калса да, перчаткасын салып тормастан «мужикның» ияк астына берне кундырыр иде. Ләкин ник бер андый нәрсә сизелсен. Хәтта пошыну әсәре дә юк. Менә тип!

Шуннан соң ул кечкенә тынгысыз күзләрен Хәким белән Талипка күчерде. Хәким, офицерның барлыгын да онытып, каядыр читкә карап тора иде. Ул үзенә төбәлгән авыр карашны тойды, ләкин башын бормады — гүя нидер күреп исе киткән... Ә Талип, намазга оеган мөселман шикелле, кулларын кендеге өстенә куеп, җирән керфекләрен җиргә терәп, тик кенә тора. Әллә уяу, әллә йокыга талган — белмәссең дә.

— Кая барасыз? — диде офицер, аңа төбәлеп. — Мин сездән сорыйм!

Талип, сискәнеп, башын күтәрде, күзләрен йомгалап алды:

— Ә?

— Идиот, — диде офицер, йөзен чытып.

Василийга эшне җайларга кирәк иде, немецны һич ярсытырга ярамый. Башта җилкәсен кашыган булды, аннан кыенсыныбрак:

— Кая булсын инде, — диде, — үзебезнең якка таба бара идек.

— Ни өчен үзегезнең якка?

— Хатын, семья, өй шунда бит, — диде Василий, авыр сулап.

Офицер кинәт елмаюга охшатып тешләрен ыржайтты:

— Әһә, хатынны сагындыгызмыни, сугышасыгыз килмимени?

Василий бик аз гына көттереп торды һәм йөзен офицерга күрсәтмәс өчен башын түбән иеп әйтте:

— Бездә берәү дә сугышырга теләмәгән иде…

— А-а-а! — дип сузды немец, аннан «так… так…» дип торды һәм шул минутта аның башында гаҗәеп оригиналь бер исәп туды. Еракка төбәлгән бик мәкерле исәп иде бу. Барыбер аның бу «хайваннарны» куяр урыны да юк, тылга-мазарга озатырга артык кешесе дә, вакыты да юк. Ә совет армиясен җимерер өчен ни эшләсәң дә ярый — фюрерның әйткәне шулай! Ләкин… башта сынарга кирәк үзләрен, күнәрлек булмасалар, «расходка җибәрү» беркайчан да соң түгел.

Немецның ничектер берьюлы карашы да, тавышы да «йомшарган» кебек булды.

— Ашыйсыгыз киләме? — дип сорады ул кинәт.

Егетләрнең колаклары торды: бусы ни тагын? Мыскыл итүеме? Ләкин Василий шул минутта ук балаларча беркатлылык белән:

— А как же… килә! — диде. Ул хәтта чынлап авызына килгән суны да йотып куйды.

— Ну утырыгыз! Без хәзер сезне сыйлыйбыз.

Һич икеләнү күрсәтмичә, иң элек Василий, аның артыннан Хәким белән Талип яшел чирәмгә утырдылар, таякларын яннарына сузып салдылар…

…Алар ач иделәр, ашау сүзен ишетүгә аларның башлары әйләнеп китте, авызларына өзлексез төкерекләре килә торды… Ләкин алар офицерга ышанмыйлар иде, икмәк урынына берәр әшәке мыскыл белән сыйлар дип шомланалар иде. Хәкимнең Василийга бераз ачуы да килде: «Нигә әйтте, нигә баш тартмады», — дип ачынып уйланды ул. Василий үзе дә офицердан бернинди дә изгелек көтми иде, әмма ул бөтен эшен бер теләк — дошманны алдап булмасмы дигән теләк белән эшли иде. Шуның өчен дә ул үзенең каушау белмәс беркатлы ваемсызлыгын ничек тә сакларга тырыша иде. Дөресен генә әйткәндә, аның үзен-үзе болай тотуы бик табигый рәвештә иптәшләренә дә йогып өлгерде.

Немец Хәкимнәрне алып килгән әлеге яшь, чибәр офицерга нидер кушты. Анысы, тиз генә борылып, агачлар арасына кереп китте. Һәм озак та тормый аннан пергаментка төргән өч кисәк нәрсә китереп безнекеләрнең алдына салды.

— Ашагыз! — диде немец.

Безнекеләр дүрт кырлы каты әйбернең пергаментын ерттылар: алар кулында чыннан да икмәк иде. Немецларның сугыш өчен махсус алдан әзерләп куйган поход икмәге. Шуңа күрә таш кебек каты да икән ул. Безнекеләр, көч белән сындырып, тәмләп ашарга тотындылар.

Бу вакытта аларны зур гына төркем немец солдатлары уратып алганнар иде. Шаккатып безнекеләргә карап торалар. Безнекеләр дә утырган җирләреннән, икмәкләрен чәйни-чәйни, немецларга бик игътибар белән карыйлар. Шушы икән инде ул бәйдән ычкындырып җибәрелгән өер! Ватып-җимереп, яндырып-көйдереп, кырып-бетереп килүче «батырлар»! Әйтәсе дә юк, карап торырга бик шәпләр. Бары да сугым малыдай көрләр, баштанаяк өр-яңадан киенгәннәр, коралның да яңасын асканнар, шуның өстенә кәефләре дә шәп булса кирәк: авызлары колакларына кадәр ерылган…

Тик аларның бу елмаюларында ниндидер аптырау чагыла: җирдә ашап утырган өч коралсыз солдатның бу кадәр пошымсыз булуларын, бу кадәр тыныч карауларын ничек аңларга? Тар-мар ителгән армиянең пленга төшкән солдатлары шулай булырга тиешме? Әллә алар үзләрен җиңелгәнгә, беткәнгә санамыйлармы? Гаҗәп, бик гаҗәп!

Егетләрнең авызыннан күзен алмыйча карап торган немец:

— Аракы эчәсезме? — диде һәм, аларны шикләндермәс өченме, әйтеп куйды:

— Руслар бит аракы эчәргә яраталар.

Василий, аңа җавап бирмичә, Хәкимгә борылды:

— Аким, эчәбезме?

Бик четерекле сорау иде бу Хәким өчен… Алар хәлендә ач корсакка аракы эчү — бик хәтәр бит ул. Ләкин немецның икмәген ашап та аракысыннан баш тарту килешерме, дошманны шикләндермәсме?.. Василий нинди җавап көтә икән соң?

Хәким икмәген чәйнәп йоткан арада шуларны уйлап алды да тәвәккәлләп:

— Печтек кенә эчсәк тә ярый, — диде.

Василий немецка башы белән ымлады:

— Сал, булмаса!

Немец биленнән чехоллы флягасын алып, шуның сырлы капкачына аракы салып, Василийга сузды. Василий сүзсез генә капкачны алды, кул сырты белән авызын сөртеп куйды. Аннан аскы иренен чыгара төшеп, аракыны ипле генә салып та җибәрде. Шунда ук аның эчәгеләре буйлап ут йөгерде, ләкин ул чыраен да сытмады, капкачны немецка кире сузып, ашыкмыйча гына икмәген иснәргә тотынды. Офицер Хәкимгә салып бирде. Хәким да сырлы капкачны кулына алу белән, башын чөеп, этеп җибәрде, «әһ» тә димәде, тик төкереп кенә куйды. Аннан Талип үз өлешен алды. Аның куллары калтырый иде, шуңа карамастан егет, иске гадәт буенча, капкачны оста гына авызына каплады. Егетләрнең аракыны эчә белүләре немецка ошады булса кирәк, кечкенә күзләре, караңгыда утырган мәченекедәй, елтырап китте.

— Браво, браво! — диде ул, юка иреннәрен ерыр-ермас.

Аның әйләнәсендәге солдатлар да үзара шаулап, көлешеп алдылар. Немец әлеге икмәк китергән чибәр офицерга тагын нидер кушты. Чибәр офицер тиз генә агачлар арасына кереп китте дә бераздан колбаса, сыр, бизәкле кәгазьгә төргән тагын нәрсәләрдер күтәреп чыкты. Немец ымлавы буенча ул шуларның барысын да егетләр алдына китереп салды.

— Ашагыз туйганчы, — диде немец.

Безнекеләр, рәхмәт әйтеп тормыйча, алларына төшкәнне бик эшлекле кыяфәт белән ипләп кенә сыпыра бирделәр. Ләкин, карчыга кебек, күзен алмыйча, карап торган немецка һәм шаккаткан солдатларга һич игътибар итмичә ашап утыруы алар өчен җиңел эштән түгел иде. Чөнки немецка энә очы кадәр дә ышанмыйлар, чөнки бу өрәкнең, кирәксә, шушы минутта ук, аларның эчләренә икмәк биргән кулы белән бер уч пуля җибәрә алачагын белеп торалар. Гомумән, немецның мәкерле ният белән сыйлавы алар өчен көн кебек ачык иде. Моны хәтта немец солдатларының чырайлары ук әйтеп тора: янәсе, офицерлары бу өч «русиш» өстеннән бик оста «шуклык» эшли, ә алар шуның нинди эффект белән бетәсен алдан ук сизеп, тәгәрәгәнче шаркылдарга әзерләнеп торалар. Кыскасы, тычканга үлем, мәчегә көлке!

Менә офицер әлеге сырлы капкачка тагын аракы салып, бер сүз әйтмичә, Василийга сузды. Василий сүзсез генә алды, эчте, кире бирде. Аннан бер сөйләшү булсын дип, офицердан сораган булды:

— Сезнеңчә аракы ничек?

— Безнеңчәме?.. Шнапс.

— Шнапс?.. Аким, онытма, немецлар аракыны шнапс дип атыйлар икән.

Хәким җитди генә:

— Ярар, онытмам, — диде. Василий елмаймас өчен тамак кырып куйды.

Ашап беткәч, егетләр кайсы учы, кайсы җиңе белән, әйбәтләп авызларын сөрттеләр; Талип итәгенә төшкән валчыкларны да чүпләп капты. Офицер галифе кесәсеннән көн тышлы портсигар чыгарып алга таба сузды да янып торган яшькелт төймәсенә басты: портсигар капкачы Василийның борын төбендә үк ачылып китте.

— Уйлыйм ки, моңардан да баш тартмассыз?

— Папирос?

— Сигарета!

Василий берсен алып, ашыкмыйча гына ике бармагы белән угалап, авызына капты. Кесәсендә шырпысы булса да, ул, аны чыгармыйча, офицерның яндырып тәкъдим итүен көтә башлады. Офицер, Хәким белән Талипка да сигарета биреп, тизрәк икенче кесәсенә тыгылды. Аннан ялтырап торган кечкенә бер әйбер чыгарып кабыргасына баскан иде, капкачы ачылып, гөлт итеп ут кабынды.

— Рәхим итегез!

Василий, курыккан булып, башын артка каерды һәм гаҗәпләнеп сораган булды:

— Нәрсә бу?

— Курыкмагыз, автомат зажигалка.

— Ә-ә-ә... зажигалка!.. Шәп нәрсә икән.

— Да... Безнең һәрбер солдатта бар ул.

— Кара син аны!

Василийның офицерны бераз шаяртасы килә иде, ничек кенә булмасын, ач корсакка эчкән аракы кәефен күтәреп җибәрде. Ләкин бу иблиснең күзләре шундый очлы, хәзер үк шаяртып маташуыңны сизеп алуы бар. Аннан — бетте баш, пешермичә тереләй ашар! Юк, саксыз кыланырга ярамый, ярамый... Һәм Василий яңадан үзенең кабыгына керде, гаҗәеп бер мәнсезлек белән авызын зур-зур ачып иснәргә тотынды. Иптәшләре дә аның үз ише — Хәким терсәгенә таянып кырын яткан килеш тәмләп кенә Истанбул сигаретасын тарта, ә Талип үлән сабагы чәйнәп утыра иде.

Офицерның безнекеләргә вакыты-вакыты белән җен ачулары кузгалып китә иде ахрысы, тик торганнан яңак сөякләрен кыймылдата башлый ул... Чыннан да, мондый сансызлыкка түзәргә кирәк бит. Ләкин немецның бик шәп планы бар, шуның хакына «русишны» аракы, сигарета белән сыйлап, тәмәкесенә ут тәкъдим итәргә туры килде, инде авыз тутырып иснәвенә генә түзәрсең.

Ниһаять, ул, ашау-эчүне йомгакларга теләп, егетләрдән сорады:

— Йә, канәгатьме сез?

— Ничево, әйбәт булып калды, — диде Василий, сигаретасының көлен бармагы белән кагып.

Офицер аның йөзенә текәлде.

— Инде нишләргә уйлыйсыз?

«Башлана!» дип уйлады Василий эченнән, ләкин сорауны аңламаган булып, үз нәүбәтендә офицерга туп-туры карады.

— Мин сездән, бездә каласызмы яки кире үзегезнекеләргә китәсезме, дип сорыйм, — диде офицер.

Сорау гаҗәп аңлаешлы иде.

Безнекеләр уенның инде беткәнен, шушы сорауга ничек дип җавап бирүдән язмышлары хәл ителәчәген яхшы сизеп алдылар. Ләкин алар тыныч гамьсезлекләрен бер генә секундка да җуймадылар һәм утырганы — утырган, ятканы — яткан килеш кала бирделәр. Тик Василий гына алдын тәмәке төтене белән тутырды. Офицерның тел төбе кая барганын белергә теләп, ул вакытсыз сүзгә керешүдән ничек тә тыелырга тырыша иде.

Һәм офицер, егетләрдән җавап көтеп ала алмагач, тагын үзе сүз башларга мәҗбүр булды. Ул, бу мәхлуклар куркалар ахрысы, дип уйлап, үзенчә мөмкин кадәр йомшаграк булырга тарышты.

— Без көчләмибез, без сезнең ихтыярыгызга куябыз, — диде ул, перчаткалы кулын суза биреп, — әгәр каласыз икән, пожалысты, рәхим итәсез... Безнең солдатларның азыкларын күрдегез. Алар бездә шоколад ашап, сигарета гына тартып йөриләр. Каласыз икән сезгә дә шулай булыр. Колбаса, сыр, май гына ашап торыр-

сыз. Аракы — теләгән кадәр, эчә генә күрегез... Ну... әгәр китәбез, үзебезнекеләргә кайтабыз дисез икән, пожалысты, тоткарлык юк, китәсез. Аңлыйсызмы, без көчләп тотмыйбыз.

— Аңлыйбыз, — диде Василий һәм сигаретасының очына төкереп шактый еракка ыргытты.

Әйе, офицер бик аңлаешлы итеп сөйләп бирде. Немец солдатлары арасында русча аңлаучылар булды, күрәсең, алар кызу-кызу гына иптәшләренә нидер әйттеләр, аннан барысы берьюлы шаулашып алдылар. Тынгач, безнекеләрнең «кызыклы» җавабын ишетер өчен бөтен чырайлары белән түземсезлек күрсәтеп, көтеп тора башладылар.

...Егетләр өчен хәлиткеч минут килеп җитте. Хәзер инде җавапны бирергә һәм бирә белеп бирергә кирәк иде. Офицер, бу җавапны бары Василийдан көткән шикелле, мәкерле сынау карашын аңа төбәде. Кинәт Василийның йөрәгендә рәхимсез ярсу кузгалып куйды, немецның озын, үлек битенә: «Без колбасага сатылучылар түгел!» — дип яман кычкырасы килде, ләкин... башын салмак кына Хәкимгә борды. Һәм гади генә итеп:

— Я, Аким, нишлибез? — диде. — Господин офицер, әнә, калсагыз да ярый, китсәгез дә була, ди.

Кырын яткан Хәким, дошман офицерын бар дип тә белмәгән гаҗәеп бер мәнсезлек белән шунда ук әйтеп тә салды:

— Бәй, нишлик монда, конешно китәбез!

Василий эченнән дустына «молодец!» диде дә Талипка борылды.

— Ну, Талип, китәбезме, калабызмы?

Талип Хәким кебек артист түгел, ләкин, гел иптәшләренә сыенып яшәргә өйрәнгәнгә күрә, үзеннән-үзе килеп чыккан табигыйлек белән:

— Мин сездән калмыйм, — диде.

Василий акрын гына урыныннан кузгала башлады.

— Киттек алайса, дуслар!.. Торыгыз! Шулай, господин офицер, без китәргә булдык.

Офицер мәгънәле генә итеп немецча:

— Зер гут! — дип куйды.

Немец солдатлары хәрәкәтсез, тып-тын торалар. Бу шомлы бер минут иде, гүя, менә хәзер, нидер булырга тиеш. Безнекеләр шул хәтәрне ничектер тиреләре белән тоеп, ләкин һич каушау әсәре күрсәтмичә, җирдән таякларын алдылар.

Иреннәрен кысып, озак дәшмичә торган офицер, ниһаять, телгә килде.

— Яхшы, мин сезне җибәрәм, ләкин бер шартым бар, — диде һәм башы белән ымлап үзе артыннан иярергә кушты. Безнекеләр иярделәр.

Солдатлар төркеменнән читкәрәк китеп туктагач, офицер егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә карап, һәр сүзенә басым ясап, акрын гына сөйләргә тотынды:

— Күрәсез, мин сезне тотмыйм... Хәзер китәрсез, ләкин шартым шул: анда, үзегезнекеләр янына кайткач, монда күргәннәрегезне солдатларыгызга әйбәтләп сөйлисез. Безнең, ягъни бөек немец армиясенең, сезне ничек яхшы каршы алуыбызны, ничек ашатып-эчертеп җибәрүебезне сөйләп бирәсез. Нәрсә ашап-эчүегезне яшермичә сөйләгез: колбаса, сыр, булки, главное — аракы! Исегездә тотыгыз: большевиклар белән еврейләрне яклаудан баш тартып безнең якка чыккан һәрбер рус солдатын без шулай каршы алачакбыз. Менә шуны яхшылап үзегезнекеләргә төшендерегез. Әйтегез, сугыш тиздән бетә, немецлар Мәскәүгә барып җиткәннәр, диегез. Безнең солдатларны күрдегез ич! Кораллары бик күп, бик шәп киенгәннәр, бик таза ашыйлар — барыбер безне җиңәчәкләр, диегез... Аңладыгызмы?.. Ләкин бездә булуыгызны командир һәм комиссарларыгызга белдерә күрмәгез. Аларга ләммим, югыйсә харап булырсыз. Бары солдатларга гына сөйләгез. Аңладыгызмы?

Офицер сөйләп беткәнче Василий башын иеп торды. Ул белә: әгәр күтәрелеп караса, дошман тырнагыннан ычкыну булмаячак. Бу минутта тынычлыкны саклау аның өчен тау күтәрүдән дә авыррак иде. Шулай да ул шик тудырмаслык нык тавыш белән:

— Аңладык! — диде.

Офицер, Талип белән Хәкимгә карап, кабатлап сорады:

— Аңладыгызмы?

Талип, аңлаганын белдереп, тиз генә башын селекте, Хәким исә бер сүз дәшмичә калды.

Әллә офицерның күңелендә берәр шик кузгалды, ул тагын егетләргә авыр сынау карашы белән текәлде.

— Мин әйткәннәрне сөйләрсезме?

— Түкми-чәчми барысын да җиткерербез, господин офицер, тыныч булыгыз! — диде Василий чегән өлгерлеге белән.

— Яхшы, барыгыз алайса! — Һәм офицер салмак кына кулын селкеп куйды.

Безнекеләр борылып киттеләр, ә хәйран булып урыннарында каткан немец солдатлары, бер тавыш чыгармыйча, алар артыннан карап калдылар.

Аз гына киткәч тә Василий иптәшләренә пышылдап әйтте:

— Артыгызга борылып карыйсы булмагыз!

Талип бер дә борчылуын баса алмый иде.

— Арттан атмаслар микән?

Хәким аңа ачу белән карап, кискен генә:

— Курыкма, ахмак! — диде.

Бераз китә төшкәч, Василий авыз эченнән нидер мыгырдана башлады. Аның йөзе кызарып бүртенгән, муен тамырлары калкып чыккан иде. Ул каты итеп кулын йомарлый һәм туктаусыз төкеренә, әйтерсең, «кунакта» ашаган сыйлардан күңеле болгана… Менә Талип алгарак чыгып, кызурак атлый башлагач, ул кычкырудан чак тыелып:

— Кая чабасың, анаңның… — диде һәм рессорлы тарантаста баргандай, тибрәтеп-тибрәтеп, биш-алты катлы итеп сүгенеп җибәрде.

Шуннан соң Талип алга чыкмас булды. Василий исә юл буена ачынып сүгенүдән туктамады:

— Ах бәдбәхетләр, ах сволочьлар!.. Нинди арзан сатып алдылар, ә?

Хәким аңа борчылып карап алды:

— Нигә бу хәтле тузасың, Василий!.. Ашадык та качтык, кемнең аларга сатылганы бар.

Василий авызының бер як чите белән генә зәһәр елмайды:

— Шул гына калган иде. Их, Аким, Аким, мәнсез кеше син… — Аннан, гердәй йодрыгын яртылаш күтәреп, салмак кына селкеп барды. — Ну, ничево… фашист актыгының «сыен» онытмабыз без… Кулга корал гына алыйк, унлата кайтарырбыз!

***

Бу вакыйганы миңа 1945 елның язын госпитальдә ишетергә туры килде. Сөйләүче — палатадагы күршем сугыш дәвамында алтынчы мәртәбә яраланып госпитальгә кергән әлеге шул Норлат егете Хәким булды. Ул көннәрдә кызыклы да, гыйбрәтле дә булып тоелды бу вакыйга, чөнки безнең армия фашистларга каршы Берлинның үзендә соңгы, каты сугыш алып бара иде инде. ■

1945

Редакциядән: хикәя Әмирхан Еникинең Татарстан китап нәшриятында 1958 елда дөнья күргән «Сайланма әсәрләр» китабыннан алынды.

ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

ФАИЛ – КАРАШӘМ КҮГЕНДӘГЕ ЙОЛДЫЗ

Рәмзи Вәлиев

Тау ягы, болгар ягы: Карашәм – тау ягы авылларының иң борынгыларыннан. Чишмәле, урманлы, болынлы, елгалы, таулы да булган бер кечкенә генә авыл инде ул хәзер.

Карашәмдә Авыл кизләве, Тукташ кизләве, Әҗәл башы кизләве, Бүре чаты, Алпут кыры, Түбән чалу, Рушша (роща) урманы, Чтапан оврагы һ.б. тарихи, табигый урыннар бик күп. Авыл күле, Гөбенә елгасын да әйтеп узыйм.

Булачак язучы, шагыйрь, юморист Фаил Шәфигуллин матур җирдә туып үсте һәм, шактый авыр юлларны узып, татар зыялысы булып өлгерде. Мең ел чамасы элек яшәгән Дүсмәт, Габделкасыйм, Габделхалик бабаларыбыз рухын иңдергән зат иде ул. Шунысы кызганыч, Фаил үзе бу бабаларыбызның барлыгын да белергә өлгермәде, һәлак булды. Әле күптән түгел «Карашәм Шәҗәрәсе» һәм Марсель Әхмәтҗановның шушы шәҗәрәгә шәрехнамә-комментарийлары дөнья күргәч кенә, белеп шакаттык! Бай тарихка ия икәнбез, ләбаса! Хәзер инде үзебезнең Биләрдән чыгуыбызны да, анда Аксак Тимер белән көрәшкән Чадаш бәк бабабызны да, Иван Грозный белән беренче булып көрәш башлаган Габделкасыйм, Габделхалик бабаларыбызны да беләбез. Фаил дә шушы токымнан, барәнҗәр ыруыннан. Бу ыру турында Ибн Фадлан да язып калдырган.

Язучының күңеле вә рухы серле була. Анысын шагыйрь үзе дә белмәскә мөмкин, әмма дә ата-бабадан килгән рух канда, күңел түрендә саклана һәм үзен бик яхшы күрсәтә дә. Фаил турында истәлек яза башлагач, туган ягым, борынгы бабаларым, Фаилнең әтисе, әнисе, 2013 елның маенда вафат булган абыйсы Шәүкәтләр искә төште. Аларның бишпочмаклы матур йортлары күз алдыма килде. Без бу йортта бик еш очраша идек…

Фаилне мин кечкенәдән беләм. Аларда уенчыклар күп иде, мин шулар белән уйнарга керә идем. Ул чакта әле Хафиз абый — әтиләре дә исән иде. Әмма ул, суык тиеп, бик тиз үлеп китте. Без ул вакытта кечкенәләр идек әле. Әмма Фаилнең әтисез калганын шәйләдек, кызгандык. Үсә төшкәч, еш кына аның абыйсы Шәүкәткә ияреп, урманга чикләвек, каен, кура җиләге җыярга йөри идек. Алпут кырына җир җиләге җыярга бара идек. Авылны чыккач та бик матур елга ага. Суы чиста, рәхәтләнеп коенабыз. Ни кызганыч, ул елгалар да кипте инде: Фаил су коенырга алай артык ыргылып тормый иде. Урман, яшел болынны ярата ул. Урманы да алар өеннән үк күренеп тора. Фаил үзе генә дә йөри. Берәр уйдык тапса, шауламый, мул итеп җыя да әнисе Гыйлем апага алып кайта, абыйсын сыйлый. Үзе генә булганда, күрше бакчасына кереп, кыяр-кишер белән дә туклана. Ипи юк иде бит инде. Җәй җиттеме, капчык-капчык какы, кузгалак, кычыткан вә алабутаны атлар кебек ашадык бит. Көз көннәрендә чикләвек, имән әкәләсе кебек әйберләрдән дә баш тартмыйбыз. Нигәдер ул елларда бәрәңге начар була иде. Вак кына сары бәрәңгеләр. Әтиәниләр ничек кенә җайлаганнардыр — барыбыз да үстек. Гыйлем апа да берүзе ике егет үстерде. Ничек авыр булганын үзе генә белгәндер инде мәрхүмә. Менә шушы вакытларда без — Фаил, абыйсы һәм мин — бик дус булып, өчәү безнең алма бакчасын саклыйбыз. Кичен клубтан кайтабыз да бакчадагы шалашка кереп чәй эчәбез, сөт, катык белән дә сыйланабыз. Безнең бит әти бар! Аз булса да, ризык пәйда була башлады. Әтиебез фронттан кайткач, бигрәк тә ул районда эшли башлагач. Әниебез Шәмсекамәр дә аларны бик ярата иде. Безгә барын да әзерләп куя. Алманың инде иң тәмлесен генә шатыр-шотыр китерәбез. Тешләребез — яшь бүренеке кебек! Ул елларда безнең бик сөтле сыерыбыз бар иде. Сөт, катык, каймак, эремчек мулдан. Без — «охранниклар» — бик тиз йокыга китәбез. Ә иртән, уянып китсәк,

Фаил юк. Гел шулай. Ул инде алмалар җыеп, Гыйлем апаны сыйларга китеп өлгергән була. Без моңа бары тик шатлана гына идек инде. «Безнең малай барына да өлгерә», — дия торган иде абыйсы Шәүкәт. Бу турыда әле вафаты алдыннан гына Шәүкәт дустым бер шигырендә:

Бер авылда туып, бергә үстек,
Мәктәп сукмакларын
бергә таптадык.
Җәйге кичтә шалаш ясап,
Алма бакчаларын сакладык, — дип язган иде. Нинди күңелле заманнар булган икән, әй! Тамак ач булса да, бик көр күңелле малайлар идек без. Байлыкка исебез китмәде — өмет белән яшәдек. Бөтен халык шулай эшләде, яшәде. Ата-ана балалар киләчәгенә өмет белән карады.

***

XX гасырның илленче еллары башында безнең авылда электр юк иде әле. Кино күрсәтү — зур вакыйга. Кино килде, дигән хәбәр таралуга ук, клуб тирәсенә җыелабыз. Беренче булып бала-чага килә инде. Зурлар — колхоз эшендә. Клубта ут бирә торган двигатель бар. Киномеханик башта шушы моторны җибәреп карый. Мотор эшли. Димәк, кино булачак! Белдерү дә эленеп куела. Безнең бер генә кайгы — кайдан акча табарга?! Югыйсә, биш кенә тиен бит инде, ә акча юк. Фаил монда да Фаил булып кала! Ул көндезен үк клубтагы мич эченә кереп ята да, кино башлангач кына чыгып, халык арасына «чума». Сәхнә астында качып җаен табучылар да бар. ...Берзаманны пытырдап эшли генә башлаган двигатель ярты юлда туктап кала. Озак маташканнан соң, механик егет: «Кино иртәгә булачак», — дип халыкны тарата. Менә шулай итеп, атналар буе бер киноны карыйбыз. Ә безгә — бала-чагага кызык! Механик тирәсендә буталабыз, авыл механизаторлары да шушы мотор тирәсенә җыелып, киңәш биреп торалар. Әмма двигатель, пыр-пыр килә дә, бераз эшләгәч, туктап кала...

Алтмышынчы елларда безгә дә электр уты керде. Заманалар үзгәрә торды, Фаил дә үсә, ныгая. Кинолар да була башлады. Әйе, акрын гына үсеп, төрлебез төрле якка тарала башладык.

Балачагында Фаил үзе уйчан, үзе — мәзәк остасы иде. Хыялыйлыгы, үзенчәлекле фикере белән — баш-

...Ак хыяллар артыннан – җилдәй җитез матайда!

Абыйсы Шәүкәт диңгез сәфәреннән кайткач. 1980 нче еллар



ка. Кешеләргә артык кушылмыйча, моңсуланыбрак йөри иде кебек. Әйе, аның зур зәңгәр күзләрендә — күбрәк моңсулык, үзе әйтмешли, «бик сагындым, тургаем» дип язларны, кошларны ярату ята иде.

…Фаил, укуын дәвам итә алмыйча, төрле эшләрдә эшли башлады. Авыл малайларына бермә-бер авыр иде шул. Бигрәк тә шәһәргә килеп урнашу бик кыен иде. Тулай торакларда, фатирларда, күченә-күченә, торып азапландык. Фаил дә шуннан башлады, шулай яшәде. Ул башта, Яшел Үзән шәһәрендә эшләп, Казанга йөри иде. Яшь чагы иде шул. Барына да түзде. Шул ук вакытта ул әдәби түгәрәккә йөрергә дә өлгерә.

Абыйсы Шәүкәт исә, армиядән соң туп-туры диңгезчеләр мәктәбендә укып, диңгезче булып китте. Озак кына югалып торганнан соң, туган якка еш кайта башлады. Әле хәзер дә безнең кибетләрдә булмаган искиткеч тәмле чәйләр, хәтта япон күчтәнәчләре дә алып кайтты. Посылкалар да җибәреп торды. Яшел Үзәнгә Фаилнең әнисе Гыйлем апа янына баргач, ул мине Шәүкәт җибәргән куертылган сөт, тәмле чәй белән сыйлаган иде. «Фаилем дә кайтып-китеп йөри, Аллага шөкер!» — ди иде ул вакытта.

1956 елда мин, унынчыны бетереп, хәрби училищега киттем һәм инде шуннан соң Фаил белән өч-дүрт еллар чамасы күрешмәдек тә кебек. Ул да эштә, мин дә — студент. Вакыт юк иде.

Яшел Үзәндә заводта эшләп, кичке мәктәпкә дә йөреп, Фаил ун сыйныфны тәмамлап, Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керде. «Тырышкан — ташка кадак каккан! — ди. — Безнең малай да кадак какты бит», — дип, Гыйлем апа сөенеченнән көлә иде. «Менә, зур язучы булгач, нигезебезне саклап, матур йорт салырбыз, улым, Фаилкәем!» — дия торган иде әнисе.

Шулай да, икебез дә бер юлдан йөри башлагач, тәки очраштык бит. Ул журналистика факультетына кергән икән, мин исә — тарих-филология факультетында укытып йөрим. Очраштык. Жора атлы бер әдәбият укытучысы моңа бераз бәйләнгән. Туктале, мәйтәм, моңа сүз кушып карыйм әле. Жора бик озак итеп аңлата башлагач: «Син бит аның язган әсәрләрен үзең дә белмисең, — дим. — Ул — зур татар язучысы бит, ә син аннан чит ил язучыларын белүне генә таләп итәсең», — дигән идем аңа. «Ярый, аңладым», — диде бу. Соңрак белдем, Фаилне шактый гына йөгерткән булып чыкты. Башка андый хәлләр булмады.

«Чаян» журналының җаваплы сәркатибе, язучы Мәгъсум Хуҗин белән. 1980 нче еллар

Егет, матур гына укуын тәмамлап, төрле редакцияләрдә эшли башлады. Үзен талантлы публицист һәм гаҗәеп кыю язучы итеп күрсәтте. Мин аның көлкеле язмаларын әле дә рәхәтләнеп, кабат-кабат алып укыйм. Бигрәк тә ул «Чаян» журналында эшләгәндә еш очраша идек. Балачакның кызык вә бәхетле мизгелләрен искә алабыз. Эштән кайтышлый, «Чаян» журналы редакциясенә киләм дә, Фаил янына керәм. Ул исә шатланып каршы ала. «Менә, бәләкәй генә китабым чыккан иде, сиңа бүләк итәм», — ди. Мин шатланып алам, аңа мактау сүзләре яудырам. Гыйлем апаны сорашам, абыйсы Шәүкәт белән кызыксынам. «Әни үзе генә калды. Кайтып йөрим», — ди. Аннары абыйсы турында сөйләп китә:

— Абый әле генә Африкадан кайткан иде. Инде Япониягә китеп бара бит, Рәмзи, — ди. — Авызы ерык, күзләре уйный: менә бит безнең Карашәм малайлары нинди, дип әйтә кебек. — Даа, малай, — ди. Тәки үзенекен итте бит, бармаган иле калмады инде», — ди.

— Син үзең дә Казанның нәкъ уртасында иң кызыклы «Чаян» журналында утырасың бит! — дим. Ул башын аска ия, күзләрен яшерә. Уңайсызлана. Безнең малайлар мактауга күнекмәгән, киресенчә, әрләгәнне ярата. Әрләгәндә дә бөркет кебек ул, керфекләрен дә селкетми Фаил... бары тик... көлә. Тагы нидер сыза, яза. Тукай әйтмешли, колагы яхшы ишетә, күзе шәп күрә!

Җитмешенче елларда, хәләл җефетем авырып торса да, Фаил берничә мәртәбә безгә килеп кунып китте. Чәй эчеп, ашап, әз генә мәй дә кабып, шактый гәпләшеп утырган идек. Бигрәк тә минем Люция белән фикерләре якын иде. Алар гаилә турында, балалар, тормыш турында сөйләшә. Ул бик соң ятып, иртә тора иде. Без торганчы инде ул торган да нәрсәдер язып утыра, эшли. Төннәр буе сөйләшеп чыга идек.

— Хәтерлисеңме, Фаил, ничек итеп без авылдан качып китәргә йөргән идек?! — дим. Ул көлә:

— Абыйның бер хыялы иде инде...

— Качарбыз дип, йомыркалар, сохарилар да җыйган идегез, — дим.

— Әйе, — Фаил җитдиләнә. — Бер качып та карадык, әмма Кайбычтан тотып алып кайттылар да шуннан соң «сүнә» башладык. Абый башкачарак фикер йөртеп, безнең диңгезчеләр мәктәбенә керүне теләде, — ди.

Фаил авылдан китүгә каршы булды. Ул авылны, әнисен бик ярата иде. Аның иң зур хыялы — яңа йорт җиткерү иде. Үзенең «Карашәм» дигән шигырендә ул: *«Синдә калган истәлекләрне, гомер буе сагынып сөйләрлек...»* — дип моңсулана. Туган авыл аның өчен

йөрәккә көч һәм дәрт бирә торган, гомер буе сагынып сөйләрлек урын иде...

Хур күрмибез кайда барсак та,
Йөрәккә дәрт бирә бер аһәң.
Җилләр чыга, куба давыллар,
Сүнми барыбер, сүнми, яна шәм.
Дәртләндереп, җанны яктыртып
Торучы син, син ул, Карашәм.

Җиденче сыйныфны бетергәч, ул, трактористка укып, авылда җир сөрде, ә соңрак исә, Владивосток якларына барып, балык та тотып карады, әмма акчасын гына аңа артык түләмәделәр. Янә авылга кайтып, Гыйлем апа янына сыенды. Гыйлем апа үзе дә көчле юморист иде. Нәрсә, улым, байый алмадың инде, әйдә, исән кайттың әле ярый, — дия иде. Чыннан да, аның язмаларында океан штормнары турында язганнарын укысаң, Гыйлем абыстайның әйткәннәре — бик тә урынлы. Менә шушы чорда инде аның авыл кешеләренә, авылның билгеле тауларына, чатларына багышланган язмалары туды. Аның урман каравылчысы «Лекандр»ы гына да ни тора! Без аннан куркып йөргән чакта ул матур итеп урман каравылчысының образын тудырган икән.

Мин үзем Фаилнең юмористик хикәяләрен кабат-кабат, көлә-көлә укыйм. Хәләл җефетем Люция:

— Нәрсә көлеп утырасың? — ди.

— Фаилнең китабын укыйм. Менә син дә тыңлап кара әле, — дим. Инде бергәләшеп көләбез. Шаян, әмма моңсу Фаил һаман арабызда кебек. Без аны юксынабыз, бик еш искә алабыз. Авыл халкы аны «Карашәм күгендәге йолдыз» дип атый. Ул — Татарстаныбыз күгендәге йолдыз, дип тә өстим.

***

...Иң соңгы күрешүебез Татарстан урамында булды. Мин бер очрашуга бара идем, ә ул эштән кайтып килә. Яңа фатир алган икән. Миңа шуны күрсәтәсе килеп кунакка чакырды, әмма мин керә алмадым. Махсус килермен, Фаил, дигән идем... Әмма шушы очрашудан соң мин инде аны, ни кызганыч, бүтән күрмәдем. Ул вафат булды... Кайтып керү белән хатыным Люция:

— Рәмзи, кайгылы хәбәр бар бит, — ди.

— Нәрсә булды? — дим.

— Фаил вафат булган бит, — ди.

Аптырап киттем. Тиз генә Фаилнең квартирасына килдем. Гыйлем апа елап утыра.

— Үтерделәр балакаемны, — ди. Мин аны юата алмаячагымны аңлап, сүзсез катып калдым, ни әйтергә дә белмәдем. Фаил тере кебек ята... Ул бер дә мәеткә охшамаган. Әллә нинди бик күңелсез караңгы көн иде. Җил исә, тузан тузган, салкын... Татарстан урамыннан татар зиратына атлыйбыз. Язучылар, журналистлар, дуслары, танышлары килгән. Күп сөйләшмиләр. Фаилне урнаштырып, кире кайтыр юлга чыккач, тагын Нәсих дустым исемә килде. Карале, дим, теге вакытта аның белән татар ашларына барган булсам, Фаилне күргән булыр идем, бәлкем әле минем белән булса, ул исән дә булыр иде, дим. Сораша торгач, Фаилнең ул көнне Татар ашлары йортында булуын белдем. Кем белә, бәлкем икебез дә һәлак булган булыр идек. Әшәке еллар иде бит. Фаилгә саклану да җитмәгәндер. Хыялый, туры сүзле авыл малае барына да ышанып яшәде. Ул елларда татар зыялылары күпме газап чикте, күпмесе Фаил кебек һәлак булды. Яңадан-яңа үрләргә күтәрелергә омтылган Фаилнең юлын кара көчләр кисте. Шунысы аяныч: үзенең талантын тулы көченә ачып, ниятләрен тормышка ашырырга өлгерә алмыйча, вакытсыз һәлак булды ул...

Килер бер заман, зыялыларыбызга зыян салучылар, мыскыллаучылар, ахыр чиктә, аларны һәлак итүчеләр дә ачылыр, нәфрәт белән искә алыныр, дип өметләнәм. Килер бер заман... Менә шулвакытта Карашәм күгендә йолдыз булып балкучы Фаилнең серле вафаты да халкыбызга билгеле булыр. ■

Фаил Шәфигуллиннан – Шәукәт Шәфигуллинга

«Паратск зур кала...»
(Халык җыры)

Сәлам Зеленодольск калаларыннан!

Исәнме, абый! Кайнар сәламнәребезне кабул ит. Сәлам әнидән дә, миннән дә. Үзебез әлегә исән-имин, әкрен генә кыштыр-кыштыр яшәп ятабыз. Әллә ни кылтайткан да юк инде шунда. Кеше кебек. Әнә шундый (рәсемдәге) агач йортта яшәп ятабыз инде без. Аскы катта. Бер тәрәзә, бер бүлмә. Тәрәзә ишегалдына карый. Тәрәзәдән карасаң, тигезле-тигезсез тезелеп киткән утын сарайлары күренә. Ә тагын да арырак безнеке шикелле үк йорт түбәсе караеп тора. Ара-тирә, анда-санда юкә агачлары үсеп утыра. Ишегалдында көне буе чыр-чу килеп малайлар уйный, кичләрен карчык-корчыклар җыелып, дөнья хәлләрен «җиңеләйтеп» утыралар. Озын-озын бауларда керләр җилферди. Бугазын киереп әтәчләр кычкыра, тавыклар җырлаша. Күрше урысларның карт мәчесе, колакларын локаторлар кебек уйнатып, күзләрен йомып, өй түбәсендә гөрләшкән күгәрченнәр моңында изрәп утыра. Кемнеңдер әле яңа гына тәпи йөри башлаган малае ишегалдына чыкса, тәрәзәләрдән төрле-төрле башлар урамга сузыла. «Марат», — дип кычкыра калынрак тавыш. «Марат, тү-тү-тү, кил монда, аппагым», — ди нечкә, чәрелдәвек тавыш. — «Марат, иди домой, сейчас иди, слышишь, — ди өченче ачулы тавыш. «Марат, Марат, Марат», — дип берен-берен уздырырга тырышып кычкыралар тәрәзәләр. Аннан кемдер радиога җибәрә: «Только очень жди...» Кайсыдыр чыш-чыш утын кисә, кайсыдыр дөп-дөп яра. Басма алдына каяндыр кайтып килүчеме, барырга җыенучымы, мотоциклар килеп туктый. Тузан болыты күтәрелә. Тузган чәчле хатын сукрана-сукрана керләрен җыеп йөри... Карт мәче мондый тавышларны исәпкә алып тормый: һаман да күзләрен йомып, күгәрченнәр моңын тыңлый...

Төн җитә. Яшь егетләр, яшь кызлар, тол хатыннар, тол ирләр, хәл кадәренчә киенеп, «Ленин» урамына таба агылалар. Госбанкка кадәр төшәләр дә, халык агымына кушылып, яңадан ДК янына әйләнеп менәләр. Тагын госбанкка, тагын ДК янына. Хәллерәкләре пиво, рәте юграклары квас эчә. Парк янына татарлар җыела. Яшьләр, яшьләр, чибәрләр, чибәрләр... Иге-чиге юк. Җырдагы кебек: «Бу яшьләргә замананың иң әйбәт чагы килде», чукынган... Кара костюмын ике якка җәеп җибәргән, ак күлмәкле, кара костюмлы егет җилкенеп-җилкенеп гармун (хромка) уйный. Ә кызларның кара-шомырт күзләре, кара-бөдрә чәчләре, кый-

«...Ишегалдында көне буе чыр-чу килеп малайлар уйный, кичләрен карчык-корчыклар җыелып, дөнья хәлләрен «җиңеләйтеп» утыралар»...
Сулдан икенче — Ф.Шәфигуллинның әнисе Гайнелгыйлем апа. Яшел Үзән шәһәре. 1969 ел

Абыйсы Шәүкәт белән. Находка шәһәре. 1960 нче еллар

гач-кара кашлылары ашкынып-ашкынып бииләр. Карап-карап торасың да «Яшьлек» дисең. Әйе, яшьлек...

Кичә 24 июнь. Безнең чыгарылыш кичәсе булды. Ниһаять, дүрт авыр ел артта калды. Кулны кысып, «өлгергәнлек» аттестаты бирделәр, бүләк итеп сәгать бирделәр. Аннары өстәлләрне «о» хәрефе кебек тезеп куйдык. Биештеләр, кычкырыштылар, җылаштылар, хушлаштылар, үпкәләштеләр, бер-беренә мактау сүзләре әйтештеләр, үбештеләр... Кыскасы, мәктәп бинасы төнге сәгать өчкә кадәр дер селкенеп торды. Специально музыка чакыртканнар иде. Джаз уйнадылар. «Буги-вуги» биеделәр...

Әни исән-сау. Дөбердәтеп йөри. Марҗалар белән теттереп сөйләшә. Трикотажны «каталажка» ди. Син җибәргән акчаны төенләп куйды. Авылга кайтам, ди. Белмим, кайчан кайта торгандыр.

Кичә төне буе яшенле яңгыр яуды. Ә бүген көн кояшлы, җилле, һава саф, күк зәңгәр.

Бүген Казанда сабан туе. Барып булмастыр, ахры...

Авылга кайтмаганга бер ел була инде, узган ел шушы вакытларда кайтып киткән идем бугай. Хәер, авыл хәбәрләрен болай да белеп торабыз инде. Әни базарга чыккан саен берәр авылдашны күреп керә. Кайчагында килеп чәй дә эчеп китләлиләр.

Анда Нәбиулла абзый (90 яшьлек) вафат диләр. Дога кылырсың. Аннары безнең теге мәчет урынына яңа клуб салганнар бугай. Анысын да кайтып күрәсе бар әле. Эш күп әле, бик күп, кем әйткәндәй, вакыт кына җитми. Җитми вакыт, җитми. Гомер җил кебек уза. Календарь битләре пушкадан аткандай атылып кына торалар. Карыйсың — дүшәмбе, икенче карыйсың — шимбә җиткән була. Инде (әйтергә онытканмын икән) безнең шәһәр дә биш көнлек эш атнасына күчте. Дүшәмбедән алып, кече атнага чаклы шәһәр тын. Җомга көн башлана. Ә инде шимбә киче, мин сиңа әйтим, җәһәннәм кебек кайнап, ду килеп тора. Прилавкалар (магазиннарда) яртылаш бушыйлар. Якшәмбе көнне дә кичкә кадәр дәвам итә типтерү. Ә кич азрак сүрелә. Дүшәмбе көнне бутылка кабул итү пунктлары янына озын чират җыела. Күпләр, похмельдан айнып җитәлмичә, эштән дә калып куялар. Шулай итеп, ял өч яисә дүрт көнгә сузыла.

Вәт, парень, сез Африканы әйләнеп кайтасыздыр.

25 июнь, 1966 ел

БИШЕНЧЕ ФАСЫЛ

Марсель Галиев

Ул – үз дөньясын, үз кыйбласын ачкан шагыйрь. Аңа җәмгыять кысаларына сыешып яшәү җайсыз булгандыр. Шарль Бодлерның очыштагы горур кошы «Альбатрос» кебек, елгыр кешеләрне аралап, җирдән атлап йөрергә аңа канатлары мөмкинлек бирми иде.

Гел читләшеп йөрү дә туйдыра, күрәсең, каләмле шәхесләр төркеменә килеп кушылса, аның әйткән сүзе сәеррәк тоела, җепкә килми, елмайса, елмаюы — мыскыллы ирен кыйшату кебек, уртак мыскалга туры килми, кыскасы, килешми иде аңа «очышын җуеп» гадәти кешеләр арасына төшү мисалы.

Ул — тумыштан шагыйрь иде. Күкләр фәрештәсе аның бишегенә каурый канат салып киткәндер. Сабый чакта, теле ачылганчы ук, шул сәмави канатка кулын тидергән, һәм инде каурыйны төшендә дә, өнендә дә эзли-эзли ул дөнья буйлап килә; бу күңел серен беркемгә дә ачмаска кирәклеген белә, фәкать шигъри сүзгә генә ышана, таяна, туган тел олылыгы каршында гына ул, изүен ачып, эчкерсез калу бәхетенә ирешә алгандыр.

Язмыш белән без бәхәстә мәңге,
Язмыш белән мәңге алышта.
Язмышыңнан өстен булам, дисәң,
Чигенмәскә өйрән карыш та.

***

Эдуард Госман улы Мостафин 1945 елның 31 гыйнварында Башкортстанның Краснокама районы Кәс авылында (Касево) дөньяга килә. Сауз авылында тәрбияләнеп үсә, урта мәктәпне тәмамлый. Яшьли каләм тибрәткән егетне шагыйрьләр Мәккәсе — Казан үзенә тарта. Монда килеп ул университетның журналистика бүлегенә укырга керә. Бер-ике ел



укыгач, аның романтик рухлы тынгысыз җаны киңлеккә сусап алгысына башлый.

Бала чактан бәйсез күңелемдә
Ике теләк яшәделәр тигез:
Беренчесе аның күктәге кош,
Икенчесе — ерактагы диңгез.

Ераклыклар дәшә, дигән чор бит бу. Университет бинасының ак колонналарын «аерып» чыга да, егетебез, язмышын ирекле җил иркенә куя. Максим Горький сыман, босяк булып,

ил гизәргә үк адарынмаса да, шактый җирләр күрә: Уралда, Урта Азиядә туктала, Игарка портында эшләп ала:

Давыллары, янгыннары булды,
Ташкыннары алып агызды...
Язмыш чикләвеген учка кысып
Чәрдәкләдем читтә ялгызым.

Тумышыннан рәссам таланты бирелгән шагыйрь дала киңлекләрен дә, ак чалмалы тауларны да, күкрәп аккан елгаларны да, шомлы тайгаларны да үз күзләре белән күреп, сурәтле сүз хәзинәсенә җәүһәрләр туплый бара. «Дулкыннар камыр басалар, комнарны ашый-ашый», «Ак якалы акчарлаклар җилфердәшә, җим эзләп», «Чү, сайрама, аксак чикерткә!», «Көтүченең чыбыркысы телеп үтте бу таңны», «Каргаларның тавышыннан чатный күкләр», «Кояш йоклый күктә әлсерәп». Болар — искиткеч чагыштырулар, табышлар, сурәтле күңел җимешләре. «Кайгыларын чәйничәйни, тәрәзәгә этләр өрә», «Йомылган кысыр болытлар шытмаган уҗым төсле», «Күзләреңдә ике диңгез талып ята, сөяр-сөймәс». Бу бит табигатьнең тере күзәнәкләрен күрә алып, аны шигъри тукымада нәкышли белү, яисә гадәти соклану гына түгел, бу бит — «Идегәй» дастанында әйтелгәнчә, «Акылы уйга бай» затның бәгырендәге тойгыларын сурәткә салу, җан авазы.

Әйе, Эдуард Мостафин шигырьнең тышкы сурәтен җимереп, шуны яңалык дип сискәндерү белән мавыкмады. Мондый «яңалык» Европа шигъриятен күптән инде таптап үткән, шаукымы XX гасыр башында русның сүз сәнгате аша татар шигъриятенә дә бәреп кергән иде (Такташ, Хәсән Туфан, Гадел Кутуйларны хәтерлик).

Ул — шигъриятнең төш-ядрәсен уятып, эчке хасиятенә егәрле сүз кертә алды, кӧтелмәгән гыйбарәләр, кыю образлары белән шигырь дигән көйлекысалы-үлчәмле шәкелнең офыгын киңәйтте, сәнгати рухын көчәйтеп, кеше җанына якынайтты. Көтелмәгән тансык сүз белән җәлеп итеп, үзен яраттырды.

Такташ, Әхмәт Фәйзи, Роберт Әхмәтҗанның шигъриятендәге образлылык, табигать арфасының нечкә кылларын чиртә белү осталыгы аңа йогынты ясаганмы, әллә инде Европа поэзиясенең рус теле аша кергән үрнәкләреннән илһам алып югарырак ботакларга үрелгәнме? Әмма шунысы бәхәссез, Эдуард Мостафин шигъри телебез ирешкән милли казанышларыбыз гөмбәзенә үз табыш-тәлгәшләрен тезеп, җете төсләрдә балкыта алды. Аның поэзиясе шигъри теленең саллылыгы белән аерылып тора. Иманы — олы язмышлы халкының җан тибешенә көйләнгән. Ашинәдән туып кыйтгаларга таралган төрки дөньяның асыл символы — бүре образы — аның шигырьләрендә юкка гына еш кабатланмый.

Еллар аша борылып карыйм да... Учымда истәлекле китап ята. 1979 елда без, берничә егет — «Яшь шагыйрьнең беренче китабы» сериясеннән җыентыклар чыгарган идек. Исе, төсе, тәме беренче мәхәббәт кебек бик кадерле иде ул китапның. Барыбызныкын да укып чыктым да... Эдуард Мостафинның аҗаганлы, яшенле, тирән офыклы шигырьләре минем «кикрик»не шиңдерде; уймак кадәр уйлап, мунча төннегеннән генә «җиһанга» карап язам икән ләбаса! Менә бу киңлек, менә бу саллылык, ичмасам, сүз егәреннән күңелем сыгылып килде. Үзен күргәч, котлап, кулын кыстым:

— Иң шәп шигырьләр — синеке!

Әйттем дә, бик якыннан аралашмаган, кырыс йөзле шагыйрем берәр тупас сүз ычкындырмасын тагы дип, сагаеп та калдым. Эдуардның кысылган ирен читләрендә сизелер-сизелмәс кенә елмаю саркып алды:

— Синнән мондый сүзне көтмәгән идем, рәхмәт, — диде.

Әллә ничек, күз алдында юашланып калды. Икенче Туфан, дип уйлап куйдым мин аңа карап. Куе чәч. Шакмаклы ияк белән тәмамланган озынча йөз.

Маңгай астыннан караган, моңсулык өртелгән күзләр. Буе, рәвеш-кыяфәте белән ул чынлап та Хәсән Туфанның яшь чактагы сурәтләренә чат охшап тора.

Эдуардның тәүге китабы «Елның бишенче фасылы» дип атала иде. Нигә бишенче? Табигатьтә дүрт кенә фасыл икәнне сабый да белә, югыйсә. Шагыйрь үзе, Пушкин кебек, көзләргә гашыйк икәнен дә яшерми:

Бер ялгызым керәм Сентябрьгә:
Туң баланнар яна таң булып.

«Чыкма язга, алданырсың, адашырсың. Син, шагыйрем, тик көзләрнең кандашысың», — дип яза ул.

Ниһаять, ул җиде елдан соң «Туасы көн» дигән китабында шундый исемдәге шигырен яза — «Бишенче фасыл» — аның үз дөньясы; үз кыйбласы, үз кәгъбәсе икән. Ә бәлки… дүрт фасылга сыеша алмаган җан дөрләведер…

Җитмешенче елларда ул Мәскәүдә М.Горький исемендәге әдәбият институтында читтән торып укыды. Еллары, чоры нинди иде бит! Евтушенколар плеядасының олы мәйданнарны, стадионнарны шигъри сүзгә бөтереп алган шаулы дәвере. Андый исерткеч шаукым, шагыйрьмен дигән шагыйрьгә йокмый кала димени! Институтта аралашырга да кызыклы шәхесләр җитәрлек. Үзебезнең Разил Вәлиевнең дә шунда укып, «дөньяны үзгәртергә» адарынган чагы. Рус шигъриятенә икенче Есенин килә, дип шау уяткан Николай Рубцов (1936-1971), «Мин әтинең баш сөягеннән шәраб эчтем», дип сискәндереп язган Юрий Кузнецов (1941-2003) белән дә ул шул чорда аралашып кала. Тәне белән дә, җаны белән дә чын рус милләтенең шагыйрьләре булган шундый шәхесләр белән аралашу — Эдуард Мостафинга да кыю сүз дәрте уянуга йогынты ясагандыр.

Европаның әдәбияты, сәнгате белән нык кызыксынган шагыйрь буларак, ул хыялында Парижның Монпарнас урамындагы атаклы кафеларда Франсуа Вийон, Шарль Бодлер, Пикассо, Ван-Гог кебек талант ияләре белән тәмәке төтене һәм йөзем шәрабе төменнән хозурланып бер генә утырмагандыр.

Ә чынбарлыкта… Эңгер төшүгә өметсез караңгылыкка чума торган Казаныбызда, «якты киләчәккә» таба карусыз барып яткан сүрән халык арасында аңа кысан булгандыр, Җаны тарыккандыр.

Шуңа да ул бер-берсен макташып, үзләре хакында легенда тудырып, оя-оя оешкан шагыйрьләр өереннән читтәрәк булды. Юл башында, бик иртә макталуның соңы хакында уйланган бер шигыреннән өзек китерик:

Күпкә җитәрме ялкының,
Бик иртә атлап киттең.
Козгыннар чукый башласа,
Тәнеңдә бармы итең?

«Дан кебек корттан сакларлык бармы синең иманың?» — дип ул, гүя, офык артындагы елларга үрелеп, кисәтеп куя…

Каләм ияләре дә нурдан яратылмаган, тамак ялына эшләргә туры килә. Эдуард Мостафин исә беркайчан да бер генә урында басылып эшләмәде. Гелән вакыт аның үз ихтыярында иде. Узган гасырның җитмешенче елларында әле, тарихи мисалларга ишарә ясап, чын шагыйрь — ихатасыз, дәрвиш, сәях, ярлы сукбай, ирекле булырга тиеш, дигән караш яши иде. Кайчакларда «Эт кебек шыңшыйсы килә, бүре кебек улыйсы килә», — дип язган Эдуард Мостафинга да үз ирегеннән бөтен нәрсәдән өстен кую, «тукайлану» ят түгел иде. Шагыйрьгә бар да кичерелә, дип яши торгач, ул хатынлы килеш хатынсыз, фатирлы килеш фатирсыз калды. Бу хакта улы Идегәйгә багышланган мондый юллары бар:

Сорарсың: кемдә ялгышлык,
Кайсыгызда соң гаеп?
Белерсең, улым; җаваплар
Килми канатын җәеп.

Мин аның тормыштан зарланганын, ачылып киткәнен хәтерләмим. Кайсыдыр кинотеатрларда рәссам-бизәүче

Камил Кәримов төшергән фоторәсем. Сулдан уңга: Эдуард Мостафин, Марсель Галиев, Рашат Низамиев, Госман Садә, Флүс Латыйпов, Нәбирә Гыйматдинова, Илдар Юзеев һәм Роберт Миңнуллин. 1975 ел, май ае. «Идел» яшьләр лагере

булып эшләп йөргәнен ишеткәнем бар иде. Заманында Саба газетасының редакторы булып эшләгән Тәлгат Нәҗмиевнең истәлек-язмасын укыгач, шаккатып калдым. Эдуард Мостафинны район газетасына хәбәрче итеп эшкә алган булган икән бит ул! Беренче көнне үк аны ерак бер авылга командировкага җибәргәннәр. Язасы кешесе хәлле, романтик, хикмәтле сүзгә сусаган булган, ахрысы, Эдуардны җибәрәсе килмичә, «ду» килеп бәйрәм итәләр болар. «Шаг влево, шаг вправо — расстрел» тәрбиясе алган Тәлгат Нәҗмиев, әлбәттә, моны кичерми, райком табаны астында чыга торган газета әсирлегеннән, үзе дә сизмичә, азат итеп, шагыйрьне коткарып кала.

Узган гасырның 90 нчы елларында, кан белән яулап алынмаган сүз ирегеннән болагайланып, поэзиядә тамак ярып кычкыру, шикле батырлык, күсәк болгаулар матур әдәбият көзгесен челпәрәмә китергән иде. Кем-кем, хәтта Эдуард Мостафинга да моның әрсез җиле тия язды, әмма ул барыбер тонын караптмады, сүзгә зыялы мөнәсәбәтен, чама хисен саклый алды.

Әдәбият хәзинәсендә аның өч китабы калды. «Уйлар» һәм «Чулман төбәге» дип исемләнгән поэмаларының жанрын ул, тыйнакланып, «фрагментлар» дип атаган. Тагын ике поэмасы — «Мин бәләкәй чакларда» һәм «Батырша» — халкыбызның гыйбрәтле язмышы, аның тарихи үткәне, бүгенгесе хакында тирән фәлсәфи уйларга этәргән вакыйгаларга корылган. «Һәр кешедә, Идел кебек дулап, типте ул чак йөрәк», «Үз иманым миңа мең терәк» ...

Диңгез булып алдансам да,
түзәрмен,
Таулар булып алдансам да,
күнәрмен,
Урман булып алдансам да,
бирешмәм,
Шагыйрь булып та алдансам,
үләрмен... —

дип язган ул бер шигырендә. Әмма ул алданмады. Киресенчә, үзенең

кабатланмас каләм иясе, шигърият каланчасының югары кимәлендә урын алган талант иясе икәнен раслады. Язу, иҗат эшен кәсеп итү, урындык биләү именнән өстен күргән, чын шагыйрьлек иманына тугры калган, затлы каләмле шәхес иде ул.

Ил таркалган, халыклар әсәренгән, кыйблалар буталган, иман тапталган чорда (1997 ел) ул кинәт кенә бу дөньядан юкка чыкты. Күкләр иелеп алдымы, «каплан кырда сөякләр яткан» дала-чүлләр буйлап, Туфан эзләреннән шәрык тарафына чыгып киттеме; ни уйларга да белмичә, чарасыз калдык. Сагыныгыз әле мине дә, дип югалып торыр да, кайтып төшәр беркөнне, ул инде бөтенләй икенче, кадере арткан Эдуард Мостафин булыр, дип ышанып көттек без аны.

Коръәндәге «Шагыйрьләр» дигән аять юкка иңдерелмәгән. Шагыйрьгә кул салган явыз бәндәләргә Ходай аяусыз җәзасын ниятләгәндер.

Исән чагында аның башыннан сыйпарга заманның бер уч җылысы җитмәде.

Хәер, аның хакында үлде, дип әйтергә дә тел бармый. Китте… Гаип булды… Югалды… Аннан соң инде, дүрт фасылын җир йөзенә таратып, ел арты еллар узды.

Бишенче фасыл гына әйләнеп кайтмый һаман.

ЭДУАРД МОСТАФИН ШИГЫРЬЛӘРЕ

БИШЕНЧЕ ФАСЫЛ

Көлтә-көлтә шигырь язармын дип,
Язны көтсәм, көтсәм тилмереп,
Кояш күптән ташкыннары белән
Дастан язган кышны җимереп.

Шаулатырмын җәйне үземчә дип,
Июнь ае кебек дәртләндем.
Урманнарга керсәм, урман сузды
Поэмалар язган дәфтәрен.

Көз аенда, дидем, җырлар җырлап,
Тутырырмын иген кырларын.
Миңа кадәр казлар каурый белән
Язып киткән легендаларын.

Кыш хакына гына булсын, диеп,
Бер көй яздым, белми башканы, —
Ап-ак җилләр яланнарга чыгып
Бөек симфония башкарды.

Дүрт шагыйрьдә кунак булдыммыни —
Дүрт төрле җыр һәр дүрт фасылда.
Моңым белән үз дөньямны корган
Мин бишенче фасыл, асылда.

КАЙТ, ДИЯРСЕҢ, ЗӨҺРӘ

Әгәр китсәм Байрон иленә —
Бездәгедәй асыл томандыр.
Томан кызы кояш төшкәнче
Салкын чыкта битен югандыр.

Тәрәзәмне каерып җил ача.
Мин киткәндә Тукай иленнән:
— Кайт, — диярсең, Зөһрә, татарча.

Әгәр китсәм Һейне иленә —
Кар өстендә болан эзедер.
Зәңгәр күзле Рейн кызы да
Мәхәббәтен әле эзлидер.

Тәрәзәмне каерып җил ача.
Мин киткәндә Тукай иленнән:
— Кайт, — диярсең, Зөһрә, татарча.

Әгәр китсәм Лорка иленә —
Гитаралар төнлә моңлыдыр.

Испан кызы, кара толымың
Күз яшеннән генә дымлыдыр.

Тәрәзәмне каерып җил ача.
Мин киткәндә Тукай иленнән:
— Кайт, — диярсең, Зөһрә, татарча.

Әгәр китсәм Данте иленә —
Тауларына болыт кунадыр.
Тау кызы бер карашы белән
Күңелеңә кереп чумадыр.

Тәрәзәмне каерып җил ача.
Мин киткәндә Тукай иленнән:
— Кайт, — диярсең, Зөһрә, татарча.

АРАЛАП БИР МИҢА

Ак көчекләр килә ак дөньяга,
Күбәләкләр — зәңгәр канатлы…
Урман дәшә әнә кочак җәеп…
«Йөрмә, көчек, борын канатып.
Анда — ерткыч, анда төннәр шомлы…»
Тыңламады, китте… «Кал, бала!»
Адаштырдың, урман, шул көчекне
Күбәләгең белән алдалап.
…Бүреләрең белән бергә хәзер
Уйлыйдыр ул төнне каршылап.
Кешеләрдән киткәч, күптән инде
Эзләреңә куйды кар сылап.
Бураннарда калып яфрак елый,
Үләннәре үкси изелеп.
Ак көчекне бер ач ерткыч иттең…
Урман, шулмы синең изгелек!
Кешеләр бит ышаналар сиңа:
Урман, күрсәт изге көчеңне —
Бүреләрдән аралап бир миңа
Күбәләкләр куган көчекне!

ВАН-ГОГ

Сары кояш. Сары яңгыр.
Сары болыт. Сары җир.
Сары урам буйлап атлый
Сары уйлы сары ир.
Бар да сары. Сөю сары,
Тоташтан көз язмыш та.
Сары карлар сарылалар,
Сары икән бу кыш та!
Җитте, җитте, тукта, хыял!
Ялган бит болар, ялган!..
Ван-Гог булып ач күзеңне —
Кып-кызыл кояш янган.
Париж өстендә ап-ак кар,
Булонда ап-ак имән.
Карт аббат та, күзен йомып,
Ап-ак җөббәсен кигән.
………………………………
Өстәлдә сары чәчәкләр,
Сары хәмер савытта.
Данынннан авыз да итми
Бер гөнаһсыз даһи ята
Париж кадәр табутта.

СОҢГЫ КӨНЕ ҖӘЙНЕҢ

Шулай итеп, җәйнең соңгы көне
Китеп бара минем тормышымнан;
Йөрәк сыкрап, тетрәп куйды хәтта,
Язмышыма керер көзге шомнан.
Бөрешеп куйдым шәрә агачтай,
Белгәнгәме көзнең холыкларын;
Синең карашың да таратталмас,
Күкне сарып алган болытларын.
Көзләр калыбына сәлам бүген
Моңаерга әвәс күңелемне;
Иртән генә күзәтермен инде,
Сары яфрак баскан тын күлемне.
Урманнарга барып йөрмәм инде, —
Сискәндерер аның шәрәлеге.
«Былтыр» да юк анда… Шаяртырга
Таба алмам тиле Шүрәлемне.
Китеп барды җәем. Көз дә үтәр, —
Бер җылатыр мине, бер моңайтыр;
Бәрелер дә күңел болытларга,
Шигырьләргә тулып моңы кайтыр.

САТАШКАН ЙОЛДЫЗ

Күк кабыгы шартлады да,
Аның төше — таң туды;
Күк читендә ялгыз йолдыз —
Төннән калган кан табы.
Сүнәр-сүнмәс, янар-янмас
Нәни генә бер җисем;
Күк сүзлеген актарып та
Тапмадым аңа исем.
Бер ялгызы тора күктә —
Ярышмый Кояш белән;
Төннән калган моңлы матдә,
Бу минем йолдыз, беләм. ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

БАЙТИРӘКОВ ӘХМӘТСАФА ГАБДЕРАХМАН УЛЫ (?-1921), Тукайның Җаекта «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә бергә укыган сыйныфташ иптәше (әмма берничә яшькә өлкәнрәк). Тумышы белән Саратов губернасы Хвалын өязе Иске Кулаткы волосте Яндовка авылыннан (хәзерге Ульяновск өлкәсе). Шәкертлек елларында «Мотыйгыя» мәдрәсәсе укучылары тарафыннан оештырылган кульъязма «Әлгасрел-җәдид» журналында үзенең язмалары белән катнаша. Тукай исә бу журналда актив язышучылардан берсе була, аның 1904 елгы 3 нче санында, дустын мактап, «Әхмәтсафа әфәнде — фазыйль әдиптер кәнде...» дип башланган өйрәнчек шигырен дә («нәзым»ын) укучыга тәкъдим итә. Тукай шигыреннән күренгәнчә, Әхмәтсафа Байтирәковның каләме шактый үткен булуын чамалап була. Кульъязма «Әлгасрел-җәдид» журналына (1905 ел, №4) урнаштырылган, мөхәрриргә (К.Мотыйгыйга) язган бер хатында, туган авылына китеп, балалар укыта башлаган Ә.Байтирәков Тукай шигырен укыганын әйтә, андагы мактау сүзләрен үзенә туры килмәвен белдерә, киләчәктә тырышачагын, хикәяләр белән катнашачагын хәбәр итә. 1905 елгы революция дулкыны белән Җаек шәһәрендә Тукайның актив тырышлыгы ярдәмендә шактый радикаль юнәлештәге «Фикер» газетасы нәшер ителә башлагач та, ул аның үзхәбәрчесе булып китә. Ә.Байтирәков газетага күп язмалар җибәреп торган, күрәсең. «...мөмкин кадәр файдалы вә хикмәтле нәрсәләр язарга тырышыгыз, мәктүбләрегезнең арасында мөляхәсезрәк (игътибарсызрак) язылганнары да булганлыктан, сайлап вә чүпләп кенә басарга тугъры киләдер», — дигән киңәшен (җавабын) «Фикер» газетасында (1906 ел, 4 август) язып чыгарга да туры килгән Тукайга. Бик озын мыек үстергәнгә, дуслары арасында аны «Мыеклы Сафа», руслар белән нык аралашканга исә «Урыс Сафа» дип тә йөрткәннәр. Һәрхәлдә, Тукай турындагы истәлекләрдән шулайрак аңлашыла. Холык-фигыле белән бик тыйнак булган. Ә.Байтирәков Октябрь инкыйлабыннан соң да берничә ел укыта. 1921 елда Саратов шәһәрендә үлә.

Зөфәр Мөхәммәтшин, *филология фәннәре кандидаты* ■

Әдәбият

Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма. — Т.1. — Казан: Татар.кит. нәшр., 2011. — Б.31; Әсәрләр. 6 томда: Т.3. — Казан:Татар. кит.нәшр., 1985. — Б.96, 346-347; Нуруллин И. Габдулла Тукай. — Казан, 1979. — Б.82;

БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ТӘМАМЛАНУГА ДА 69 ЕЛ ТУЛДЫ. 9 МАЙ — АЗАГЫЧИГЕ БУЛМАС КЕБЕК ТОЕЛГАН ДӘҺШӘТЛЕ, АЯУСЫЗ ВӘ КАНЛЫ ЯУДА ҖИҢЕП ЧЫГУ КӨНЕ. ӘЙЕ, БӨЕК ҖИҢҮ ХАКЫНА ГАДИ СОЛДАТ ГОМЕРЕ БЕЛӘН ГЕНӘ ИСӘПЛӘШЕП ТОРА ТОРГАН ВАКЫТ ТҮГЕЛ ШУЛ УЛ СУГЫШ ЕЛЛАРЫ... ӘММА ҖАНЫНДА ГАМЕ БУЛГАН ҺӘРКЕМ ӨЧЕН КАДЕРЛЕ, ИЗГЕ БУ КӨН!

ҖИҢҮ — 70!

ЯҢА СӘХИФӘБЕЗ ӘНӘ ШУЛАЙ АТАЛА ҺӘМ УЛ БЕР ЕЛ ДӘВАМ ИТӘЧӘК. 2015 ЕЛДА БӨЕК ҖИҢҮГӘ — 70 ЕЛ!

БАБАЙЛАРЫБЫЗНЫҢ КАБЕРЛӘРЕ КАЙДА?

Ләбиб Лерон

Минем ике бабам да сугыштан кайтмаган. Тимерче Хөҗҗәт бабамның (әтинең әтисе) кайсы бәрелешләрдә катнашуы, кайчан, кай туфракларда җирләнүе турында әле дә берни белмим. «Хәтер» китабында «1943 елның июлендә хәбәрсез югалган» дигән коры мәгълүматтан гайре сүз юк. Тиешле урыннарга хатлар юллыйм, эзләнәм, интернетта утырам, әмма аның язмышының очына һаман чыга алганым юк. Тик өметемне өзмим. Икенче бабам Әүһади (*әниемнең әтисе, өстәге рәсемдә беренче рәттә — сулдан икенче. — Л.Л.*) хакында исә азмы-күпме беләм сыман...

Эзләнә торгач, интернеттан Әүһади бабамныкына охшаш исем-фамилия язылган бер бит кәгазь — «Именной список безвозвратных потерь начальствующего и рядового состава» табып алдым. Кәгазь өстенә, бит санын күрсәтеп, кызыл карандаш белән 139 дип язылган. Бер биттә 13 сугышчы турында мәгълүмат бар. Исемлектә 146 нчы итеп теркәлгән бабай хакындагы язмалар түбәндәгечә: «Шехрадиев Авходы, 107 с.п., ТАССР, Калининский район, с.Улиман, 1907, Калининский

РВК, умер от ран 2.09.1942 г., похоронен 400 м.сев.зап. д.Херенки. Полавский р-н, Ленингр. обл., жена — Шехрадиева Мусафкира, Тат.АССР, Калининский р-н, с.Улиман».

Эчемә җылы йөгерде. Кайбер төгәлсезлекләр булуга карамастан (бабайның атасы кем икәнлеге күрсәтелмәгән, үзенең исем-фамилиясе дә дөрес язылмаган), әлеге сугышчының нәкъ минем Әүһади бабам булуына бөтенләй шигем калмады. Чыннан да туган җире (Актаныш районы элек Калинин исемен йөрткән) туры килә, туган авылы шул — Олыймән (Улиман), исем-фамилияне ничек ишеткән булсалар, шулай язганнардыр, күрәсең, чынлыкта Шәйхразыев Әүһади (Шайхразиев Аухади), хатыны — Мофаккирә (Мусафкира дип ялгыш язылган). Бераздан тагын шулар ачыкланды: 1964 елда бабайның җәсәден Херенкадан (ул авылны немецлар, партизаннарга калмасын дип, тулаем яндырган) Борки дигән икенче бер авылдагы туганнар каберлегенә (хәзер аны шул зиратта күмелгән генерал-майор С.Г.Штыков (1905-1943) каберлеге дип тә атап йөртәләр) күчереп җирләгәннәр. Күчергәч, ниндидер сәбәпләр аркасында (исем-фамилияләре артык хаталы булганнарны яисә төгәллектә шик уятканнарны ташка уймаганнар), бабайның исем-фамилиясе ташка язылмыйча кала. Бәлки аның җәсәде бөтенләй күчерелмәгәндер, дигән шик тә бар...

Кыскасы, көннәрдән беркөнне (узган елның август ахырында) хатыным Фидания һәм туганнан туган энем Фирдәвис (әниемнең энесе Рөстәмнең улы) белән булдык без бүгенге көндә Новгород өлкәсенә караган, Парфин районына кергән әлеге Борки авылында. Әлеге авылдан читтәрәк урнашкан бер зират янына килеп туктадык. Ләкин ул туганнар каберлегенә охшамаган иде. Шулвакыт безнең янга мотоцикллы бер ир-егет белән мотороллерлы хатын-кыз килеп туктады. «Сугышта һәлак булганнарның каберлеген эзли идек» дигәч, алар икесе беравыздан «Әз генә түргәрәк керегез, Штыков каберлеге шунда», — диде.

Кердек, таптык каберлекне. Мин андагы ташларга язылганнардан бабамның исем-фамилиясен тапмасымны чамалый идем. Шулай да күңел төбендә нәни генә бер өмет чаткысы да бар иде. Ташлардагы исемлекне берничә кат җентекләп карап чыктык, әмма таныш исем-фамилияне очратмадык. Язуларның барчасын фотога төшердем, кайткач, исемлекне иркенләп барлап чыктым: каберлектәге 1002 сугышчының кырыгы мөселман исем-фамилияле булып чыкты (бәлки әле монда керәшен кардәшләр дә җирләнгәндер, анысын инде бер Ходай белә). Кан-кардәшләрнең барысы да диярлек 1942 елның мае һәм 1943 елның августы аралыгында шушы тирәдәге Херенка, Замошка, Кутилиха дигән авылларда җирләнгән булган. Әйткәнемчә, 1964 елда, шушы тирәлектә җирләнгән сугышчыларның җәсәден казып алып, Борки авылы читендәге ошбу туганнар каберлегенә китереп күмгәннәр. Борки авылының урта бер җирендә тагын бер каберлек бар. Монысында 472 сугышчы җирләнгән (башка зираттан күчереп түгел). Шуларның 14е татар булуы ихтимал. Кан-кардәшләребезнең исем-фамилияләрен башка якын-тирә авыллардагы туганнар каберлегеннән дә (ә андый авыллар Парфин районында бихисап!) күпләп очратырга мөмкин (мәсәлән, Парфино бистәсе зиратында җирләнгән 1088 кешенең кимендә 7се (кабер ташындагыча язам: Ахметов Ибрагим, Займулин Юсуп, Зайнулин Ибрагим Хайнович, Вахрутдинов Галидзян (дөресе, бәлки, Фахрутдинов Галимзян?), Гизиев Химитджан (Газиев Хамитзян?)...), Загоскадагы 1080 кешенең 39ы, Парфино авылы зиратындагы 264нең 4есе (Хасанов Самат, Ахметов Ибрагим, Балыкбаев Ахмед, Балыкбаева Ания...), Ясная Полянадагы 1351 мәрхүмнең 31е, Конюховодагы 2056 кешенең 37 есе, Юрьеводагы 647 нең 11е (Абдулов Нуры, Валиуллин Тимер, Салиев Якуб...), Хмелеводагы 149ның 6сы (Газизов Гариф Насибул-

Туган нигездән – кушуч туфрак...

лович...), Тополеводагы 122 кешенең 5есе (Амиров Смагул (Исмәгыйль?), Арзиев Ахмед, Бизарбаев Искандер, Мухамедзянов Косим...), Сельцодагы 329 кешенең кимендә 2се (Исмалов Кургаш, Файзулин Абдулкалим...), Обшадагы 325 сугышчының 6сы (Хуснимардапов Такип, Сотрудинов Расих, Сайдалиев Акзам...), Пола бистәсендәге 505 кешенең 10ысы, Ростани авылндагы 188 кешенең 3есе (Галлямов Шарифан, Имашов Фубай, Кабаев Муслим...), Дубровыдагы 262 кешенең кимендә 10ысы, Ивашоводагы 345 кешенең кимендә 13е, Навельедагы 413 кешенең кимендә 18е, Лукинодагы 154 сугышчының кимендә 4есе, Мануйловодагы 978 кешенең кимендә 24е, Тулитоводагы 136 кешенең 3есе (Баязитов Ахмет Райсатович, Салахутдинов Хайдар Фаркутдинович, Акчурин Белял Келанович...),296 Кече Заходтагы 194 кешенең кимендә 5есе, Кузьминское авылы зиратында җирләнгән 5286 сугышчының кимендә 120се... безнең милләттәшебез булуы ихтимал.

Бәлки, кем дә булса, туганын, якын кешесен танып алыр дип, Штыков каберлегендә җирләнгән газиз кардәшләремнең исем-фамилияләрен үз вакытында «Шәһри Казан» газетасында («Бабам каберен эзләп...» дигән язмамда) бастырып чыгарган идем. Әлеге исемлеккә Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев тә игътибар иткән икән. Күп тә үтми миңа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан, төгәлрәк әйткәндә, идарә җитәкчесе Р.Р.Кадыйровтан М.Ш.Шәймиев күрсәтмәсенә таянып язылган хат килде (№ Л — 18537/1755). Анда мондый юллар бар: «...Язмада телгә алынган 56 солдат һәм офицерның 21е безнең якташ булып чыкты. 29 кеше безнең төбәкнеке түгел, шул сәбәпле алар Татарстан Республикасының Хәтер Китабына кертелмәгән. Исем-фамилияләрендәге төгәлсезлек аркасында 6 сугышчының (хатта язылганча китерәм: рядовой Карамов Валеж (похоронен 29.07.1942 в д.Кутулиха), рядовой Машков Абдрашит (1916 г.р., похоронен 06.09.1942 в д.Замошка), рядовой Хафизов Ахмедзян (1916 г.р., похоронен 18.09.1942 в д.Херенка), Демидов Закей Синотулович (похоронен 11.02.1942 в д.Борки), старшина Шарафутдинов З.К. (похоронен 04.02.1943 в д.Борки), Зинатуллин Гинят (*похоронен 14.10.1942 в д. Борки. — Л.Л.*) чынлыкта кем булуын ачыклап булмады. Чыгышы белән ТАССРдан булган 21 якташыбызның 19ы Татарстан Республикасының Хәтер Китабына кертелгән. Ике сугышчының (берсе минем бабам Әүһади) исем-фа-

милиясе Хәтер Китабының 29 нчы өстәмә томына кертеләчәк».

Инде хәзер Новгород өлкәсе Парфин районы Борки авылындагы туганнар каберлегендә җирләнгән 21 якташыбыз турындагы мәгълүматларга игътибарыбызны юнәлтик (барысы да дөрес һәм анык аңлашылсын өчен һәлак булган яисә ярадан вафат булган сугышчылар турындагы мәгълүматлар русча, исем-фамилияләр дә кабер ташларында язылганча бирелә):

1. **Шайхразиев Аухади Шайхразиевич,** 1909 г.р., место рождения с.Улиманово Актанышского (Калининского) района, мобилизован Актанышским (Калининским) РВК, красноармеец, 107 стрелковый полк, погиб в декабре 1943 года (*дөресе: алган ярасыннан 1942 елның 9 сентябрендә үлә, Херенка авылында җирләнә. – Л.Л.*), похоронен в Новгородской обл., Парфинском районе, д.Борки, братская могила (могила Штыкова). Будет занесен в 29 том Книги Памяти, без места захоронения есть в 2 томе Книги Памяти, стр.559;
2. **Аменев Нурмахмед (Нуриахмет) Закирович,** 1917 г.р., родился в Казани, моб. Свердловским РВК Казани, старшина, 151 стрелковая бригада, 55 стрелковая дивизия, умер от ран 24. 07. 1942 в 67 медико-санитарном батальоне, захоронен Новгородская обл., Староруский район (*хәзер Парфин районы. – Л.Л.*), д.Херенка. Книга Памяти, 11 том, стр.59;
3. **Ахмедзянов Заки Ахунович (Гафурович),** 1906 г.р., родился в с.Куш. Елга, мобилизован Заинским РВК, красноармеец, 228 стрелковый полк, 55 стрелковая дивизия, умер от ран 24. 09. 1942 в 67 медико-санитарном батальоне, захоронен Новгородская обл., Парфинский район, д.Херенка. Книги Памяти, 10 том, стр.32;
4. **Бурганов Мингазидин (Мингазетдин) Хаеткутдинович (Хуснутдинович),** 1905 г.р., г.Менделеевск, мобилизован Бондюжским РВК, гв.Старшина, 9 МСБ (ОУЧБ), 28 гвардейская стрелковая дивизия, умер от ран 15.08.1942 в 35 медико-санитарном батальоне, захоронен Новгородская обл., Парфинский район, территория Поплавского с/с. Книга Памяти, том 16, стр.295;
5. **Габаев (Губаев) Ахметзян Шарифзянович,** 1916 г.р., Будёновский район, с.Вольный Стан, мобилизован Дмитровским РВК Московской обл., красноармеец, 62 стрелковый полк, 10 стрелковая дивизия, погиб 08.08.1942, захоронен Ленинградская (хәзер Новгородская) обл., д.Кутилиха. Книга Памяти, том 23-1, стр.249;
6. **Гарифуллин Унус (Юнус),** 1902 (1912) г.р., совхоз им.Вахитова, мобилизован Мамадышским РВК, красноармеец, 65 гвардейский стрелковы полк, 22 гвардейская стрелковая дивизия, умер от ран 19. 08. 1942, захоронен Новгородская обл., Старорусский район (*хәзер Парфин районы. – Л.Л.*), д.Замошка. Книга Памяти, 16 том, стр.68;

Борки авылы уртасындагы туганнар каберлеге

7. **Гильматов (Гильманов) Фатак** (*Фаттах, Фатых. – Л.Л.*), родился в с.Камаево (*шагыйрь Дифгать Сирай белән Вафирә Гыйззәтуллинаның туган авылы. – Л.Л.*), мобилизован Бондюжским РВК, красноармеец, умер от ран 24.07.1942 в 405 медико-санитарном батальоне, захоронен Новгородской обл., Парфинский район, д.Борки. Книга Памяти, 16 том, стр. 10;
8. **Идиятуллин Рахим (Рахимзян) Хафиятович (Гафиевич),** 1921 г.р., с.Нижние Тиганы, мобилизован Алексеевским РВК, гв.мл. сержант, отдельный учебный батальон, 28 гвардейская дивизия, умер от ран 02.10.1942 в 35 медико-санитарном батальоне, захоронен Новгородская обл., Парфинский район, д.Борки. Книга Памяти, 16 том, стр.108;
9. **Иштуков Абдулла Валеевич,** 1918 (1919) г.р., с.Куштово, мобилизован Апастовским РВК, сержант, 1318 стрелковый полк, погиб 23.02.1942, захоронен Новгородская обл., Парфинский район, д.Борки. Книга Памяти, 4 том, стр.336;
10. **Музагитов Акрам Музагитович,** 1920, Тукаевский район, д.Кугашево, мобилизован Ворошиловским РВК, гвардии лейтенант, командир строевой роты, служил 28 гвардейская химическая дивизия, 89 гвардейский стрелковый полк, умер 07.07.1942 (07.08.1942) в 35 медико-санитарном батальоне, захоронен Новгородская обл., Парфинский район, д.Борки. Книга Памяти, 12 том, стр. 353 не все данные, войдёт в 29 том;

11. **Вофин (Вафин) Хариз (Харис),** 1907 г.р., из г.Казани, красноармеец, пом.командира взвода, служил в 52 отдельной стрелковой бригаде, убит и похоронен 25.02.1942 в Новгородской обл., Парфинский район, д.Борки. В Книге Памяти не было данных на него, будет занесён в 29 том;
12. **Заляв (Заляев) Нури (Нурияздан) Заляевич (Габбасович),** 1905 г.р., родился в Арском районе, призывался Арским РВК, служил 107 полк, 55 стрелковая дивизия, умер 05.06.1942, похоронен 03.12.1942. (*Биредә ике кеше хакында сүз бара булса кирәк. — Л.Л.*). Похоронен у Дома инвалидов. Книга Памяти, 5 том, стр.230;
13. **Хазлеев (Хазиев) Муллахмат (Мулахмет),** 1923 г.р., родился Арском районе, д.Сикертан, призывался Арским РВК, красноармеец, автоматчик, служил в 1274 стрелковым полку, 384 стрелковая дивизия, убит 17.08.1942 г., похоронен 28.08.1942 в д.Ярцево. Книга Памяти, 5 том, стр.521;
14. **Хайруллин Минихай (Минах),** 1910 г.р., родился Кукморском районе, д.Янцыбино, служил в 717 стрелковом полку, 170 стрелковая дивизия, рядовой, убит и похоронен 05.11.1942 в д.Херенка. Книга Памяти, 14 том, стр.524;
15. **Валитов Файзурахман (Файзрахман) Ахмедов (Ахмедович),** 1908 г.р., родился в Казани, мобилизован Верхне-Муллинским РВК Пермской обл., служил в 1276 стрелковом полку, штаб 384 стрелковой дивизии, умер от ран в 469 медико-санитарном батальоне, похоронен 03.11.1942 в д.Борки. Книга Памяти не было на него данных, будет внесён в 29 том ;
16. **Шакиров Нургалей (Нургали) Шакирович,** 1905 г.р., родился Верхне-Услонском районе, п.Идель, служил 42 ЗАП, 52 отдельная стрелковая бригада, номерной, красноармеец, убит и похоронен 03.02.1942 в д.Борки. Книга Памяти. 8 том, стр.199;
17. **Шакирзянов (Закиров Сабирзян Р.),** 1915 г.р., г.Казань, стрелок, красноармеец, служил 52 отдельная бригада, убит и похоронен 12.02.1943 в д.Дубки (д.Борки). Книга Памяти, 11 том, стр.472;
18. **Хасанов Нури Хасанович,** родился в д.Б.Берези, мобилизован Арским РВК, красноармеец, разведчик, служил 52 отдельная стрелковая бригада, погиб 13.02.1942 и похоронен в д.Борки. Книга Памяти, 5 том, стр.557;
19. **Абдрахманов (Габдрахманов) Фабзраман (Файзрахман),** 1923 г.р., с.Тихие Горы, мобилизован Бондюжским РВК, красноармеец, 496 стрелковый полк, 370 стрелковая дивизия, умер от ран, похоронен 06.04.1942 в д.Борки. Книга Памяти, 16 том, стр.301;
20. **Сибгатуллин Набиулла,** 1904 г.р., мобилизован Лаишевским РВК, красноармеец, 1230 стрелковый полк. 370 стрелковая дивизия, умер от ран 05.12.1942 в 462 медико-санитарном батальоне, похоронен в д.Борки. Книга Памяти, 15 том, стр.253;
21. **Гилязов Файзрахман Гилязович,** 1905 г.р., с.Дубъязы, Высокогорский район, мобилизован Кировским РВК, красноармеец, 52 отдельная стрелковая бригада, погиб и похоронен 13.02.1942 в д.Борки. В Книге Памяти в 26 томе на стр. 184 не все данные, войдёт в 28 том.

Кем әйтмешли, боз кузгалды... Югарыда исемнәре әйтелгән бабайларыбызның җәсәде яткан Боркидагы Штыков каберлеге бүген яңартылуга, чын мәгънәсендә тәртипкә китерелүгә мохтаҗ: искереп беткән кабер ташларындагы (*алар куелганга быел илле ел тулды! — Л.Л.*) язулар акрын-акрын җуелып бара, ташларны яңаларга алыштырасы иде, каберлекне әйләндереп алган койма да үзен заманча итеп яңартканнарын көтә. Моны без — исәннәр — эшләмәсәк, тагын кем эшләр?! Минем янә бер теләкхыялым бар: шушы Парфин районы җирлегендә (бәлки ул татарлар күпләп җирләнгән каберлек янында булыр), яуда башларын салган кардәшләребез истәлеген яд итеп, стелла куясы иде. Мондый күркәм эшләрнең безнең республиканың (җитәкчелек дип тә аңларга кирәк) турыдан-туры катнашы белән җиренә җиткереп башкарылганы бар инде. Бу юлы да шундый нәтиҗәгә ирешербез, дигән өметтә калам. Әлеге гамәлне тормышка ашыру юлында Татарстан Республикасы сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннарының (инвалидларының) иҗтимагый оешмасы рәисе, генерал-майор Әхәт Гайнулла улы Юлашев, аның ярдәмчесе полковник Равил Гыйният улы Хәкимов, «Ватан» яшьләр иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Александр Юрьевич Коноплёв актив эшчәнлек күрсәтә башлады инде. Бу эшнең барышы белән Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең дә даими кызыксынып торуы ниятнең уңышлы булачагына һичбер шик уятмый. ■

БЕРЛИННЫ КЕМ АЛГАН?..

Хикәя

Мидхәт Садыйков

– Гали агай, Җиңү бәйрәме якынлаша, ветераннардан кемнәрне чакырырбыз икән? — дип, тәрбия эшләренә җаваплы укытучы, директор бүлмәсенә керә-керешкә, шундый сорау бирде.

— Ничек инде кемнәрне?! — диде директор. — Безнең авылда берәү генә ич инде ул, Зарифулла абый гына.

Укытучы дәшмәде, Гали Галиевич исә сүзен дәвам итте:

— Берлинны алуда катнашкан... Аны чакырмыйча булмый! Ярар, күбрәк үзебез сөйләрбез, концерт куярбыз. Программасын төзе дә, миңа күрсәт!

Сугышта кылган батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнгән, өч тапкыр яраланган, контузия алган Зарифулла бабайның башыннан кичкәннәрен сөйләгәндә кайнарланып китә торган гадәте бар иде. Хисләре тышка бәреп чыга да, теленә күчә аның. Авыл халкы ветеранның мондый сөйләм рәвешенә күнегеп беткән булса да, мәктәп-тәрбия үзәге өчен ятрак күренеш иде бу.

...Ә нечкә күңелле Зарифулла өчен елга бер килә торган Җиңү бәйрәменнән дә зур, тантаналы бәйрәм юк! Ул аны сабый баладай көтеп ала. Кызыл эчле яңа галошларын, орден-медальләр тагылган костюмын алдан ук хәстәрләп куя. Чакырылган кичәләргә, очрашуларга шатланып-куанып бара. Үзенә сүз бирелгәч, хисләнеп-канатланып китә...

— Командирның: «Вперёд, в атаку!» — дигән командасын ишетүгә, акуплардан атылып чыгабыз да, явромайт, китәбез нимесләрне куып. Артларына борылып карарга да куркып, явромайтлар, йөгерәләр... Каян килгән юлларын онытып, ...майтлар, чабалар гына, куып җитешеп тә булмый. Җитмәсә, мин пулемёт белән тегеләрне, явромайт... Артларына ут капкан, керер тишек тапмыйлар, мин сиңайтим...

Аптырашып калган балалар да, авызлары ачылып, торараш булып каткан укытучылар да ни эшләргә белми. Шулчакны директор алдан әзерләп куелган чәчәкләрне эләктереп ала да, амбразурага капланган сугышчы сыман, тиз генә ветеранга илтеп бирә, аны тынычландыра. «Әле сөйләп бетермәдем бит», — диюенә карамастан, урынына илтеп утырта, бүләкләрне дә китереп бирергә куша...

Кемгә ничектер, әмма Зарифулла бабай мондый очрашулардан үтә бер күңел күтәренкелеге белән рухланып чыга. Алар, каршы алырга килгән карчыгы белән, парлашып кайтып китә. Өзелеп калган нотыгын юлда дәвам итә Зарифулла. Күндәм карчыгы исә бу җөмләләрне, дошманга булган бу нәфрәтне мең дә беренче кат ишеткән булса да, картын бүлдерми. Киресенчә, «э-һе, э-һе» дигәләп, иренә көч-куәт кенә өстәп җибәргәли.

Көн кояшлы, матур булганда карт белән карчык, сөйләшә-сөйләшә, арткы урамнан да бер әйләнәһ. Ара-тирә кулларын күтәреп-селтәп җибәрүләреннән Зарифулланың әле «суынып» бетмәгәнлеге чамаланса да, авыл халкы аның чит кешегә сәер булып күренгән мондый гадәтләренә бөтенләй игътибар итми. Киресенчә, юллары туры килгәндә хәлаәхвәл сорашалар, бәйрәм белән котлыйлар. Бу көн — алар бәйрәме, алар көне ләбаса...

Шөкер инде, еллары тыныч. Ветераннарга да кадер-хөрмәт арта. Быел да, хөкүмәтнең яңа программасы буенча, сугыш ветераннары, аларның толлары өчен барлык уңайлыклары да булган дистәләгән йортлар җиткерелде. Шуларның берсе Зарифуллага атап төзелде. Кызганыч, үзе генә күрә алмады. Һичьюгы берәр ел гына яшәп калса да, үкенечле булмас иде кана. Йортның ачкычын тантаналы шартларда тапшырыр өчен, тугызынчы майда ветеранның

хатынын район үзәгенә чакырдылар. Кызы белән икәү бардылар.

— Сүз бирә калсалар, рәхмәт кенә әйт, күп сөйләп торма! — дип, кызы юлда ук әнисенең колагына пышылдап куйган иде куюын. Чөнки әтисе белән ярты гасыр бергә яшәп, холыкгадәтләре, әйтем-сөйләмнәре бер рәвешкә кереп беткәнен ул да бик яхшы белә иде. Әгәр дә ки әнисе үзенең чыгышын: «Минем Зарифуллам, «Вперёд, в атаку!» — дигән команданы ишетүгә, акуптан атылып чыгып...», — дип башласамы?... Аннары туктатып кара син аны! Хәер, ул шулайрак килеп чыкты да.

...Урамда, мәдәният йорты каршында үтәсе чарага алар бик вакытлы килеп җитте. Яше-карты, олысы-кечесе урам тутырып җыелган.

Хәтта микрофонга сулаганны да аргы урамга ишеттерердәй көчле динамикларның эшләве кат-кат тикшерелгәч, бәйрәмне башлап та җибәрделәр.

Район башлыгының котлавыннан, урынбасарының ерактан ук курчак йортлары кебек балкып торган өйләргә төртеп күрсәтә-күрсәтә сөйләгән чыгышыннан соң, ветераннарга шул өйләрнең

Ф.Муллахмәт рәсеме

ачкычлары тапшырылды. Араларында чагыштырмача яшьрәк тә, үткенрәк тә булып күренгән Зарифулла карчыгына җавап сүзе белән чыгарга кушылды. Ул үзе дә шуны гына көтә иде сыман. Түрдә Берлинны алгандай күкрәк киереп басып торган түрәләрне читләтеп үтте дә, ашыгып-кабаланып, сәхнә кебек җиргә менеп тә китте әбекәй.

— «Чемберлин» дигәнен мәктәптә укыган еллардан ук белә идем әле. Аны бер шагыйрь дә язган. Ә менә «Берлин», «нимес», «фашист» дигән сүзләрнең мәгънәсен соңрак аңладым. Бәгыремә уелып калды алар!

Халык арасыннан:

— Кычкырыбрак!

— Карчык кына димәссең, ушлы күренә әле...

— Микрофонга сөйләгез! — дигән сүзләр ишетелеп алды. Ул арада кемдер әбинең кулына микрофон китереп тоттырды. Әбекәй исә аның ни-нәрсә икәненә төшенеп бетә алмады бугай, Зарифулласы кебек, кулларын болгыйболгый, сөйләвен белде:

— Әнием дә, бабам да ярым ач килеш көне-төне басуда эшләде. Шунда җан бирде. Әтием дә яу кырында ятып калды. Без, сугыш чоры балалары, аның газапларын гомер оныта алмабыз!..

Нәфрәт белән, җан ачысы белән әйтелгән бу сүзләргә хис-хәрәкәт тә өстәлепме шунда, әллә чик-чаманы онытып, артыграк талпынуданмы, теге микрофон әбинең кулыннан ычкынып, түрәләргә таба очты. Монысын ук көтмәгән халыкның алдагы рәттәгеләре, куркып, башларын аска иде. Кайберләре куллары белән йөзләрен каплады. «Микрофон-граната»ның бетон плитәгә килеп төшкән мизгелендә ... «берничә снарядның берьюлы шартлаган тавышы»... йөзләгән кешене миңгерәтеп җибәрде: колаклары, күзләре тонды, Берлинны алу операциясе дә шулайрак булгандыр кебек күзалланды. Халык, хушына килеп, елмаешканда-көлешкәндә, Зарифулланың сөекле карчыгы, Берлинны алган кыяфәт чыгарып, сәхнәдән төшеп килә иде инде. ■

СӘЙДӘШ МАРШЫ

Марс Макаров

Д.Нәүрузова коллажы

Сәйдәш маршы! Нинди хозур, балачактан таныш, колакка ятышлы «Сәйдәш маршы» дип халык теленә күчкән сүзсез музыка атамасы! «Сәйдәш маршы» – әнкәй, әткәй дигән кебек, кадерле сүзләр булып, балачактан ук безнең җаныбызга сеңеп калган, күрәсең. Нигә шулай?! Нәрсәдә хикмәт?! Сәйдәш көйләрендә нинди тылсымлы сер ята соң?

...Сугыштан соңгы бик авыр еллар. Ниндидер могҗиза белән яудан исән кайткан башлангыч мәктәп укытучысы Карл Алексеевич, башка йортларның берсендә дә булмаган «Урал» радиоалгычын, бигрәк тә олы бәйрәм көннәрендә, ачык тәрәзә төбенә урнаштырып, Казаннан яңа хәбәрләр, татарча концертлар тыңларга мөмкинлек бирә иде (рәхмәт аңа, авыр туфрагы җиңел булсын!).

...Гомеремдә дә онытмыйм, Җиңү бәйрәмендә тәрәзә тирәсенә җыелышкан халык белән, тәэсирләнеп, Сәйдәш маршын тыңладык. Урамдагы әтәчләр дә, кикрикләрен күтәреп, безнең тыңлаганны күзәтеп торалар кебек тоелды миңа шулчагында. Музыка тынгач, янымда гына басып торган Кулсыз Җәгүр дәдәй (аның кушаматы шулай иде), музыка тәэсиреннән яшьләнгән күзләрен ак болытларга төбәп: «Күп кырылсак та, барыбер без җиңдек!» — диде дә, башын югары күтәреп, горур атлап, үзенең йортына таба юнәлде. Шул мизгелдә мин Сәйдәш көйләренең адәм баласының рухи халәтен никадәр үзгәртү сәләтенә ия булуын сизгән кебек булдым. Кызганыч ки, кешенең рухын күтәрә алырлык музыкаль әсәрләр хәзерге заманда бик сирәк. Интим, сөю, вак-төяк күңел ачу-шоу җырлары басты дөньяны. Шулай булса да, яшәеше яңартылган Татарстан Республикасында Сәйдәш рухы, шөкер, һаман яши. Яши күрсен! Сәйдәшев исемендәге Мәдәни үзәк, Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залы, Сәйдәш һәйкәле, урам исеме хакында уйланырга сәбәп бар, чөнки музыка сәнгате тарихында Салих Сәйдәшев югары баскычта тора. Чынында ул — профессиональ милли музыкага нигез салучы. Иң мөһиме — маршына үрелеп, ул үзе дә легендар шәхес булып, халкыбыз күңелендә яши. Бу марш милләтебезнең гимны кебек тә кабул ителә сыман... Казанның тимер юл вокзалында аны тыңлаган саен, ирексездән башка шундый уй килә: бу — безнең милли гимныбыз!

Инде легендар маршның кайчан һәм ничек язылу тарихына күчик. Заманында Төркестанда татар бригадасы белән командалык иткән, Укчылар полкының командиры, үзебезнең татар генералы Якуп Чанышев, 1929 елда, инде ул вакытта ук танылып өлгергән яшь композитор Салих Сәйдәшевкә, Кызыл Армиянең 11 еллыгына багышлап марш язарга тәкъдим ясый. Табигате белән тыйнак Салих:

— Булдыра алырмынмы, Якуп абый, бигрәк тә җаваплы эш бит, — ди. Әмма маршның беренче төп көй темасын җиңел табуы — Сәйдәшнең илһамы күтәрелеп китүенә сәбәп булгандыр, күрәсең. Маршның калган ике көй темасын да ул кыска вакыт эчендә тәмамлый. Марш тематикасы буенча традицион формада — өч кисәктән төзелгән булып чыга. Яңа гына табадан төшкән «Кызыл армия маршы» тәүге тапкыр элеккеге Татар дәүләт академия театры бинасында моннан 85 ел элек — 1929 елның 23 февралендә башкарыла.

Климентий Ворошилов яңа татар маршын тыңлап хәйран кала һәм авторга үзенең алтын кул сәгатен бүләк итә.■

ҖИҺАНДА СҮЗЕ КАЛЫР

Таһир Гыйлаҗев

Татар милли-мәдәни тарихы күренекле һәм бәһале шәхесләргә бай. Көч-куәтләрен, акыл-гыйлемнәрен, рухи егәрлекләрен татар халкына хезмәт итүгә багышлаган, төрки-татар, мөселман халыкларының иҗтимагый-фәлсәфи, әдәби-гыйльми фикере һәм мәдәнияте тарихында дан казанган зыялы затлар арасында Хатыйп Миңнегуловның могтәбәр урыны бар.

Хатыйп Миңнегулов — күпкырлы һәм киң диапазонлы, фәнни хезмәтләре белән ил күләмендә генә түгел, ә төрки-мөселман дөньясында да яхшы танылган, югары бәяләнгән, әдәбият гыйлеме бакчасында үз сүзен әйткән һәм фәнни мәктәбен булдырган тюрколог-галим.

Ул Алтын Урда чоры әдәбиятының күренекле шагыйре Сәиф Сараиның тормыш юлын һәм иҗатын тикшерүгә багышланган монографиясе (1976) белән үк әдәбият фәненә зур гыйльми потенциалы булган галим килүен белгертте. Хезмәттә С.Сараи иҗаты, ныклы фәнни-теоретик нигезгә утыртылып, тюркология, татар әдәбияты фәне, тугандаш халыкларның нәзари фикере һәм көнчыгыш мәдәнияте ирешкән казанышлар белән тыгыз бәйләнештә тикшерелә. Х.Миңнегулов әдәби-тарихи фикерне шагыйрь тормышына һәм рухи мирасына караган яңа фактлар, әдәби күренешләр белән баета. Хезмәт авторы атаклы фарсы шагыйре Сәгъдинең «Гөлстан»ы белән С.Сараиның «Гөлстан бит-төрки» поэмалары арасындагы аермалыкларны, әсәрнең жанр үзенчәлекләрен, сәнгати алымнарны аерып чыгара. Батырлыкка һәм мәхәббәткә дан җырлаган «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасын, чорның иҗтимагый-тарихи вакыйгалары яссылыгында карап, автор С.Сараиның тормыш юлы һәм сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләре хакында мөһим нәтиҗәләр ясый. Урта гасыр Яңарыш чорының икенче вәкиле Котбка багышланган «Котб» (1976) монографиясе дә галимнең фән

дөньясында ныклы адымнар ясавы турында сөйли.

Х.Миңнегуловның «Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар» (1988), «Татарская литература и Восточная классика: вопросы взаимосвязи и поэтики» (1991), «Татарская литература и Восточная классика» (1993) һ.б. монографияләре шушы юнәлештәге тикшеренүләрнең мантыйкый дәвамы булып тора. Галим фактологик, гыйльми-теоретик һәм әдәби-тарихи материал белән оста эш итә: аларны чагыштырма-тарихи планда бәяләп, татар әдәбиятының төрки-мөселман мәдәниятенең аерылгысыз, гасырлар дәвамында үрелеп үскән өлеше булуы хакында зур нәзари гомумиләштерү ясый.

Х.Миңнегулов эшчәнлегенең бер тармагы XX гасыр башы әдәбияты белән бәйле. Мәсәлән, аның хезмәтләрендә узган гасырда фән буларак формалашкан Тукай гыйльмиятенең аерым аспектлары тикшерелә. Аның иҗатында урта гасыр татар поэзиясе һәм Шәрык классикасының күп гасырлык бай традицияләрен иҗади үстерелеше, шагыйрьнең сәнгатьчә фикерләвенә йогынтысы ачыклана. Галимнең шулай ук Ш.Бабич, Дәрдмәнд, С.Рәмиев, М.Гафури шигъриятләренә багышланган монографик мәкаләләре бар.

XX гасыр ахырындагы кискен иҗтимагый-рухи үзгәрешләр галимнең бу юнәлештәге фәнни эшчәнлегенең офыкларын тагын да киңәйтергә мөмкинлек бирде. Әдәби-мәдәни яңарышның хәбәрчесе булган мәшһүр язучы Гаяз Исхакыйның исемен, бай рухи мирасын халкына кайтаруда Х.Миңнегулов җиң сызганып эшкә керешә. Беренчеләрдән булып, ул әдип сукмакларыннан эз алып, Финляндия, Төркия китапханәләрендәге, чит илләрдә гомер кичергән мөһаҗир татарларның шәхси архивларындагы Гаяз Исхакыйга караган бай фактологик материалны барлый. Гаҗәеп дәрәҗәдә сабырлык һәм ихтыяри көч белән аларны текстологик яктан эшкәртеп һәм фәнни теоретик яктан тикшереп, «Исхакый мөһаҗирлектә» (1999), «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты»(2004) дигән монографик хезмәтләрен яза.

Г.Исхакый турындагы эзләнүләр бөтенләй яңа дөньяга ишек ача һәм ул чит илдә яшәгән татарларның әдәбияты һәм матбугаты белән кызыксына башлый. Х.Миңнегуловның «Чит илләрдәге татар әдәбияты» (2007) китабы — шушы юнәлештәге эшчәнлегенең тагын бер матур нәтиҗәсе. Бу хезмәттә Г.Исхакый йолдызлыгының нурланышын көчәйткән язучының шәкертләре, мәсләктәшләре — Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш, Хәсән Хәмидулла, Ләбиб Каран, Исфәндияр Ишгай, Минһаҗ Исмәгыйли кебек әдипләрнең иҗатларына бәя бирелә, тормыш сукмаклары хакында бай мәгълүмат урнаштырыла.Татар рухи, әдәби-мәдәни мирасыбызның бер өлеше булган Кытайда, Алманиядә, Финляндиядә татарча нәшер ителгән газета-журналлар тарихына, эчтәлегенә караган бай фактологик материал һәм гыйльми күзаллаулар хезмәтнең гүзәл сәхифәләре булып тора.

XX-XXI гасыр чикләрендә Х.Миңнегуловның татар әдәбияты белеменең, татар халкы рухи мирасының, милли-мәдәни яшәешенең төрле чорлары һәм мөһим мәсьәләләре гәүдәләнгән, сүз сәнгатенең күренекле шәхесләренә-язучыларына багышлаган «Дөньяда сүземез бар...» (1999), «Гасырлар өнен тыңлап» (2003), «Записи разных лет» (2010) хезмәтләре нәшер ителде һәм алар татар укучысы тарафыннан җылы кабул ителде.

Соңгы елларда Х.Миңнегулов тугандаш-төрки халыкларның әдәби-мәдәни мирасын тикшерү һәм яңача бәяләү юнәлешендә мавыгып, матур бер үҗәтлек белән эшли башлады. Төрки әдәбиятларның методологик, әдәби-теоретик проблемаларына багышланган йөзләгән

фәнни конференцияләрдә, форум-симпозиумнарда, конгрессларда ясалган докладлардан тыш, галим «Төрки әдәбиятлары энциклопедиясе» томнарын, Төрки Академия җитәкчелегендә төрки кавемнәрнең әдәби ядкярләрен туплаган антологияләрне төзүдә, төрки халыкларның уртак хәзинәсен комплекслы тикшерүгә багышланган «Төрки дөньясы» альманахларын чыгаруда һ.б. актив катнаша. Аның шушы көннәрдә генә «Төрки сүз сәнгате» (2014) дигән хезмәте басылып чыкты. Китапта пратөркиләр чорыннан алып XXI гасыр башына кадәр төрки сүз сәнгатенең яралуы, формалашуы һәм үсеш баскычлары тарих, дин, халык авыз иҗаты һәм язу тарихы белән тыгыз бәйләнештә яктыртыла. Хезмәттә әдәби барышның төп тенденцияләре, төрки дөньяның киңкырлы эчке һәм тышкы багланышлары аерып чыгарыла, билгеле бер дәрәҗәдә традицияләр, поэтика һәм тәрҗемә проблемаларына да игътибар ителә. Төрки әдәбиятның олы әдипләре Йосыф Баласагунлы, Ясәви, Кол Гали, Юныс Әмрә, Нәвои, Мәхтүм Колый, Абай, Тукай, Чыңгыз Айтматов иҗатлары хакында мәгълүматлар һәм күзәтүләр дә урнаштырыла.

Х.Миңнегуловның әдәбият белеме, мәдәният өлкәсендәге һәм педагогик-методик эшчәнлегендәге фәнни ачышлары, ирешкән казанышлары ил күләмендә генә түгел, төрки-мөселман дөньясында таныла һәм югары бәяләнә. Ул — Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе (1994, 2005), Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1995), Кол Гали һәм Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләкләр иясе (1998, 2005), «Халыкара ел кешесе» (Англия, Кембридж, 1998), Халыкара казак-төрек университетының (Төркестан) «Шәрәфле профессоры» (2004), «Казан университетының мактаулы профессоры» (2009) һ.б.

Хатыйп Миңнегуловның гомер йомгагын беркадәр генә сүтеп караганда да — тау чаклы эшләр эшләнгән, төрле шәкелдә хезмәтләр язылган һәм биниһая игелекле гамәлләр кылынган. Милли әдәби-мәдәни күтәрелеш елларында миңа остазым белән Әлмәт, Чаллы, Чабаксар һ.б. шәһәр-төбәкләрдәге югары уку йортларында методик-педагогик ярдәм күрсәтү максаты белән, лекцияләр укырга туры килде. Юлдашың үзеңнән әйбәт булсын дигәндәй, Хатыйп абый миңа ышанычлы, көр күңелле һәм истәлек-хатирәләргә бай шәхес буларак ачылды: ул елларны хәзер дә сагынып искә алам. XIX-XX гасыр иҗтимагый-рухи яңарышы вәкиле энциклопедист галим Ризаэддин Фәхреддиннән: «Син бу кадәр эшләргә ничек өлгерәсең?» — дип сорагач, — «Мин бервакытта да өстемә кояш төшермәдем!», — дип җавап биргән. Шуның шикелле, бик тыйнак шартлары булган кунакханәләрдә яшәгән вакытларда мин Хатыйп Йосыф улының моңланып көйләгән көйләре астында йокыдан уянуга, ул инде әллә никадәр эш эшләргә өлгергән: көндәлек матбугат белән танышкан, курс-диплом эшләрен тикшергән, үзе белән алып килгән яңа мәкалә корректурасын карап чыккан була иде. Яшәү рәвеше белән генә түгел, ә белеменең киңкырлы булуыннан чыгып та, аны коллегалары Р.Фәхреддингә тиңләгән иде. Фәнни-гыйльми эшчәнлектә, педагогик хезмәттә генә түгел, ә яшәештә, тормышта да тәртип, системалылык, оешканлык, җаваплылык, җитди мөнәсәбәт белән аерылып тора ул!

Татар халкының гасырлар тирәнлегеннән килгән милли-әхлакый кыйммәтләре белән бәйләнеш, заман сулышын тоеп, киләчәккә карап эш йөртү, яшәү ямен һәм мәгънәсен милләткә һәм әдәбиятка хезмәттә билгеләү Хатыйп Миңнегулов ирешкән казанышларның нигезе булып тора. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

АЗАК тар. — Азов. Дон елгасы тамагындагы шәһәр. *Адзак* язылышы да очрый. Атаманың этимологиясе бәхәсле: осетиннарның элгәрләре асс халкы атамасы ярдәмендә, төрки *азан* (түбәнге) сүзенә бәйләп аңатырга тырышу да бар. 1067 елда бу шәһәрне басып алган кыпчак ханы *Азум (Азуф)* исеме белән аңлату нигезсез дип исәпләнелә. Бередә я.э.га кадәр III гасырда греклар Танаис (Таис, Тана) шәһәрен нигезләгәннәр. Хәзәр-кыпчакларның *Азау* торлагы шушында булган. Урта гасырларда Европадан Кытайга *Бөек ефәк юлы* шушыннан үткән.

М.Әхмәтҗанов бу шәһәрнең исеме татарча *Аҗак* рәвешендә яңгыраган, дип фараз итә һәм аны Татарстанда Арча шәһәре янында урнашкан *Әҗәк* авылының атамасы белән бәйли. Татарстанның Актаныш якларында янә бер татар авылы «Әҗәкүл» дип атала һәм бу авылга нигез салган бабайлар XIV-XV гасыр чикләрендә Кырымнан килгән нәселләр икән. Шул рәвешле, бу авылларның исемен Азов/Азак шәһәре белән бәйләнештә карарга мөмкин.

АЗАН, АЗАН ӘЙТҮ – Чакыру мәгънәсендә. Мәчеттә җомга намазы укылачак вакытны халыкка игълям итү зарур күрелгәч, сәхабәләр тарафыннан кыңгырау кагу, быргы кычкырту, ут яндыру кебек ысуллар куллану тәкъдим ителгән була. Ләкин Рәсүлулла хәзрәтләре, боларның нәсраниларга (христианнарга), яһүдиләргә һәм мәҗүсиләргә иярү булуын сәбәп күрсәтеп, тәкъдимнәрне кабул итми вә азан кычкырырга карар бирелә. Соңыннан Рәсүлулла мәчетне ут белән яктыртуны рөхсәт итә. Димәк, бүгенге мәчетләрнең манараларын электр уты белән яктыртуда җәдитлек тә, бидгать тә юк. Азанны радиодан әйтүне исә заман таләбе дип аңлатырга туры килә, чөнки бүгенге шау-шулы шәһәр шартларында азанчы тавышы күмелеп кенә калыр иде.

Ривайәтләргә караганда, азан әйтүне Мөхәммәд 622-623 елларда (һиҗрәнең беренче елында) кертә, ә азан «әс-Салат җәмигатән» – «Намаз – бергәләп» сүзләреннән генә торган.

Рәсүлулла заманында җомга намазы бер генә мәртәбә әйтелгән. Госман хәлифә вакытында Мәдинә зурая башлагач, тагын бер азан өстәгәннәр.

Хәзерге вакытта сөнни азаны җиде гыйбарәдән (формуладан) тора: 1) Тәкбир – «Аллаһү әкбәр!» – «Алла бөек!» (4 тапкыр әйтелә); 2) «Әшһәдү әл лә иләһә илләллаһү!» сүзләре – «Алладан башка тәңре юк икәненә таныклык бирәм» (2 тапкыр әйтелә); 3) «Әшһәдү әннә Мөхәммәдәр-Рәсүлүл-лаһи» сүзләре – Мөхәммәд – Алланың илчесе икәненә таныклык бирәм!» (2 тапкыр әйтелә); 4) «Хәй'йә галәс-саләһ» – «Намазга ашыгыгыз!» сүзләре (ике тапкыр әйтелә); 5) «Хәй'йә галәл-фәләх» – «Газаптан котылырга ашыгыгыз!» сүзләре (2 тапкыр әйтелә); иртәнге намаз алдыннан: «әс-Саләтү хайрүм-минән-нәүм» – «Намаз уку йокыдан хәерлерәктер!» сүзләре өстәлә (тәзвиб, ике тапкыр – бу сүзләрне Мөхәммәд Пәйгамбәрнең беренче мөәззиннәреннән Өмми Мәктум әйткән, Рәсүлулла моңа каршы бул-

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

маган); 6) Тәкбир – «Аллаһү әкбәр!» сүзләре (2 тапкыр әйтелә); 7) Шәһәдә – «Лә иләһә иллә-л-Лаһү» сүзләре (1 тапкыр әйтелә).

Шигый азанында исә бишенче һәм алтынчы формулалар арасында бер җөмлә («Иң күркәм эшкә килегез!») өстәлгән була. Шигыйларда азанны теләсә кайсы мөселман әйтә ала.

Мөәззин бу гыйбарәләрне әйткәндә, Мәккә тарафына карап баскан хәлдә, ике кулының баш һәм имән бармаклары белән колак очларын тотып тора (Әхмәтһади Максуди хәзрәт азан әйтүче «ишарә бармакларын колак очларына куя», — дип яза). Бу гамәлне *колак кагу* дип тә атыйлар. Азан укучы кеше тәһарәтле булырга тиеш.

«Хәй'йә гәләс саләһ» сүзләрен уң тарафка карап, «Хәй'йә гәләл фәләх» сүзләрен сул тарафка карап әйтү мөстәхәб.

Азан гыйбарәләрен яңа туган баланың уң колагына пышылдап әйтәләр (сул колагына камәт әйтелә). Җенләнгән дип уйлаган кеше белән дә шуны ук эшлиләр. Балага исем кушканда азан вә камәт әйтү йоласы да киң таралган. Дөрес, бу мәсьәләдә фикер башкалыгы бар. Мәс., Нурулла Мөфлихун хәзрәт Арыслани бу йолага кискен каршы чыгып: «Пәйгамбәребез галәйһиссалатү вәссәлам заманында һәм аннан соңгы гасырларда азан һәм камәт намаздан башка һичбер нәрсәгә кулланылмаган һәм һичкемнең баласына исем биргәндә азан һәм камәт әйтмәгәннәр… Һичнәрсә белмәгән сабыйга азан вә камәт әйтү белән аның рухы һәм тәне үзгәрми», – дип яза. Ләкин, мәсәлән, кыргызларда балага ат кушуны мөәзин азан әйткән вакытка туры китергәннәр, шуңа күрә *азандагы ат* – беренчел, иң баштагы исем.

1998 елның 14 ноябрендә Казанда республика күләмендә азан әйтүчеләр бәйгесе булып узды. Бәйгедә төрле төбәкләрдән килгән мөәззиннәр һәм, гомумән, барлык теләүчеләр катнашты. Беренче урынны Россия Ислам университеты шәкерте Шәүкәт Әбүбәкеров, икенче урынны Балык Бистәсе районының имам-мөхтәсибе Гомәр хәзрәт Садыйков алды. Өченче урын Чистай шәһәренең Үзәк мәчете мөәззине Абуталип Нурамиевка бирелде. Бәйгедә катнашкан иң яшь азанчы Исраев Маратка (Азнакай ягыннан) 10 яшь кенә иде.

Җиде азан – авыру кешенең хәлен яхшырту өчен җиде тапкыр ясин укыту. //*Җиде азан кычкырту. Җиде азан белән өшкертү. Манара азаны. Минбәр азаны.*

АЗАР-БИЗӘР – Туган-тумачалар арасында килеп чыккан низаглар. «Азар һәм бизәр сүзләре, асылда, борынгы Иран мифологиясендәге *Асура* һәм *Мизра (Митра)* – җир йөзендә тәртип саклаучы ике фәрештә исемнәренә кайтып кала» (Р.Әхмәтьянов). Шушы ук автор татар-башкорт җырларындагы *Айзар, гизаем, Байзар, гизаем* кушымтасын да шушы мәҗүси Асура һәм Мизра исемнәре белән бәйли.

АИТ г. – Татарда исем булып та йөргән сүз (мәс., *Аитов* фамилиясендә сакланган), *гает* (*гайд* – бәйрәм) сүзенең башкача әйтелеше. Татарда тагын *Гает, Гаетбай, Гаетгол, Гаетмөхәммәт, Гаетхан, Гаетхуҗа, Гаетҗан* исемнәре дә булган. Мондый исемнәрне гает бәйрәме көнне туган балага кушканнар. «Гаетмөхәммәт» исеменең фонетик һәм диалекталь вариантлары арасында очраган *Аетмөхәммәт, Аетмәт, Аймәт, Әйтмәт* исемнәренә игътибар итик. Мондый фонетик үзгәрешләр башка төрки телләргә дә хас. Мәс., күренекле кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның фамилиясе *Айт* һәм *Мөхәммәд* исемнәреннән тора, Мөхәммәд биредә *Мамат-ка* тикле кыскарган гына. (Алим Гафуров катлаулы исемнәрдә *Мамат*-ның *Мат*-ка тикле кыскаруын искәртеп китә; бездә, мәсәлән, *Колмәт* исемле авыл бар).

АЙ (ӘЙ) – Чиләбе өлкәсе һәм Баш-

кортстан территориясендә ага торган елга, Уфа елгасының сул кушылдыгы. «Башкорт АССРның топонимнар сүзлеге» елга исеменең «әйле» этнонимыннан булуы ихтимал, дип саный. Озынлыгы – 549 км. Аның Башкортстандагы уң кушылдыгы *Ака (Ока)* дип атала.

АЙ ТӘҢРЕСЕ бор. – Төрки мифологиядә Баш Тәңредән, аннары Йер-су һәм Ћомайдан соң кече тәңреләр рәтендәге алла («Татар мифлары» китабы, төзүчесе Галимҗан Гыйльманов).

Халык ышанулары буенча, Ай калыкканда кычкырып көләргә, зәхмәтле урынга, шулай ук мал суйган җиргә утырырга, шакшы су чыгарып түгәргә, тырнак кисәргә, ялгыз гына мунча керергә ярамаган. Ай калыкканда изге теләкләреңне теләргә, Тәңредән бәхетеңне, тәүфигыңны сорарга киңәш иткәннәр.

Айны кызларның химаячесе, яклаучысы дип исәпләгәннәр. Хатын-кызлар, бигрәк тә кияүгә чыкмаган кызлар, айлы алка тагып йөрергә тиеш булган.

«Борынгы төркиләр Айны вакыт белдерү өчен мөкаддәс санийлар вә шул инсаннарның эшләренә тәэсир итә, дип ышаналар иде» (Г.Баттал, «Татар тарихы»). Кол Шәрифнең «Зафәрнамәи вилайәте Казан» («Казан өлкәсенең җиңүе») дигән хезмәтеннән күренгәнчә, «Болгар вилаяте, җиденче икълимендә Ай тәрбиясендәдер һәм Айның яклавындадыр».

Мәс., тулган Айның беренче төнендәге хыял чынга аша дип өметләнгәннәр, Ай кими башлаган чорда киләчәккә ният-планнар кормаска киңәш ителгән. Ерак сәфәргә Ай тулысында чыгу хуп күрелгән. Тулган Ай вакытында туучылар озын гомерле, сәламәт булалар икән. Ир балалар гадәттә Ай тулган чорда яралалар, дип тә ышанганнар. Ай кимегән чакта чәч кистерергә дә кушмаганнар, чөнки чәч коелучан була, дип уйлаганнар.

Татарлар Айның түгәрәк йөзендә (Маһруйда) көянтә чиләкле кыз (Айсылу яки Зөһрә) сурәтен күрәләр.

Айны төштә күрү, гадәттә, яхшыга юрала. Мәс., төшендә Ай күргән мөселман байлык һәм муллык, мәртәбә казаныр, карендәшләреннән сөенер. Тулган Ай күрү бәхетле мәхәббәт, саулык-сәламәтлек, эшеңнең уңышлы төгәлләнәчәген хәбәр итә. Яңа айны күрү – никахка. Ай тотылганны күрү йогышлы авырулар турында кисәтә. Әгәр төштә Ай кан-кызыл төстә күренсә – сугышка һәм ызгышка, дип юрыйлар.

Йокыдагы кешенең күзенә төшеп торган Ай яктысы аның төшендә хатын-кыз сурәте барлыкка китерә, диләр. Сүрән Ай нурлары йокыдагы аң төпкелендә Айсылу сурәтен уятсалар, гаҗәп түгел.

АЙАРА — Иске Ай бетеп яңа Ай туганчы булган ара. Ике-өч тәүлек дәвам итә. Шуңа күрә ай башын билгеләүдә кыенлыклар килеп чыккалый һәм кайчак, Г.Тукай үзенең «Ай башы» дигән фельетонында (1908, 20 сентябрь саны) әйтеп киткәнчә, «Истамбулда, Казанда, Кырымда, Хиҗазда вә гайре җирләрдә ай башы якшәмбе көн, бары ялгыз Бохарада гына шимбә көн булган», имеш. Шундый хәл аркасында, заманында Мәрҗани хәзрәтне дә имамлыгыннан читләштереп торганнар. Мондый очракларда яңа ай туган мизгелне астрономнардан белешү зарур. Моңа Мөхәммәд Пәйгамбәр дә каршы булмаган.

Латинча — interlunis.

АЙВАЗ ф. — Өй хезмәтчесе мәгънәсендәге сүз. Кеше исеме буларак татарга Ираннан, Төркия һәм Азәрбайҗаннан кергән, дип исәплиләр (Г.Ф.Саттаров).

Башка фикерләр дә бар. Мәс., Р.Әхмәтьянов Айваз исеме фарсыча «Якты ай», «Тулган ай» мәгънәсен белдерә дип саный.

Айвазов фамилиясе, Казан татарларыннан тыш, Дунай болгарларында да бар икән. Айвазовский — мәшһүр рус рәссамы. ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның май ае

Зур янгын

29 апрельдә көндезге 4 сәгатьтә чыккан беренче янгын төнге сәгать уннарда читкә таралудан имин хәлгә килде. Тирә-яклар уттан киртәләнеп өлгерде.

Бу беренче янгын Ишморатов[1] бухгалтеры, потомственный гражданин Ибраһим Мозаффар углы Яхинның ат абзары өстендәге печәнлектән чыккан. Яхинның йорты 15 мең сум тора икән. Бу йорт «Якор» ширкәтенә 7 мең сумга страховать ителгән. Бу беренче янгын Ком асты, Тәгәрҗеб, Большая Мещанская[2], Екатерининская[3] урамнары араларындагы кварталларда булып, барлыгы 86 йорт, төрле-төрле маллар тулы күп складлар һәлак булды[4].

Икенче янгын. Шул ук 29 нчы апрельдә, төнлә сәгать 12дә янә бик зур янгын күтәрелде. Бу янгын Евангелистовская[5] урамында торучы Казан мещаны Юныс Гыйльман углы Рәхимов йортыннан, печәнлектән башланган. Бу соңгы янгында 9 йорт хуҗасының 10 йорты янган.

Беренче вә икенче янгыннарның чын сәбәпләре хәзергә мәгълүм түгел, тикшерү дәвам итә.

Ләбибә ханым[6] мәктәбе

Ләбибә ханым мәктәбе яну сәбәпле, анда булачак имтиханның шимбә яки якшәмбе көндә Мөхәммәдҗан Кәримов[7] йортында булуы ихтимал.

1914. — №402. — 1 май.

Фаҗига вакытында күренгән шатлыклы галәмәт

Янучыларның мал-мөлкәтен ташыган егетләрнең бер авыздан биргән шәһадәтләренә караганда, иң фәкыйрь квартирларның нәрсәләре арасында да яңа татарча китапларның барлыгы күзгә бәрелерлек булган икән. Янгында күп хезмәт иткән бер егет әйтә: «Мин иң фәкыйрь квартирларның

---

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Габдрахман Әхмәт улы Ишморатов (1857-1922) — бәз ману, чәй үлчәү-бүлү лавкалары («Ишморат чәе»), май язу һәм ат заводлары хуҗасы, эре җирбиләүче.

[2] Хәзерге Нариман урамы.

[3] Хәзерге Тукай урамы.

[4] Газетаның 8 май санында (№408) бирелгән соңгы мәгълүмат буенча, беренче янгында 87 йорт хуҗасының 86 йорты (капка хисабы белән), таш һәм агачтан гыйбарәт 104 склад, каралтылар янган. Биредә янгын «Олуг, Кече Мещанская, Чокыр асты, Екатерининская урамнары арасында» булган, дип әйтелә.

[5] Хәзерге Татарстан урамы.

[6] Хөсәенова Ләбибә Һади кызы (1880-1920) — педагог. 1904 елда Казанда кыз балалар өчен үз мәктәбен оештыра.

[7] Мөхәммәдҗан Кәримов — Казандагы данлыклы «Матбагаи Кәримия» басмаханәсе, «Бертуган Кәримовлар сәүдә йорты» хуҗаларыннан берсе.

нәрсәләрен ташыштым, 30-40лап квартирга кереп чыктым. Шуларның һәрберсендә берникадәр яңа татарча китаплар барлыгын күрдем. Мондый китаплар бер дә булмаган бер квартирны булсын, очрата алмадым.

Кояш. — 1914. — №403. — 2 май.

Ике кат янучылар

Әүвәлге янгында квартирлары янган бик күп фәкыйрь гаиләләр Юныс Гыйлманов вә аның күршеләре йортларында тора торган белеш-танышлары янына вакытлыча күчеп торганнар икән. Икенче янгында бу кешеләрнең әүвәлге янгыннан котылдырып калган нәрсәләре дә янып беткән. Шулай итеп, бик күп мескиннәр бер көн эчендә ике янгын фаҗигасен күргәннәр. Бу бичараларның хәлләре соң дәрәҗәдә мөшкелдер. Болар менә инде икенче көн ачык күк астында гомер итәләр.

Кояш. — 1914. — №403. — 2 май.

Китаплар – иң яхшы юанычлар

Ике кат янгынга эләккән бичаралар арасында биш балалы, керләр юуучы бер тол хатын бар. Әүвәл янгыннан саклап калган вак-төяге аның икенче янгында янып беткәнгә, бичара хатын биш баласы белән тирес башында, ачык күк астында калган. Балаларның кечкенәләре елыйлар, аналарын гаҗиз итәләр икән. Әмма бераз олуграклары үзләренең уттан котылдырган китапларын укып юанганнар. Алар өчен фаҗигале 30 апрель көнен, ул бичаракайлар, тиреслек башында, ачык күк астында, ач карыннан китаплар укып уздырганнар.

Кояш. — 1914. — №403. — 2 май.

Пороховойда сабан туе

Пороховойда сабан туеның якшәмбе көн актык көне иде. Сабан туеның ике көнендә дә хатын-кызлар катнашкан иде. Бу соңгы көндә сабан туе Пороховойдагы янгынга каршы тору фиркасе файдасына вә шул фирка идарәсендә ясалды. Сабан туе өчен бик күп бүләкләр әзерләнгән, бик күп акчалар тотылган. Сабан туеннан килгән акча күп булса да, саф файда 200 сумнар чамасы гына калыр, дип хисаплана. Сабан туе Э.С.Семёнов һәм Г.Монасыйпов идарәсендә үтте. Иң дикъкать ителерлек җире дә, хатын-кызның клублардагы шикелле ирләр белән бергә булулары, исерек кешеләрнең очрамавы булды.

1914. — №412. — 13 май.

Каберстан мәсьәләсе

Чәршәмбе көн 14 нче майда «Амур» залында Казанның мөселман җәмәгасе (мәхәлләләр әһалисе) вәкилләренең мөселман каберстанын киңәйтү хакында мөзакәрә мәҗлесе булды.

Шәһәр главасы Петербургтан кайткач, шәһәр управасы тарафыннан Дахилия нәзарәтенә [Эчке эшләр министрлыгына] мөселман каберлекләрен киңәйтергә рөхсәт сорап мөрәҗәгать ителгән үтенечтә тиешле мәгълүмат җиткермәгәнлек сәбәпле, туктап калганын хәбәр биргән иде. Инде хәзер мөселман җәмәгасе, Екатеринбург тимер юлының зиярат яныннан үтүе карарлаштырылганлыктан, тимер юл өчен җир кисү мәсьәләсе алда тор-

ганга, каберстан мәсьәләсенең ашыгыч хәл ителүен бигрәк тә тиешле таба. Шунлыктан, бер яктан, управаның тиешле мәгълүматны тизрәк бирүе, икенче яктан, нәзарәткә баргач та, эшнең ашыгычрак хәл ителүе кирәк. Менә шул җәһәтләрне игътибарга алып, мөселман җәмәгасе Петербургка бер вәкил җибәрүне мәслихәт күрә.

Вәкилләр җыелышы түбәндәге карарларга килде: 1) Петербургка вәкил итеп Габдрахман Мирсәлимовны җибәрергә; 2) аңа Петербургта бер ай торырга 400 сум бирергә; 3) әгәр Петербургта бер айдан артык торырга туры килсә, артык торганы өчен шул нисбәттә арттырырга; 4) Габдрахман Мирсәлимовның, моннан элек тә шул ук каберстан эше белән Петербургка барырга дип, хосусый кешедән 200 сум бурычка алып, сарыф иткән бурычын түләргә. Мәҗлес бу акчаларны халыктан җыеп бирергә карар бирде. Акча җыю өчен сигез кеше тәгаен ителде.

Каберстанга шәһәр җиреннән урын аерып, шәһәр планын үзгәртү эшен раслату өчен тиешле мәгълүматны управа якын арада җибәрәчәк. Мөселман җәмәгасе вәкиле үтенечләр белән тиеш урыннарга мөрәҗәгать итәчәк.

«Русская Швейцария» бакчасы

Гуляние

Пәнҗешәмбе көн 15ендә «Русская Швейцария» бакчасында янганнар файдасына «гуляние» ясалды. Бакчага керү өчен билет бәһасе 10 тиен иде. Керүчеләргә 12210 билет сатылган ки, моннан килгән варидәт [керем] — 1221 сум. Лотерея билетлары 5 ярым сәгатьтә инде беткән иде. Лотереядан килгән сбор — 2800 сум.

1914. — №415. — 18 май.

Кызлар өчен тиҗарәт [сәүдә] мәктәбе

Казанда кызлар өчен тиҗарәт мәктәбе ачылды. Уку вакыты 8 ел булып, ике хәзерләү сыйныфы да бар. Беренче хәзерләү сыйныфына балалар имтихансыз кабул ителәләр.

Бу мәктәп электә Эккерт гимназиясе булып, 4 сыйныфлы иде. Бу ел инде нәзарәт тарафыннан яңадан 4 сыйныф арттырылып, 8 сыйныфлы

тиҗарәт мәктәбе итәргә рөхсәт ителгән. Мәктәп өчен көздән күчәргә Проломная урамында, Калягин йортында махсус йорт-сыйныфлар хәзерләнә. Бу мәктәптә французча, немецчә, инглизчә, латинча телләр укытылачак. Программасы ирләр тиҗарәт мәктәбе программасы белән бертигез. Мәктәптә мөселман кызлары өчен дин дәресләре дә кертеләчәк. (Хәзерге көндә мәктәптә 17 мөселман кызы укымактадыр.) Кабул итү имтиханнары майның 27-29ларында булачак. Гаризалар һәркөн сәгать 9дан 12гә кадәр кабул ителәчәк. Мәктәпкә шәкертләр Проломнаядагы Кишнер йортында, Эккерт школасында кабул ителәләр.

Сабан туе

Киләсе җомга көн 23ендә һәм якшәмбе 25ендә хәйрия җәмгыяте файдасына Казанда сабан туе булачак. Сабан туе былтыргы урында, газ заводы янында, ипподромда булачак. Сабан туе сәгать 3тә башланачак. Сабан туе хәзерлекләре күрелмәктә инде. Хәзерләнүләргә караганда, туй мәрасименең [йоласының] гаять тантаналы булачагы өмид ителәдер.

Кояш. — №417. — 20 май.

Мосафир

Татар әдәбиятын тәфтиш белән шөгыльләнә торган зыялыларыбыздан мәдрәсәи «Хөсәения»нең[8] әдәбият мөгаллиме Нәҗип әфәнде Гасрый[9] шәһәребездә мосафирдер. Берәр көн торып, ул ватаны Әстерхан губернасына сәфәр итәчәктер.

1914. — №419. — 22 май.

Сабан туенда хатын-кызларыбыз

Казанда могтәбәр гаиләләрдән берникадәр ханымыбыз бу ел сабан туена барырга карар биргән. Шунлыктан, башка елларга караганда, бу ел сабан туеның мәдәни рәвештә, хатын-кызларыбыз катнашы белән булуы көтеләдер.

1914. — №420. — 23 май.

Мөслимә табибә

Петербургның югары медицина хатыннар курсында укый торган Суфия ханым Агиева («Ак юл» мөхәррире Ф.Агиевның хатыны) государственный имтиханнарын тотып, укуын бик уңышлы тәмам иткән. Шушы көннәрдә Казанга кайтачактыр.

Суфия ханым бай түгел генә бер гаиләдән, гимназиядә укымыйча, хосусый имтихан тотып, югары курсларга кергән иде. Кирәк гимназиядә имтихан биргән елларында вә кирәк курсларда укыган вакытындагы аның тырышлыгы, аның гайрәт вә ныклыгы кешеләр өчен үрнәк бер гыйбрәт вә мисалдыр. Казан вә Петербург яшьләренең күз алдыннан үткән бу иҗтиһад вә бу гайрәтне яшьләр ихтирам белән бик озак заманнар хәтерләрендә тотсалар кирәктер. Яңа табибәгә киләсе тормышында сәламәтлек һәм эшләрендә зур уңышлар телибез!

1914. — №421. — 25 май.

[8] «Хөсәения» мәдрәсәсе — Оренбургта 1891-1919 елларда эшләгән уку йорты.
[9] Гасрый Нәҗип — әдәбиятчы, тәнкыйтьче, шагыйрь, публицист, журналист.

Апанай мәчете

Мөселманча хайван бугазлау

Кичә, шәһәр управасында, управа әгъзасы Шакир Апанаев, шәһәрнең хайван бугазлау ханәсе табибы Григорьев һәм дә мөселман руханиларыннан вәкил булып килгән Касыйм хәзрәт Салихов[10], Сафиулла хәзрәт Габдуллин[11], Галимҗан хәзрәт Галиев[12] катнашы белән шәһәр зәбеххханәсендә [мал чалу урыны] мөселманча хайван бугазлау мәсьәләсе мөзакәрә ителде.

Григорьев хайван бугазлаганда хайваннарның аякларын бәйләү бетерелсен иде, дигән фикерне гарыз итте. Мөселманнар вә руханилар аяк бәйләүнең шәригатьтә күргәзелгәнлеген бәян итсәләр дә, бугазлаганда аяк бәйләү тиешлеге хакында катгый дәлил китерә алмадылар.

Мөселманнар арасыннан, шәһәр зәбеххханәсендә хайван бугазлауны карап тикшереп тору өчен, назыйр [карап торучы] сайлансын иде, дигән фикер кабул ителде.

Бу көн, 21 нче майда, шушы мәҗлестә булган мөселман вәкилләре, шәһәр зәбеххханәсендә хәзерге көндә мал бугазлауның нинди ысулда икәнчелеге белән танышыр өчен, шәһәр зәбеххханәсенә барачаклар.

1914. — №418. — 21 май.

Текстны һәм искәрмәләрне басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.*

[10] Касыйм Салихов — икенче җамигъ мәчете мулласы, 1899 елдан «Касыймия» мәдрәсәсенең («Апанай», «Күл буе мәдрәсәсе» исемнәре белән дә мәшһүр) мөдәррисе.
[11] Сафиулла Габдуллин — 1908 елдан беренче җамигъ мәчетенең имамы.
[12] Галимҗан хәзрәт Галиев — Галимҗан Баруди.

Мәзәкләр

«Шура» журналы, 1909 ел

Җор җавап

Французлар Мәскәүгә сугышып кердегендә, һәрбер карьялардан [авыллардан] гаскәр алынып, сугыш җиренә җибәрелмеш иде. Сугышта җәрәхәтләнмеш гаскәрләр почта юлларыннан кайта башладыкларында, стансаларга туктадыклары илә бөтен авыл халкы, гаскәрләр янына барып, үзләренең карындашларын сорашырлар вә тикшерерләр иде. Бер стансага җәрәхәтле гаскәр кайтып кердегендә авыл халыклары: «Солдат кайтты!», — дип һәр тарафтан йөгерешеп чыга башламышлар. Шул арада бер карчык һәм сугыш хәбәрләре сорашмак улып, бу илә сөйләшмеш.

Карчык: «Сугыш җирендә бер-берегезгә каршы килеп кылыч илә чабасызмыни, балам?!»

Гаскәри: «Чабамыз, әби!»

Карчык: «Башлар өзелеп төшәләрмени?»

Гаскәри: «Төшәләр, әби».

Карчык: «Соң, нә эшлиләр, балам?»

Гаскәри: «Нә эшләсеннәр, башы өзелеп төшмеш адәм, башны алып култык астына кыстырадыр да, бер тарафка йөгерәдер, әби!»

Шура. — 1909. — №4. — Б.128.

Хак «төрттергән»

Рәсем төшереп кәсеп итмәктә булган бер кемсәнең ошбу гамәлен ташлап, табиблык итәргә керештеген күрдегендә, дия Җанәс хәким: «Гүзәл иттең! Сурәт вә рәсем төшермәктә булган хаталарың күзләргә күрелеп торалар иде, әмма табиблык итүеңдә булган хаталарың күзләргә күрелмәс, бәлки туфрак астында яшереләр».

Акчаң булса

Тыйб мөгаллиме имтихан нияте илә үзенең шәкертеннән: «Бер хастаны карарга башладыгыңда иң элек нә кеби хәлләргә дикъкать итәсең?» — дия сорамыш. Шәкерте исә: «Акчасы улып-улмадыгына!» — дия җавап бирмештер.

Шура. — 1909. — №5. — Б.160.

Зирәк карар

Падишаһлардан бере зинданга кереп мәхбүсләр хәлләрен тәфтиш итеп [тикшереп] йөрде. «Нә кеби гаеп илә бунда ябылдың?!» — дия сорадыгында, һәрбере гаепсез вә нахак кердекләрен сөйләделәр. Ялгыз бере үзенең гаепле идекен икърар итте [таныды]. Падишаһ исә, зиндан башлыгына: «Бу әхлаксыз адәмне буннан чыгар! Юкса бу кадәр гаепсез вә намуслы адәмнәрнең холыкларын бозар!» — дия гаепне икърар иттеге өчен буны азат итәргә боерды.

Исән каласың килсә

Мөнәҗҗимнәрдән [астрономнардан] бере падишаһның сөйдеке җариясенең (яшь кол хатынның) вафат улачагын сөйләмештер. Тәсадефе уларак [көтмәгәндә] шул көннәрдә җария вафат итте. Падишаһ исә, ачуын мөнәҗҗимнән алмак касд илә [ният белән], сараена чакыртты вә мөнәҗҗимгә дә: «Син һәркемнең нә вакыт вафат итәчәген белерсең, үзеңнең нә вакыт вафат итәчәксең, буны белерсеңме, сөйлә!» — диде. Мөнәҗҗим дә үзенең үлтереләчәген белеп: «Йолдызыма караганда, синнән ике көн мөкаддәм вафат улачагым», — дия җавап бирде. Падишаһ үзенең әҗәленнән куркып, мөнәҗҗимне үлтермәк фикереннән дүнде.

Шура. — 1909. — №8. — Б.256.

***Рәисә Шәрәфиева** әзерләде.*

«ШАЯН МИРАС»ТА – «ТЫНГЫСЫЗ КАЛӘМ»!

Заманында, 1970-1990 елларда, Татарстан Язучылар берлегендә «Тынгысыз каләм» исеме белән дивар газетасы чыгып килде. Үз вакытында әлеге газетаның баш редактор вазифасын Гөлшат Зәйнашева, Фаил Шәфигуллин, Әхәт Гаффар, Камил Кәрим, Марсель Галиев һәм Ләбиб Лерон алып барды. Күпләр хәтерлидер әле, бизәлеш өчен берара шагыйрь Зиннур Мансуров, рәссам Айдар Үтәгән җаваплы булды. Газетаны чыгарышуда, бигрәк тә Фаил Шәфигуллин редактор булган чакта, Мөдәррис Әгъләмов белән Зөлфәт бик актив катнашты. «Тынгысыз каләм»не укучылар түземсезләнеп көтеп ала иде. Көтеп алырлык та иде шул ул! Җитди язмалар белән бергә, пародияләр, мәзәкләр, шаян, тәнкыйди һәм каһкаһәле, кинаяле мәкаләләр, язучыларның бер-берсеннән көлеп-шаярып язган кечкенә көләмле әсәрләре, төрттерүләре, кыскасы, барысы да бар иде «Тынгысыз каләм»дә!

Басмабызның шушы санынннан башлап, «Тынгысыз каләм»дә басылган иң затлы, иң кызыклы язмаларны сезнең игътибарга «Шаян мирас» сәхифәсендә тәкъдим итеп барырга ниятлибез.

Фаил Шәфигуллин.
Суфия Насыйрова шаржы

КУМПЫК

М.Әпкәли (Фаил Шәфигуллин)

2081 елның кышы салкын килде. Шәһәр буенча грипп йөри. Кибетләрдә тозлы балык саталар. Кар күп. Метроның тагын бер линиясе эшли башлады. Нишләптер аны «Кумпык линиясе» дип атыйлар. Исән чагында Марсель Галиевтән сорап калырга оныткамын. Нәрсәне аңлаткандыр инде «кумпык» сүзе. Ә бит яратып әйтә иде Марсель Галиев ул сүзне. Урамда кемне генә очратса да, исәнләшер алдыннан: «Син кумпыкмы?» — дип сорый торган иде. «Әйе, мин — кумпык!» — дисәң, авызын ерып, рәхәтләнеп көлә иде Марсель Галиев.

Әле дә хәтеремдә: Марсель Галиев шул чорда Казан каласында чыккан «Казан утлары» дигән әдәби, иҗтимагый-сәяси калын журналның проза бүлеген җитәкли иде. Бер бүлмәдә дүрт кеше эшлиләр иде алар.

Район советы депутаты Р.Миңнуллин, Мәҗнүн премиясе лауреаты Рәдиф Гатауллин һәм Мәскәүдә укып кайткан укымышлы егет Солтан Шәмси. Бүлмәләре кысан булса да, күңелләре киң иде егетләрнең. Кергән бер кешене, хәтта Мөдәррис Әгъләмовны да кочак җәеп каршы алырлар иде алар.

Калганнарын хәтерләмим, мәгәр Марсель онытылмый. Аның эш өстәлендә кирпеч калынлыгы кулъязмалар — Мәхмүт Хәсәнов романнары һәм башка язучыларның кайбер әсәрләре өелеп торыр иде. Марсельнең ыспай мыегы гына күренер иде кәгазьләр арасыннан. Өстенә дуңгыз тиресеннән тегелгән кыска пинҗәк, утыра торган җиренә һәйбәт чалбар киеп йөрер иде Марсель Галиев. Ботинкасы да бар иде, но һәрвакытта да олтаны йә купкан, йә ярылган була иде өстәвенә.



Марсель Галиев.
Зөлфәт Хәйруллин шаржы

Әйе, яланаяк йөргән чагын хәтерләмим мин аның. Шуның өстенә кызыл джемпер да кигәләргә ярата иде егет. Егет, дим, Марсель өйләнгән иде бугай шул ул чагында. Зур фатиры, фатирында аерым кабинеты, кабинетында зур өстәле, йомшак урындыгы бар иде аның. Туны да бар иде. Эрот Зариповныкыннан озынрак, Разил Вәлиевнекеннән кыскарак иде бугай аның туны. Бүреген хәтерләмим. Илле сигезенче размер иде шикелле.

Бильярд уйнарга бик маһир иде тагын Марсель Галиев. Бөтен яшьтәшләрен ота, фәкать Гариф Ахуновны гына ота алмый иде. Аны ота алмавына борчылмый иде үзе тагын. Чөнки ул тумыштан ук шат күңелле оптимист егет булган, күрәсең.

Заманында китаплар күп чыгарды ул, төрле жанрда, төрле юнәлештә, төрле үлчәүдә, төрле бәягә эшләде. Шагыйрьләрдән Марс Шабаевны, Равил Фәйзуллинны, прозаиклардан үзен бик яратты, драматурглардан гомер буе көлеп яшәде. Телефоннан сөйләшкәндә трубкага көзгегә баккандай игътибар белән карый иде, ләкин ни өчендер трубканың сөйләшә торган башын колагына куеп, тыңлый торган ягын, киресенчә, иреннәренә терәп утырудан тәм таба иде ул. Әйтәсе дә юк, сәер гадәтләре күп иде Марсельнең. Кеше белән исәнләшкәндә, әйткәнемчә, «Син кумпыкмы?» — дип сорарга яратса, сабуллашканда «Син бөекме?» — дип теңкәңне корытыр иде. Аның: «Син бөекме?» — дигән соравыннан Ринат Мөхәммәдиев белән Зәки Нури гына уңайсызланмый иде. Чөнки икесенең дә буйлары озын, бәдәннәре мәһабәт иде аларның.

Хәтер бик начарланды бу арада. Марсельнең барча сыйфатларын да санап чыга алмыйм. Мәгәр шунысын кистереп әйтәм: салават күпере кебек төрле-төрле төсләргә гаҗәп бай тәти катламасы шикелле катлаулы натура иде Марсель Галиев.

«Тынгысыз каләм», 1981

Туфан Миңнуллин.
Нияз Хаҗиәхмәт шаржы

ТМИН* КАЗАНДА

«Тынгысыз каләм» редакциясе үтенече буенча күренекле чәчәнебез Тмин озак сроклы иҗат командировкасында булып, шактый үзгәреп, сакал-мыек җибәреп, аркасына гобой гитарасы асып, авызына гавана сигареты кабып кайтты. Кайтып ашап-эчкәч, раскладушкага ятып, азрак хәл җыеп алгач, ул редакция халкы белән кул биреп күрешеп чыкты, хәл-әхвәл сорашты, киткәндә алып киткән сигез сум егерме дүрт тиен өстенә тагын дүрт сум унике тиен аванс язуыбызны үтенде һәм кайбер сорауларга җаваплар бирде, ә кайчагында үзе бездән сорады.

Шул әңгәмәнең тузга теркәп барылган аеруча әһәмиятле өлешләрен укучыларга тәкъдим итәбез.

Сорау. Әйтегез әле, хөрмәтле Тмин, сез ни өчен самолёт белән китеп, җәяү кайттыгыз?

Җавап. Бу сорау — провокацион сорау. Чөнки, беренчедән, Тмин самолётка утырмый (курка). Икенчедән, Тмин җәяү дә йөрми (общий вагонлык кына гонорар ала ул «Тынгысыз каләм»нән, сез биргән 8 сум 24 тиен шул максатка тотылды).

Сорау. Сезгә авыллар күбрәк ошадымы, әллә урман-кырлармы?

Җавап. Авыллар, дияр идем. Авылда кибет бар, ә урман-кырда ни бар? Кибет дигәннән, шуны өстәп әйтәсем килә: анда да кайбер нәрсәләр итәк астына яшерелгән — сәгать 11 тулмыйча бирмиләр.

Сорау. Сез булган якларда поэзия алдамы, әллә тәнкыйть арттамы?

Җавап. Минемчә, янәшә атлыйлар. Чөнки мондый хәл күрдем: икәү кочаклашып баралар иде — Поэзия: «Акча безгә мунча ташы, ефәк безгә мунчала», — дип кычкырып җырлап җибәрде, Тәнкыйть: «Үкермә әле», — дип аны туктатты һәм тату гына юлларын дәвам иттеләр.

Сорау. Халык авыз иҗатын җыю белән шөгыльләндегезме бу сәфәрегездә, әллә башка нәрсә беләнме?

Җавап. «...Әллә башка нәрсә беләнме?» дигәндә Сез нәрсәне күз алдында тотасыздыр, белмим, әмма фольклор җыйдым. Җырлар күп. Мисал өчен бер-икесе:

Рукавица, рукавица,
Рукавица — бияли.
«Рукавица-бияли»не
Белә микән КИЯЛИ?

Мой милёнок — татарёнок,
Я — его татарочка.
Ул язганны мин мактыймын,
Мин язганны ул мактыйдыр —
Мировая парочка.
һ.б.

---
* Тмин— Туфан Миңнуллинның әдәби кушаматы

Сорау. «Тынгысыз каләм»гә карата халыкның фикере ничек?

Җавап. Укыйлар, әй. Өлкән язучылар да катнашсыннар иде, әллә аларның юмор хисләре бер бөртек тә калмаганмы, дип сыкраналар.

Сорау. Нәрсәләр иҗат иттегез? Тамыразыклар турында шигырьләр язмадыгызмы (кишер, чөгендер, шалкан, турнипс һ.б.).

Җавап. Күп нәрсә иҗат иттем. Нәкъ менә сез әйткән тамыразыклар өлкәсендә эшләдем. Тик турнипс мәсьәләсе бик борчыды. Рифма табып булмый, пнимаешь.

Кирәк икән куркып тормыйпыс —

Илһам бирә безгә турнипс, — дип язган идем дә — чувашчарак килеп чыкты. «Нейтрон»га гына әйбәт рифма табып була ул, ә менә турнипска табып карагыз. Шалкан мәсьәләсенә килгәндә... Хәер, күп сүз — чүп сүз, шигырьләремне үзегез укып карагыз.

МӘДХИЯ

Авызыгызны ермагыз сез шалкан диеп.
Гөмбә — шалкан, әллә нәрсә — талкан диеп.
Көлеп әйтер өчен генә шалкандыр ул,
Бактың исә микробларга калкандыр ул.
Сәяхәттә озак йөреп арыган идем —
Шалкан каптым — яллар итте организм.
Әминә кислоталарга бай ул шалкан,
Шалкан чәч син, шигырь язып ятма чалкан.

ШАХМАТ ҺӘМ КИШЕР

Заманында Фишер дан тоткан,
Хәзер куркып ята Карповтан.
Сәбәбе ни? Ни булсын — Фишер
Үстерми һәм ашамый кишер.
Рифмам өчен, шагыйрь, син кичер,
Тик үзең дә аша син кишер.

СКЛЕРОЗГА КАРШЫ

Кичә микән, бәлки бүгендер,
Пешердем мин кызыл чөгендер.
Бүген микән, бәлки түгелдер,
Ашадым мин уган чөгендер.
Ашамадым элек чөгендер,
Яман чирем инде чигенер,
Сөйгән ашым хәзер чөгендер.
Склерозың булса, серен бел —
Көне-төне кимер чөгендер.

КИҢӘШ

Шигырь язып җанны ачыттырма.
Бакчаң бармы — үстер ачы торма.
Интервьюыгыз өчен рәхмәт.
Ышанычыбыз — Тминдер, диюегез өчен рәхмәт.

«Тынгысыз каләм», 1977 ■

МИРАС һӘМ ВАРИС

Исәнмесез! Кайгылы чаклар булса да, законнарны төпле белмәү сәбәпле, сезгә мөрәҗәгать итәргә булдым. 3 ай элек улым белән киленем автоһәлакәткә очрап вафат булдылар. 15 яшьлек үсмер кызлары калды. Оныгымны үземә карамага алачакмын, документлар җыям. Сорау башкада. Улым һәм киленемнең ике бүлмәле фатирлары бар иде, икесенә бертигез өлештә язылган. Минем кодагый беркөнне фатир бүлү турында сүз чыгарды. Әллә аңа да өлеш тияме бу очракта? Бу закон буенча дөресме? Баланы мин караячакмын бит алга таба. Улымның, тагын яңа гына кредитка алынган Мазда машинасы бар иде, авариядән соң йөрерлек хәлдә түгел, билгеле. Аның кредитын кем яба инде хәзер? Бу мал-мөлкәтне тиз арада мирас итеп алу тәртибен һәм кемгә күпме өлеш тигәнен аңлатып бирә алмассыз микән. Алдан ук рәхмәт белдереп,

Земфира Каюмова,
Чаллы.



Сорауларга юридик фәннәр кандидаты Таңсылу САБИРОВА җавап бирә:

— Хөрмәтле Земфира ханым! Олы кайгыгызны уртаклашып, юридик яктан сезгә түбәндәге киңәшләребезне бирә алабыз. Беренчедән, фатир бүлү мәсьәләсе буенча. Фатир улыгыз һәм киленегез исеменә бертигез өлешләрдә бүленеп теркәлгән. Рәсәй Федерациясенең Гражданлык кодексының 1142 маддәсе буенча улыгыз һәм киленегез — һәрберсенең өлеше үзенең беренче чират варислары арасында бертигез бүленәчәк. Ягъни, улыгызның ½ өлеше — кызы һәм сез — әнисе арасында ½ өлешкә бүленә һәм киленегезнең ½ өлеше — кызы һәм үзенең әнисе (сезнең кодагыегыз) арасында тигез ½ өлешләргә бүленәчәк. Закон буенча кодагыегыз дөрес фикер йөртә һәм үзенә тиешле өлешне мирас итеп алырга хокуклы. Шулай итеп, закон буенча әлеге фатирның $^{2}/_{3}$ өлеше оныгыгызга, $^{1}/_{6}$ өлеше сезгә, $^{1}/_{6}$ өлеше кодагыегызга туры килә. Билгеле, мораль яктан кодагыегыз сезнең авыр хәлегезне аңлап, алга таба оныгыгызны аякка бастыру сезнең җилкәгезгә төшкәнне күз уңында тотып, оныгыгыз файдасына үзенә тиешле фатир өлешеннән, ягъни мирасны кабул итүдән баш кагарга мөмкин. Мирас алудан баш тарту, варис гаризасы нигезендә, нотариуста теркәлә. Мирастан баш тарткан зат киләчәктә әлеге мөлкәткә дәгъва кыла алмый. Бу очракта, бәлки, сезнең тарафтан кодагыегызга зур булмаган акчалата компенсация тәкъдим итеп карау да дөрес булыр.

Ничек кенә булмасын, тиз арада, паспортларыгызны, улыгыз һәм киленегез вафат булу турындагы таныкнамәләрне, әлеге фатирның улыгыз һәм киленегез исеменә язылу турындагы таныкнамә, фатирга кагылышлы техник документларны җыеп, улыгыз һәм киленегезнең яшәү урыннарына караган нотариуска барып, мирас кабул итү турында гариза язарга кирәк. Улыгыз һәм киленегез вафат булган көннән алып, мирас кабул итү көненә кадәр алты айдан да артык вакыт үтәргә тиеш түгел (РФ ГК, 1154 маддә).

Земфира ханым, машинаны мирас итеп алуга килгәндә, ачыклык кертәм, мирас итеп машина үзе алынмаячак, бередә машина өчен калган кредитны түләү турында сүз бара. РФ Гражданлык кодексының 1175 маддәсенә игътибар итик: вафат булган заттан соң варисларга мирас итеп алган очракта мал-мөлкәт кенә түгел, ә барлык бурычлары да күчә. Димәк, улыгыздан соң калган фатирны мирас итеп аласыз икән, аның машинасы өчен кредитны түләү дә сезнең өстегезгә төшәчәк. Тик, хатыгыздан аңлашылганча, авариядән соң әлеге машина йөрергә яраксыз дип табылган. Машина кредитка алынган дидегез, һәр банк оешмасы диярлек, кредит килешүен (төзегән вакытта сатып алучыны КАСКО иминләштерә) төзергә мәҗбүр итә. Әлеге килешүдә нәкъ сезнең очрак каралган булырга тиеш. Машина хуҗасы авариядә гаепле булмаган очракта, йөрергә яраксыз машина өчен иминләштерү компенсациясе түләнә. Бу акчага сез машина өчен кредитны түли алачаксыз. Машина өчен кредитны ябып бетергәч, ул машина оныгыгыз һәм сезнең арагызда тигез ½ өлешкә бүленә. Машинага булган бурычны мирас итеп алуны шулай ук улыгызның яшәү урынына караган нотариус хәл итә. Кичекмәстән аңа мөрәҗәгать итәргә киңәш бирәм.

Кадерле редакция! Әтиебездә революциягә кадәр төшерелгән фоторәсемнәр тупланмасы һәм шул чор рәссамнары ясаган картиналар саклана иде. Ул вафат булгач, мирас мәсьәләсе калкып чыкты. Без, аның варислары, икәү — мин һәм энем. Бу кыйммәтле ядкярләрнең кайберләрен үзебездә калдырырга, бер өлешен экспертлардан бәһаләтеп, сатарга ниятлибез. Әлеге мирас безнең арада ни рәвешле бүленергә тиеш?

Өммегөлсем Галиева,
Казан.

— Хөрмәтле Өммегөлсем! Сез биргән сорауга җавапны Россия Федерациясенең Гражданлык кодексыннан табып була. Әлеге закон акты буенча (РФ ГК, 1111 маддә) мал-мөлкәтне мирас итеп алуның ике төре каралган: васыятьнамә буенча мирас итеп алу һәм закон буенча мирас итеп алу. Әтиегез исән чагында үз милкендәге малын кемгә нинди күләмдә калдыру турында васыятьнамә язып, аны яшәү урыныгызга караган нотариуста теркәгән булса — бөтен булган милек васыятьнамәдә теркәлгән өлешләргә бүленергә тиеш. Әгәр дә мондый васыятьнамә юк икән, әтиегезнең милкендә булган бөтен мал-мөлкәт беренче чират варислары — балалары, хатыны һәм әти-әнисе арасында бертигез өлешкә бүленә. Хатыгыздан күренгәнчә, әтиегезнең тормыш иптәше һәм әти-әнисе исән булмау яисә мирастан баш кагу сәбәпле, бүген бары тик сез һәм сезнең бертуган энегез мираска дәгъва кыла. Шулай итеп, әтиегезнең милкендә саналган мал-мөлкәт, шул исәптән, фотосурәтләр һәм картиналарише кыйммәтле ядкярләр, сезнең һәм сезнең энегез арасында бертигез өлештә бүленергә тиеш. Шуны да истән чыгармагыз, малны мирас итеп алуның закон белән каралган сроклары бар. Әтиегез вафат булган көннән башлап алты ай вакыт эчендә аның милкендә булган малны мирас итеп алмасагыз, әлеге мал РФ ГК 1151 маддәсе буенча дәүләт милкенә күчә. ■

Редакциядән: хөрмәтле укучылар, мираска бәйле нинди сорауларыгыз бар — языгыз, мөрәҗәгать итегез.Төпле киңәш бирергә без һәрвакыт әзер!

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ / МАЙ

110 ел элек (1904)

● 5 майда күренекле фольклорчы галим Хәмит Ярми дөньяга килә.

100 ел элек (1914)

● 19 майда җырчы, педагог һәм театр эшлеклесе Мөнирә Булатова туа.

95 ел элек (1919)

● Казанда 1 май бәйрәмендә Шамил Усманов чыгыш ясый. «19 нчы елның Беренче мае да Казанда үтте. Колчак Чистайны алган, Лаеш янында тора. Шәһәрдә һәр сәгать восстание көтәләр. Братская могилада булган митингка безнең 1 нче татар полкы ике меңкешедән артык составта җыелып барган иде. Мин брәдәрләр зыярәтендә трибунага чыгып сөйләдем. Кич белән полк циркта вакытта бригада командиры Ибраһимов, миңа срочный хат җибәреп, 2 нче армиянең минем өстемнән донос язганнарын, Малютинның мине атарга теләгәнен белгерде. Мин игътибарга да алмадым. Кәеф күтәренке иде». Әдип бу көн хакында үзенең көндәлегенә әнә шулай дип язып куя.

● Казанда «Мәгариф» һәм «Бертуган Кәримовлар» дип аталган шәхси типографияләр конфискацияләнә.

85 ел элек (1929)

● Алтын Урданың башкаласы Сарай шәһәрендә язылган борынгы тел-әдәбият истәлеге «Нәһҗел-Фәрадис» исемле китапның Сәед Вахиди тарафыннан өч нөсхәсе табыла.

75 ел элек (1939)

● 5 майда ТАССР Югары Советы Президиумы татар язуын латин алфавитыннан рус графикасы нигезендә төзелгән алфавитка күчерү турында Указ чыгара.

70 ел элек (1944)

● 18-19 майда кырым татарлары Ватаныннан сөрелә.

● II Белоруссия фронтында татар телендә «Фронт хакыйкате» исемле газета чыга башлый.

55 ел элек (1959)

● 9 майда Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган яшь шагыйрь Мансур Гаязга (5.10.1917-19.11.1943) Мари АССРның Бәрәңге районы Бәрәңге авылында истәлек-такта куела.

● Франциядә нәшер ителә торган «Франция-СССР» исемле журналда атаклы француз шагыйре Луи Арагон тәрҗемәсендә Муса Җәлилнең «Ышанма» һәм «Җырларым» исемле шигырьләре дөньяга чыга.

50 ел элек (1964)

● «Совет әдәбияты» журналында Илдар Юзеевның «Язылмаган поэма»сы басыла.

45 ел элек (1969)

● Татарстан китап нәшриятында Гамил Афзалның «Мирас», Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр», Ләбибә Ихсанованың «Көмеш елга», Мөхәммәт Мәһдиевнең «Атадан бала яшь кала» һәм Марк Твенның «Принц һәм теләнче» китаплары дөнья күрә.

Мирасворд

Тоткын
Армия

нота

...-Лумпур (Малайзия мәркәзе)

Төп, нигез (иск.)

Сәламәт

... Яһүдин

Таләп ителгән, тиешле (иск.)

Ярослав Гашекның милләте

... Камалов

... Шакирҗанова

Борынгы төркиләр байрагы

1944-1945 елларда чыккан фронт газетасы

Түче (ант.)

Болгария акчасы

... Шимин

Хабаровск краенда яшәүче халык

Куркыныч килүен белдерә торган сигнал

Яуга чакыру авазы

Җиңү авазы

Поляк алпавыты

Франция каласы

Пулядан саклану чокыры

Ачы төтен

Оканың уң кушылдыгы

Германиядәге тарихи өлкә
Гектар

Легендар крейсер

Европадагы иң зур күл

Аяк чолгавы

Виноград сорты

Элек җан башына тигән

Рим мифологиясендә сугыш алласы

Казах, кыргызларда шагыйрь-җырчы

Удмурт (иск.)

Иосиф Броз ...

Көньяк агачы

Морза
... Әлмиев

Армиядә хезмәт итүче

Кыю, куркусыз

Траншея, вал
Хәрби бирәмлек

Рәис Габдулла төзеде.

4 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: кыпчак, Насрый, им, гаян, Каюм, бу, Эшпай, гагауз, гетр, киек, Клим, нирвана, аем, замш, Аяз, Огове, Акмулла, бәхтәр, арт, Сен, мәкам.
Өстән аска: Гог, акинак, яугир, ям, Кунанбаев, зубр, указ, әл, си, эз, на, Лхаса, чирмеш, кам, Атрек, Ош, Әтнә, куй, кари, Айтматов, Магомаев.

Х.МИННЕГУЛОВ
ЭТАПЫ РАЗВИТИЯ ТЮРКО-ТАТАРСКОЙ, АНТИЧНОЙ И РУССКОЙ ЛИТЕРАТУР. –
Казань: Ихлас, 2014. 288 с. (500 данә)

Әдәбият фәне дөньясында, иң беренче нәүбәттә, Борынгы һәм Урта гасырлар татар әдәбиятын Шәрык классикасы белән әдәби-мәдәни бәйләнешләр контекстында тикшерүче галим буларак танылган Х.Миңнегулов соңгы елларда үзенең фәнни эшчәнлеге орбитасын тагын да киңәйтә төште. XX-XXI гасыр чикләрендә совет чорында зәгыйфьләнеп калган төрки-тугандаш халыклар белән аралашуның яңарышы өчен мөмкинлекләр барлыкка килде. Татар зыялылары һәм галим-голямалары арасында бу эшкә, беренчеләрдән булып Х.Миңнегулов тартылды. Дистәләгән саллы хезмәтләр авторы булган әдәбият белгеченең күптән түгел рус телендә «Төрки-татар, антик һәм рус әдәбиятларының үсеш этаплары» дигән күләмле хезмәте дөнья күрде. Әлеге монографияне язуга төрки әдәбиятлар тарихын өйрәнүгә багышланган киңкырлы эзләнүләр дә, әдәбият белемендә чагыштырма-тарихи, компаративистик юнәлешнең көчәюе дә, бай рухи хәзинәне бүгенге буынга җиткерү омтылышы да этәргән күрәсең.

Китапның беренче бүлегендә бай гыйльми-нәзари һәм гамәли тәҗрибәгә нигезләнеп, сүз сәнгате тарихын чорларга бүлүнең фәнни-методологик принциплары системалаштырыла һәм гомумиләштерелә, дөнья әдәби хәрәкәтенең аеруча әһәмиятле баскычлары аерып чыгарыла. Шушы теоретик бүлектә күзалланган гыйльми күзаллаулар фонында төрки-татар, татар әдәбиятының үсеш баскычлары, һәр тарихи-әдәби чорның закончалыклары һәм төп сыйфатлары, күренекле язучылар иҗатының идея-эстетик байлыгы яктыртыла. Татар сүз сәнгате, милли рамкаларда гына чикләнеп калмыйча, антик һәм рус әдәбияты рухи хәзинәләренең эстетик сыйфатларын теге яки бу дәрәҗәдә үзләштерә. Әдәбият тарихының нигезен тәшкил иткән антик мәдәният һәм рус сүз сәнгатенең тарихи баскычларга бүленеше дә татар әдәбияты белән бәйләнештә тикшерелә һәм әдәбият фәненең аерым җитди проблемаларына ачыклык һәм төгәллек кертелә.

Китапның «Йосыф Баласагунлыдан Чыңгыз Айтматовка кадәр» дигән икенче кисәге, аның әүвәлге өлешендәге нәзари материал белән бәйләнештә булып, рухи мирасыбызны моңа кадәр аз яисә бөтенләй билгеле булмаган материаллар белән баета. Мәсәлән, «Пушкин телендә Тукай», «Габделгазиз Монасыйпов иҗатында дөнья картинасы», «Закир Кадыйриның тормышы һәм киңкырлы эшчәнлегеге сәхифәләреннән» һ.б.шундыйлардан.

Хезмәттә Х.Миңнегулов гыйльми эшчәнлегенең асыл хасиятләреннән берсе — әдәби күренешне шәрехләүдә һәм бәяләүдә фәнни төгәллекне, объективлыкны һәм принципиальлекне ассызыкларга кирәк. Галимнең әдәби-мәдәни бәйләнешләр яссылыгында эшләнгән «Төрки-татар, антик, рус әдәбиятларының үсеш этаплары» монографиясе татар әдәбиятының гына түгел, төркология-ориенталистика фәненең зур казанышы булып тора.

Таһир Гыйлаҗев,
филология фәннәре кандидаты ■

ВӘКИЛ ШӘЙХЕТДИНОВ

«Мәккә янында таң ату күренеше». 1996.
Киндер, майлы буяу

Вәкил Гайнелгыйлем улы Шәйхетдинов 1951 елның 5 маенда Башкортстанның Бүздәк районы Кәпәй-Кобау авылында туа. 1974 елда Уфа сәнгать училищесын, 1980 елда Уфа сәнгать институты театраль факультетының сәнгать бүлеген тәмамлый. 1991 елдан — СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы.

Вәкил Шәйхетдинов — заманча реализм өслүбендә иҗат итүче рәссам. Күп рәсемнәре киндер вә майлы буяу техникасында язылган. Ул, шулай ук, монументаль-декоратив сәнгать өлкәсендә дә эшли. Уфадагы «Нур» татар театрының фойесындагы 90 квадрат метрлы флоренция мозаикасын ул иҗат иткән. Аның Башкортстан һәм Россия калаларында 20дән артык шәхси күргәзмәсе оештырылды.

Вәкил Гайнелгыйлем улы — Башкортстанның атказанган рәссамы һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

«Җомга намазы». 1996.
Киндер, майлы буяу

«Тимучин». 2005. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САННАРДА:

Яңа табылган «Нократ бәете»

Кырым татар драматургы Усеин Болатуковның моңарчы дөнья күрмәгән «Айшә ханым» пьесасы

Илһам Гомәров. «Иран татарлары»

Билгесез авторның 1896 елда басылган «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр аз, дигән сүз – рас сүз» хикәяте

Үткәннән хатлар. Каһәрле язмышка дучар булган шагыйрь Сирин Батыршинның бер кайда да басылмаган хаты һәм аңа Афзал Шамовның җавабы

Мостай Кәримнең «Җәләлетдин әти» хикәясе

Ленар Гобәйдуллин. «100 ел элек авыл сабантуйлары»

Себастьян Цвиклински. «Әл-Җиһад» газетасы сәхифәләреннән»

Индекс:
Татарстанда – 54132
Чит төбәкләрдә – 70275

Икенче артыеллыкка язылу бәясе – 420 сум
Редакциядә язылу бәясе – 319 сум

4 612750 670172